Безнең МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
12
декабрь 2018
ISSN:2500-011X
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ӘМИР МӘҖИТОВ «КЫШКЫ ӘКИЯТ».

Татарстан архивларына – 100 ел

21 ноябрь көнне башкалабыз Казанда Татарстан Республикасы дәүләт архив хезмәтенең 100 еллыгына багышланган тантана узды. Әлеге чарада Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Федераль архив агентлыгы җитәкчесе Андрей Артизов та катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

12 (300)

декабрь 2018

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

24


TÜRKİYE CÜMHURİYETİ

Ankara Hukuk Fakültesi mezuniyet diploması

Ankara Hukuk Fakültesinde okunan derslerden imtihanları neticesinde Pek eyi derecede mezuniyete liyakat kespeden Kıbrısta doğmuş Hüseyin Cahit Beye devletin kanun ve nizamlarının tanıdığı haklardan istifade etmek üzere bu diploma verilmiştir. 20. V. 1928

Fakülte reisi V. Adliye vekili

Diploma No 1

Ahmet İhsan matbaası

ЭЧТӘЛЕК

48 **ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ.** *Габдерәшит Ибраһимов*

62 **САУ БУЛ, АВЫЛЫМ!** *Хәлим Җәләй*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Гамил Афзал**

ТАРИХИ МИРАС

4 **Гәүһәршад.** *О.Иванова*
12 **Казан ханлыгының язмышы.** *Б.Хәмидуллин*
20 **Гани бай хатирәсеннән исемдә калганнары.** *Т.Соловьев*
24 **Әнкара хокук мәктәбенең тарихи әһәмияте.** *С.Максуди*
29 **Ачлыктан соң Татарстан авыллары.** *Р.Сабиров*
34 **Эчкен татарлары.** *Р.Исакаев*
38 **Мөхәммәт Мәһдиев мәкаләләре**
42 **Хәлемездән шикаять.** *Ш.Күлтәси*

ДИНИ МИРАС

48 **Ислам дөньясы.** *Габдерәшит Ибраһимов*
54 **2019 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр**

ӘДӘБИ МИРАС

56 **Үткәнгә хат.** *Н.Гыйләҗева*
60 **Сәгыйть Сүнчәләй**
62 **Мәгыйшәт.** *С.Максуди*
68 **«Яңгыр җиле» яңгыр вәгъдә итә.** *М.Әгъләм*
73 **Шагыйрь Бәдрүш Мокамай.** *Ф.Хәбибуллин*
78 **Гыйбрәтле хикәятләр**

ХӘТЕР САНДЫГЫ

84 **Сау бул, авылым!** *Х.Җәләй*
90 **Соңгы очрашу.** *Ә.Фәйзрахманов*
92 **Истә, һаман да истә!**

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

94 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
96 **Сүз уравын белмәгән үзенә сүз китерер...** *Р.Хәбибулла*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)
Лотфулла Шәфигуллин
(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Данил Салихов
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89520365448

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-92)

Бүлек мөхәррирләре
Марат Закир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

ХӘТЕР САГЫНДА

98 **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
104 **Симетбаш мәчете**
108 **Киез итекләр иле**

112 **«Безнең мирас» хәбәрләре**
114 **Мирасворд**
115 **«Безнең мирас» елъязмасы**. *Декабрь*

Заказ №Е-3140. Тираж – 2050 данә. Формат 70 X 108 $^1/_{16}$.
Басарга кул куелды: 23.11.2018.
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Кышкы әкият». 1962. ***Әмир Мәҗитов рәсеме***

Гамил Афзал

(23.05.1921-20.08.2003)

***

Тау күтәреп бара-бара,
Талпына да сүнә йөрәк.
Үлеп күрсәтү – бер чара,
Яшәп күрсәтү дә кирәк.

***

Бакча кебек гомер юлы,
Җилкапкаңа җил какса да;
Карурманда карга тулы,
Сандугач бул бер бакчада!

***

Тынмый күңел авыз йомып калган белән,
Чын кешегә авыр була – алдан беләм;
Җил-давылсыз үтәр идең гомер юлын,
Тешне кысып тату торсаң ялган белән.

***

Мин утырам, күзгә күзне терәп,
Үз намусым белән кара-каршы.
Ялгышсам да кайчак сирәк-мирәк,
Намус белән тату тору яхшы.

***

Ат аунаган җирдә төк калды.
Урманны кистеләр – төп калды.
Төп астында тирән тамырлар.
Шул тамырдан безне танырлар.

***

Хак булса да гәрчә, ят күренә
Ялгышыңны әйтеп бирүче.
Былбыл булып куна өй түренә
Матур итеп алдый белүче.

*Текстны **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

Гәүһәршад

Ольга Иванова

Тәрҗемәчедән

Трилогиянең бу китабы Гәүһәршад белән Булатширинның чираттагы уңышлы «эш йөртүе» белән төгәлләнә. Аның нәтиҗәсендә Сафагәрәй хан Казаннан качып китәргә мәҗбүр була.

Ләкин сарай эчендәге хәлләргә үзе теләгәнчә юнәлеш биреп торучы ханбикәгә дә «уңыш» дигәнең бер битен, бер... арт санын күрсәтә шул... Сафагәрәй тәхеткә кабат әйләнеп кайтканнан соң янә бер түнтәрелеш көтелгәндә, Кырым аксөякләренең вәкилләре берләшеп эш йөртүчеләрне фаш итүгә ирешәләр. Тарихчылар билгеләп үткәнчә, шул җәнҗалдан соң, Гәүһәршад ханәкә белән олуг карачы Булатширин сәясәт мәйданыннан бөтенләйгә читләштереләләр. Әмма Казан ханлыгының әлеге күренекле шәхесләре белән чынлыкта ни булып беткәне билгесез. Кыйссада фаразланганча, Булатширинның җәзалап үтерелгән булуы ихтимал. Ә Гәүһәршад турында ике риваять сакланып калган. Аларның берсендә, Юраучы аның иле тиздән юк ителәчәген алдан күреп хәбәр салгач, бу кара көнне күрмәс, ватандашларының бәхетсезлегенә шаһит булмас өчен, ханбикә, Кабан күленә ташланып, үз-үзен шәһит иткән, дигән тарих сөйләнелә. Икенче риваять исә батып үлгән Гәүһәршад, имеш, убырга әверелеп, яшүсмер малайларны Кабан күле төбенә алып төшә икән. Бәлки, чыннан да, ханбикә, шушы хәлләрдән соң, су буйлап Казаннан качарга уйлагандыр һәм Кабан күлендә батып үлгәндер? – Тик бу хакта тарихта ышанычлы чыганак юк.

Кайбер тарихчыларның фикеренчә, Гәүһәршадның Казанны саклап шәһит киткән булуы да ихтимал.

Роман мөәллифе тасвирлаганча, Гәүһәршад хан кызларына тигән язмышы белән килешә алмый, гомере буе агымга каршы бара, үзе теләгәнчә яшәп, ирләр белән тиң булырга омтыла. Әнисеннән алып җиткерә алмаган җылылыкны ул үзе үскән кояшлы Кырымга нәфрәт катыш мөнәсәбәте һәм Нурсолтан сайлаган юлны инкарь итүе белән дә табарга теләгәндер кебек.

Тарихчы галимнәр табып терки алган азмы-күпме мәгълүмат та бу омтылышның нигездә тормышка ашканын раслый. Әсәрнең үзен (кызганыч ки, татарчага аударылган өлешен) укыйк....

Мөдәррис Вәлиев

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

Гәүһәршад ханбикәне Мөхәммәдьяр икенче көнне иртән, хуҗабикәләрен – ханның искиткеч мәрхәмәтле кызын сәламләргә, дип аланга җыелган шагыйрьләр, көйчеләр, юраучылар һәм йолдызбагарлар җыенына килеп кушылгач кына күрде. Хаҗи белән бергә, хөрмәт йөзеннән кулларын күкрәкләренә кушырып, башларын иеп, ханбикәнең сарай хезмәтчеләре арасында басып торалар иде, Гәүһәршад нәкъ менә алар янына килеп туктады.

– Миңа, Сез Сәмәркандның үзеннән килгәнсез, дип әйттеләр, шулаймы? – дип сүз катты ул.

Башын күтәреп карарга әле һаман да кыюлыгы җитмәгән Мөхәммәдьярга хансолтанның тирәннән чыккан хисле тавышы матур көй булып яңгырады, ул үзенә буйсындыру, тартып тору сәләте белән сихерләде булса кирәк. Затлы нәселдән чыккан ханбикәнең соравын остазына юнәлтүенә куанды мөрид, югыйсә ул үзе дулкынланудан тел тибрәтә алмаган булыр иде.

– Әйе, чын-дөресе шулай, олуг хөрмәткә лаек мөхтәрәмә ханым-солтаным, мин Сәмәркандтагы шагыйрьләр мәктәбендә мөдәррис идем, – дип, үз дәрәҗәсен белеп, сабыр гына җаваплады хаҗи. – Ә аңа хәтле халкым бәхете, минем бәхетем булган Казанда Сезнең кодрәтле абыегыз Мөхәммәдәмин хан – исеме телдән-телләргә күчеп, гасырларда дан казансын, Аллаһ аңа разый булып, оҗмах түреннән урын бирсен, йа Рабби, – сараенда хезмәт иттем.

– Амин, – дип, теш арасыннан гына сыгып чыгарды ханбикә һәм күз карашын, түземсезләнеп, Галим хаҗи янәшәсендә катып калган оялчан яшь егеткә күчерде. – Миңа, Сезнең белән иң акыллы шәкертегез дә килгән, дип хәбәр бирделәр. Менә улмы инде?

– Нәкъ шулай, нурлы ханым-солтаным. Аның исеме Мөхәммәдьяр була, газәлләрне аңардан уздырып сөйли алган, нәфис авазлардан, мәгънәле уй-фикерләрдән үрелгән касыйдәләрне шулкадәр оста язарга сәләтле бүтән берәү дә юк.

– Менә хәзер шуны тикшереп карарбыз да, – дип, Гәүһәршад бармакларын шартлатып алды, күз ачып йомган арада, хезмәтчеләре алан уртасына ханбикә тәхетен чыгарып куйдылар. Ул анда ипләп кенә менеп кунаклады. Гыйлем-сәләт ияләре булган ир-егетләр исә туп-туры аяк асларындагы яшел «келәм» – чирәм өстенә утырдылар, бары тик Мөхәммәдьяр гына аягүрә калды. Йөрәге туктардай булып типкәндә шагыйрь ханбикәгә күзләрен төбәп карады һәм... алсу хыялы эреп югалудан аһ итеп, авыр сулап куя язды. Колак сиземе белән шигъри хыял аны алдалаган булып чыкты, егет, баштарак күз алдына китергәнчә, Гәүһәршадның яшь кыз булмавын танырга әзер иде инде, әмма аның тавышы әлегә кадәр сихерләвен дәвам итте, таң калып соклану мизгелен тагын бер кавымга озайтты. Тик бер чара да юк: Мөхәммәдьяр, каршысында үз дигәнен итә торган караләҗым күзле, авыр сөякле ханымны күргәч, аның әлегәчә үзенә җәлеп итеп, хәтта гыйшык хисләре уятырлык кодрәткә ия җиңел өрфиягә төрелгән сурәте, кояш күтәрелү белән эреп таралган томан сыман, әзсез-нисез юкка чыкты. Яшь булмавы бер хәл, хатын-кызларга гына хас мөлаемлык, назлылык бөркелеп тормавы күңелне шунда ук суытырлык халәткә күчерергә сәләтле иде. Аның каравы, ханбикә егетне ачыктан-ачык хуплавын яшереп тормады.

– Остазыгыз Сезне бик мактый, – дип, илтифатлы, хәерхаһлы тавышы белән эндәште Гәүһәршад. – Хафиз Ширазиның берәр шигырен укып күрсәтегезче, мин аның иҗатын яратам.

Мөхәммәдьярга, күптән түгел тагын бер кат күздән кичергән юлларны хәтер хәзинәсеннән казып чыгарыр өчен, каушап калуын тиз генә җиңәргә кирәк иде. Ул,

үзенә таяныч эзләгәндәй, агачларга, шау чәчәктә утырган бакчага күзен тутырып карады һәм шул мизгелдә куе-татлы шигырь иреннәннән бал сыман агып чыкты:

«Йөрәгем үзе ия булганны гына сорады:
Телдәге тылсымлы касәдә җиһанны урарга...
Энҗе бөртеге, тапкыр сүз җәүһәре сачелде...
Сукырдан садака эстәде – һәм күзе ачылды!»

Серле көчләрдән тукылып, илһам канатында гарешкә күтәрелгән юллар сихерләве шул мәлдә аны чынбарлыктан алып китүе булдымы, Мөхәммәдьяр инде үз илендә зур хөрмәт яулаган ханбикәнең чыраен күрмәде, үзен колак торгызып тыңлаган шагыйрьләргә дә игътибар итмәде, ул кайчандыр ерак Ширазда язылган шигырь алып килгән гаҗәеп хисләр, дәртле хыяллар дулкынында тирбәлә иде. Егет, шул халәтне сакларга, ләззәтне озаграк татырга омтылып, күзләрен йомды, ә йөзен сәмави яктылык балкытты.

«Сорады Хафиз:
– Ә нишләп мәхәббәт зынҗырдай, богаудай авыр?
– Йөрәк акылдан язып җырлар өчен татлы сызланыр!»

Мөхәммәдьяр, ниһаять, күзләрен ачты, Гәүһәршад аңа өзми-куймый карап тора икән, сәбәбе шул: дәртле-илһамлы бу яшь егет аның шулкадәр озак дәшми яткан, инде суына башлаган күңел кылларын кузгатты. Аңардан саф хис, күтәренке рух бөркелә, шул ук вакытта чиктән тыш зур көч белән үзенә тарта! Бәлки, шигърият тылсымы зур осталык белән кушылып, аңа җан иңдергән ымсындыргыч шагыйрь тавышы ханбикәне әлегәчә татып бетерә алмаган мәхәббәт биеклегенә чакыргандыр? Әллә соң яшүсмерлек бусагасыннан яңа гына атлап чыга башлаган бу ир-егет шундый ук, кайчандыр күңелен алгысыткан, сүзгә оста, якты яшел күзләре һәм ияк астын каймалаган кечкенә ефәк сакалы белән әле дә хәтер төпкелендәге кайнар көл астында калган утлы күмер сыман янып торучы бүтән берәүгә охшаган булып тоелдымы аңа? Йокымсыраган йөрәген уяткан яшь шагыйрь, чыннан да, олы карачы Булатширинны, әле аның яшь морза чагын һәм чак кына аның ире була язып калган елларны исенә төшерде Гәүһәршадның. Аһ, йә үкенеп, гарьләнеп, яисә шулчакта бәдәни теләкләрен җиңеп, корычтай нык ихтыяры тантана иткәненә сөенеп, ничек еш яңарта иде ул бу хатирәләрне!

Ханбикә утырган төшеннән торды, аның ишарәсенә буйсынып, хезмәтчесе кыйммәтле билбау алып килде. Алтынланган тәңкәләрдән хасил бу билбау асылташлар белән мул итеп бизәлгән һәм монда җыелганнарның инде күптән күзен кыздыра, аны кулга төшерү иң зур теләкләреннән берсе иде. Әлеге путаны затлы нәселдән чыккан хуҗабикәләре, араларындагы иң булдыклысына бүләк итәрмен, дип ышандырды һәм алар инде, искиткеч матур һәм кыйммәтле бу җиңү билгесен кулга төшерү өчен, күпме айлар буенча үзара үртәлә-үртәлә ярыштылар.

– Мондарак кил, Мөхәммәдьяр, Мәхмүд хаҗи углы, – дип, шәһвәтле тавышы белән үзенә якынрак чакырып алды Гәүһәршад. Шагыйрьне ул күпкә ымсындырган карашы белән назлады, чын күңелдән әйтелгән сүзләре белән үзенә каратты: – Ошбу бүләк яхшыларның яхшысына, сандугач теленә ия булганнарга биреләсе иде. Мин, гаҗәеп күбәләкләр сыман, колак яфрагымны иркәләп, күңел кылларымны тибрәтеп, йөрәгемне җилкендереп очардай җиңел сүзләр иясен табарга теләгән идем. Син ханбикәңне таң калдырдың, Мөхәммәдьяр, ә бит мине гаҗәпләндерүе бер дә җиңел түгел.

Ул чытлыкланып елмайды да шагыйрьгә затлы билбауны сузды. Мөхәммәдьяр, тезләнеп, башын иде һәм ханбикәнең бүләген кабул итте. Ул көндәшләренең ризасызлык белдереп пышылдашуларын ишетте, бу мәлдә өметләре өзелгән әлеге кешеләрне, хуҗаларының җиңүчене шулкадәр озак эзләп тә, зарыгып көтелгән бүләкне аларның бусагасын әле генә атлап керергә өлгергән чит-ят мосафирга бирүе аптырашта калдырды. Әмма берсе дә үзенең фикерен авыз ачып әйтергә кыймады. Ә инде ханбикә хезмәтчеләре бәһасез һәдияне Мөхәммәдьярның гади генә чапанына урап куюга, ханбикә яраннары арасындагы шагыйрьләр, дәррәү кузгалып, бәхетле кунакны котларга тотындылар. Алар, әлбәттә, Гәүһәршадның кырыс, таләпчән күзәтеп торуы астында соклануларын белдерергә ашыктылар. Гәрчә һәр икесенең берсе, бүләк язмышы читтән килеп кергән егетнең күркәм кыяфәте аркасында гына шулай хәл ителде, дип саный иде. Бары тик остазы – мөхтәрәм мөдәррис Галим хаҗи гына шәкертен ихлас күңелдән тәбрикләде, ул аның җиңүен үзенеке кебек горурланып кабул итте.

«Гәүһәршад». Зөфәр Хәкимов рәсеме

Хезмәтче хатын-кызлар белән урап алынган ханбикә шуннан соң өенә кереп китте, ә аланга җыелган ир-егетләр бакча буйлап таралышты. Әле тәгам җыю вакыты җитмәгән, шуңа күрә һәркайсы үз эшенә кереште, тик каләм әһеленең генә күпчелеге, төп шөгыльләрен читкә куеп, үзара гайбәт сөйләшеп, яңа килгән ике шагыйрьне чәйнәүдән юаныч тапты.

– Карап карарбыз, бу малай монда озак түзеп тора алырмы әле?

– Аллаһка шөкер, хуҗабикәнең утарында аны җәлеп итәрлек ирләр байтак, ә бу кошчык бары кабымлыкка гына ярый.

– Мөриден яхшы гадәтләргә өйрәтмәгән картлач белән икесен дә бусаганың теге ягына чыгарып ташларлар әле.

– Сәләтле шагыйрьдә нинди гадәтләр булырга тиеш соң? – Тәкъдирдә ни язылганын алдан күреп торучы йолдызбагарның шыгырдавык тавышы гайбәтчеләрне сискәндереп, коргаксыган, бөкрәйгән картка борылып карарга мәҗбүр итте. Чуалып беткән сакаллы бу кәкре-бөкре Ходай бәндәсен бер ай гына элек ханбикә йортының идарәчесе кәрвансарайларның берсеннән табып кайткан иде. Карт юраучы Үргәнеч хакименең бик тиздән каберстанга китәсен юраган икән. Хаким, җене чыгып,

картлачның башын чабып өздерергә ниятләгән, әмма аксакал, монысын да алдан күреп, муенын тумранга куйганчы күздән югалырга өлгергән. Инде юлга чыккач, хакимнең үлеме турындагы хәбәр аны куып җитте исә, юраучы авыр сулап:

– Без барыбыз да Аллаһ хөкемендә, – дип кенә куйган.

Йолдызбагар Казанга бер сәүдәгәр кәрваны белән кайтып иреште, Кырым ханының сараена китәргә карар кылганчы, ханәкәдә яшәп торды. Аның, мондый һөнәргә ия затларны ул якларда аеруча яратып кабул итәләр икән, дип ишеткәне бар иде. Үзен Юраучы дип таныткан карт, Казанда озак тоткарланмыйча, юлын дәвам итәр өчен, кәрван башын эзләргә кереште. Әмма аңа кадәр Гәүһәршадның утар идарәчесе өлгеррәк булып чыкты. Хакименең үлемен көне-сәгате белән алдан әйтеп биргән йолдызбагар турындагы хәбәр ханбикәгә килеп ирешкән иде инде. Юраучы, хан кызының биләмәсенә килеп кергәч тә, аның йолдызлар фаразы буенча язмышын алдан белгеләргә кереште. Әмма, шагыйрьләр арасында булырга туры килгәнлектән, аларны вакыт-вакыт, колакларының бик ишетәсе килмәсә дә, һич көтелмәгәнчә алдан күреп әйтелгән сүзләре белән шаккатыра иде. Әле кичә генә ханбикәнең зур бүләге – танылган түрәләргә генә лаек затлы билбауның чатырда утыручы берәүгә дә тәтемәячәген хәбәр итте картлач. Зыялылар кавеме ул чакта йолдызбагарның бу юравын мәзәккә санап шаркылдашканнар иде, ә хәзер, шуны искә төшереп, телләрен тешләделәр. Авызларына су капкан кебек, берсе дә дәшмәде, сәер бабайның үзләренә берәр бәла-каза киләсен алдан күреп әйтүеннән куркып, аның белән бәйләнешкә керәселәре килмәде. Бары тик Хәмса Дутар – госманлылар җиреннән килгән шагыйрь генә бәхәсне куертырга маташты:

– Хөрмәтлем, Сез бу малайның сәләтен кайдан багып күрдегез соң? Йолдызлар буенча, дисәң, алар әле күктә кабынып та өлгермәгән бит? Аның кеше язганны көйле генә сөйләп чыгуы гаҗәп түгел, ә каләм иясе буларак нәрсә майтара алганын әлегә ишеткән-күргәнебез юк ләбаса.

– Егетнең нәрсәгә сәләтле булуын бәяләр өчен, күккә карарга кирәк булмады. Мин, очраклы рәвештә генә, остазына аның үз иҗат җимешләрен укып торганын ишеттем. Бу шагыйрьнең киләчәге бик зур. Мондагыларның берсенә дә Ходай Тәгалә андый язмыш насыйп әйләмәгән. Чөнки сезгә бары бер генә сәләт бирелгән, ул да булса – үзегезне сыендырган, тукландырган хуҗабикәгә куштанланып дан җырлау. Очынуларыгыз затлы нәселдән чыккан хатынның күңелен яулап очланмады, хәтта шунысы да хәлегездән килмәде, димәк...

Шагыйрьләр төркеме дулкынланып-чайкалып алды, ачулары килде, ләкин карт йолдызбагар инде аларны тыңлап тормады, ул игътибарын үзенә таба килгән хезмәтчегә юнәлткән иде. Ә тегесе исә Юраучыны ханбикәнең үз катына чакыруын ирештерде.

Шагыйрьләрнең берсе, уйга калган карашы белән картны озатып калгач, барысыннан да ерактагы эскәмиядә утырган Мөхәммәдьяр белән Галим хаҗи янына юл тотты. Бу агай яшь түгел инде, сакалына куе «кар бөртекләре» кунган, ак чалмасы астындагы чәчләре дә чаларган. Ул, башын иеп сәламләгәннән соң:

– Мин Әхмәдеддин ибн Мәхмүд дигән кеше булам, тумышым белән Шираздан, хөрмәтлеләрем, – дип, үзе белән таныштырды.

– Бөек Хафиз Ширази кебекме?! – дип җанланып китте Мөхәммәдьяр.

– Әйе, син аның газәлен гаҗәеп матур итеп сөйләдең, улым, – дип, бу көркәм йөзле аксакал, яратып-хуплап, мөриднең иңеннән какты. – Тик бер сөалем бар, егет: син монда озакка тоткарланырга уйлыйсыңмы? – Яшь шагыйрьнең аптырашлы карашын

тотып, ул әлеге соравына сабыр гына ачыклык кертте: – Ихтимал, авыр юллар узып килгәннән соң, сиңа монда оҗмахка эләккән кебек тоеладыр, әмма бу рәхәтлекнең тышкы кабыгы алдаучан. Аның ятьмәсенә төшеп уралганчы, мин сиңа тышы гына ялтырап күренгән әлеге оҗмахны ташлап китәргә киңәш итәр идем, – диде.

Мөхәммәдьярның мөхтәрәм остазы, Шираздан килгән шагыйрь аларга чыгу капкасын ачып куйганын күргән кебек, кинәт күтәрелде дә:

– Сездә көнчелек уянмадымы икән, Әхмәд әфәнде? Бу бүләк өчен бер көн генә көрәшмәгән ирләрне узып, аны минем шәкертем яулый алды, инде Сезне ханбикәнең мөридемә булган җылы карашы борчуга салгандыр, күрәсең! – диде.

Шагыйрь чал сакалын селкеп алды, Мөхәммәдьяр аның акыллы күзләрендә һич тә көнчелек түгел, ә бәлки кешеләрчә гади генә хәлгә керү билгеләрен таныды.

– Ышаныгыз, сине хуҗабикәнең үз күңеленә якын кабул итүе чынлап та мине борчуга салды, – дип дәвам итте сүзен Әхмәд. – Дөнья тоткасына ия кешеләрнең илтифат күрсәтүе бик куркыныч: алар сине бүген күтәрә, ә иртәгә кайгы төпкеленә ташлый. Мин бу биләмәне тутырган гайбәтләрне колактан-колакка тапшырырга җыенмыйм, пычракта казынырга түгел, ә бөекләр шигъриятен җырларга телим. Әмма, кызганыч ки, безнең химаячебезнең күзе төшкән чибәр егетләрнең бәхетсезлегенә көнләшеп карамас идем.

– Ачыграк итеп сөйләгез, хөрмәтлем! – дип кычкырды Галим хаҗи. – Бу сүзләрегез һәм урынсыз шикләрегез белән Мөхәммәдәмин ханыбызның аксөяк сеңлесен мыскылларга теләмисездер бит?!

– Мөхәммәдәмин ханның күркәм шәхес булганлыгы турында берәү дә бәхәсләшми, урыны җәннәт түрендә булсын. Ярлы-ябагай шагыйрьләрне – кулларында каләмнән кала бернинди байлыклары булмаган хирызсыз-ваемсыз бу сабый күңелле адәмнәрне фани дөньяны калдырып киткән хаким янында шундый бәхетле итә алган сарайлар тагын күпме икән? Мин яраткан ханыбыз турында ни дә булса әйттеммени? – Әхмәд әфәнде күңелсез генә көлемсерәде, Мөхәммәдьярга карап куйды. – Ә Хәйям сүзләре синең колакка гына, егетем:

Мактаулардан оеп китмәче бер көндә, –
Тәкъдир кылычы һәрчак тора баш өстеңдә.
Дан никадәр татлы булмасын,
Язмышның агуы әзер.
Хәлвә белән сыйлап та, агуламасын!

...Шираздан килгән шагыйрь Әхмәд тагын бер мәртәбә баш иеп саубуллашты да каләм «кортлары» җыелган чатырга таба китте. Мөхәммәдьяр аны уйчан карашы белән озатып калды, ә күңеле урыныннан купкан остаз, аны көнченең сүзен тыңламаска өндәп, ялвара ук башлады:

– Алар синнән куркалар, Мөхәммәдьярым. Хуҗабикәнең игътибары, сусаган ирен яныннан тамчысын да тамызмый узып киткән шәраб касәсе сыман, ымсындырып кына калды ич аларны. Бу гөнаһкярләр безгә каршы якка бастылар әнә, күрәсеңме, чөнки без аларның барысына караганда да сәләтлерәк икәнне беләләр, шул көрәштә җиңеләселәре килми. Әлеге көнче агаеңның сүзен тыңласак, без, монннан китеп, кая барырбыз? Янчыгыбызда бер бакыр тәңкә дә юк, хурҗиннарыбыз коргаксыган, атларыбыз арык ишәккә әверелгән! Карт остазыңның сүзенә колак сал, Мөхәммәдьяр, дошман сүзенә бирешмә! – диде ул.

Хаҗиның шулкадәр кәефе кырылды ки, хәтта күзләреннән кайнар яшь атылып чыкты да бу көннәрдә ябыгып киткән йөзе буйлап тәгәрәде, моны күреп дулкынланган шәкерте йөрәгенә якын остазын тынычландырырга ашыкты:

– Без монда калырбыз, вәгъдә – иман. Сез җылы урын-җир һәм кайнар көлчәгә мохтаҗ, Сез ханбикәнең ихтирамына лаексыз. Ә мин... – Мөхәммәдьярның күзләрен уйлану томаны басты. Ул янә әлеге чатырга, Гәүһәршадның сарай шагыйрьләре тарафына карап алды. Юк, алар бу мәлдә шигърият турында бәхәсләшмиләр, фәлсәфи мәсьәләләр белән баш катырып яки иҗатларын үзара тикшерешеп маташмыйлар, ә хуҗабикәләренең чираттагы бүләген – бер табак пылауны бүлешеп яталар иде. Мөхәммәдьяр башын чайкап куйды һәм сүзен әйтеп бетерде: – Ә мин, әгәр изге Хозыр галәйһиссәлам безгә бүтән юл күрсәтмәсә, монда калырга каршы түгелмен.

...Гәүһәршад Юраучыны бик мөһим эш буенча чакырткан икән. Ул дөньяны үзе теләгән якка үзгәртергә күптән тырыша иде бит. Бүген исә, үзенең хаклыгына ышанып җитмәгәнлектән, гел кичектерә барган ниятен кичекмәстән гамәлгә ашыра башларга, дигән карарга килде. Карт нәҗембагарга, йолдызлар аңа уңыш вәгъдә итәрме икән дип сорау өчен, яшерен серләрен ачарга әлегәчә кыймаган иде ханбикә.

Картның үз дәрәҗәсен белеп, бик килештереп кенә баш иеп сәламләве Гәүһәршадны бу юлы да сагайта калды. Беркайчан өстеннән төшмәгән чапаны астындагы бетерешкән тәне алдыйдыр, ул әле яшь, куәтле ир-аттыр, шул кыяфәткә кереп кылана гынадыр кебек тоела иде. Әле дә аның башын, әлеге йолдызбагарны хәйләкәр һәм явыз дошманнары, ханбикәнең бөтен серләрен белешергә, аннары баш бирмәс бу хатыннан үч алырга, дип, астыртын эш йөртү өчен җибәрмәделәрме икән дигән курку хисе бер мизгелгә чатнатып алды. Юраучы телгә килү белән, шул шыгырдавык тавышның һәм тирән буразналар белән ергаланган чырайның ясалма түгеллеген аңлап, Гәүһәршад тирән сулыш алды. Барысын да алдан күреп әйтергә сәләтле ябык Юраучы чынлап та яшисен яшәгән, ә аның җәһәтлеге һәм җиңел генә буй сона алуы озак еллар буе иң танылган хакимнәр янында хезмәт итәргә, аларга бил бөгәргә туры килүе белән бәйле булса кирәк.

– Сезнең йолдызнамәне төгәлли яздым, хуҗабикәм, – дип, үзе сүз башлады карт, – соңгы ноктаны куяр өчен, миңа егерме бишенче ай көнен генә көтәсе бар... Тик Сез мине шуны ишетер өчен чакырмагансыздыр бит?

Ханбикә яңадан сагаеп калды, керфек тә какмыйча, аның якты, үтә күренмәле дип әйтерлек күзләренә үтеп керердәй булып, Юраучыга текәлде.

– Дөрес уйлагансыз, хөрмәтлем, Сезне мин бер мөһим эштә булышу өчен дәшкән идем...

– Сөйләп тормасагыз да була, ханым, – дип, чуалган сакалын сыпырып алды карт һәм сүзен болай дәвам итте: – Бүген төшемдә Сез миннән бер нәрсә турында сорадыгыз, имеш. Төшемдә үк аның җавабын да белдем.

Гәүһәршад, сабыры төкәнеп, йолдызбагарга карый, ә ул, юри сузып торган кебек, чапан итәгендәге сырларны төзәткән була.

Ниһаять:

– Төшегез турында сөйләгез инде, мөхтәрәм Юраучы! – дип әйтмичә түзә алмады ханбикә.

– Ул бары тик төш кенә ич, хуҗам, мин күк җисемнәренең хәрәкәтен күзәтә дә, нөҗүм гыйлеме, фал китапларын ачып карый да алмадым бит әле. Тик төшләрдә безне алда бер йолдызлык та ачып бирә алмаган ачы хакыйкать көткәне мәгълүм була. Бу җирләр күңелегезгә бик якын, ханбикә, Сезгә бөек нәсел тамырларыгыздан сихри көч килә. Әмма ул тамырлар корыган-кипкән, нәселегез ир туганнарыгыз белән

бергә үлгән. Арадан берсенең гүргә иңүе Сезне сөендерсә дә, гүзәл ханлыкны көткән фаҗигале язмышның, юкка чыгуның башы шунда булган.

– Юкка чыгумы?! – дип кычкырып куйды ханбикә. – Син ялгышмадыңмы, карт?! Шундый зур һәм көчле дәүләтнең ничек юкка чыгуы мөмкин? Бер нәсел үлсә, аңа алмаш булып, чиктән тыш куәтле Чыңгызхан канын берләштерүче дистәләгән башка хакимнәр килер!

– Алар киләчәк, әлбәттә, затлы хуҗабикә, – дип, авыр сулап дәвам итте йолдызбагар, – бер-бер артлы килерләр, ләкин берсе дә дилбегәне ныгытып тота алмас, бу фәйтунны инде туктатып булмый, аның атлары дулаган. Ни үкенеч, бөек илне афәттән берни дә саклап кала алмаячак!

– Аһ! – Гәүһәршад урындыгына сыгылып төште, учлары белән йөзен каплады. Һәлакәтне бу рәвешле алдан әйтеп кую белән, аның күз алдында җимерелгән калалар, читләрнең ат тоягы астында ыңгырашкан җир, кан елгалары пәйда булды. Әмма бер мизгелдән ханбикә инде үзен кулга алды, башын артка чөеп, гәүдәсен турайтты. – Боларның барысы да төш кенә, хөрмәтлем! Караңгы төн уртасында килеп тә, кояшның беренче нурлары белән тарала-таркала торган нәрсәгә ышанып буламы? Ханлыгыбыз башына төшкән һәм төшәсе бөтен бәла-казалар да төтен кебек таралыр, Аллаһ боерса!

Карт авыр сулап кына куйды, башын иеп ишеккә таба юнәлде, тик, тоткага кагылыр-кагылмас көе борылып карады да:

– Ә бу егетне, бөек хуҗабикә, алтын белән дә, затлы-купшы киемнәр белән дә беркем үзенә бәйләп тота алмаячак. Ул артык инсафлы һәм гөнаһсыз, күңеле ялганны, икейөзле вә нәфес колы булуны кабул итә торган Аллаһ бәндәсе түгел. Ул кыланырга, койрык болгарга җыенмый. Киң күңелле ханбикә, яз көне алтын читлектән кошларны азат иткән кебек, оланны җибәрегез, үз язмышына таба очсын ул. Бәхетсез һәм ягымлы чырай күрсәтмәс булса да, үз язмышы көтә аны.

Йолдызбагар тагын бер кат буен сонды да ишек артындагы ярым караңгылыкта, моңарчы ханбикә хозурында бөтенләй булмаган да кебек, эреп юкка чыкты. Гәүһәршад бу тәкәллефсез картлачны ачуланып өлгерә алмый калды, бары тик гаҗәпләнүдән зур булып ачылган күзләрен ачкалап-йомгалап, башын гына чайкады. Ханбикәнең, әле карт килер алдыннан гына, Мөхәммәдьярга матур киемнәр һәм алтын тәңкә тутырылган янчыкны илтеп бир, дип, сарай идарәчесенә кушуын кайдан белгән соң бу? Егет бай бүләкләргә егылып китәрме, көтмәгәндә шундый биеклеккә ирешүеннән файда күрергә омтылышы бармы-юкмы икәнен тикшереп карыйсы килгән иде. Икенче көнне иртән идарәче бөтен бүләкләрне – сүтеп-ачып та каралмаган матур итеп төрелгән киемнәрне, калтаны һәм кыйммәтле билбауны ханбикә катына алып кергәч, Юраучының хаклыгына ышанды. Яшь шагыйрь үзе исә эзсез күздән югалган булып чыкты.

Ахыры киләсе санда

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе* ■

Казан ханлыгының язмышы

Булат Хәмидуллин

ВАСИЛЬСУРСК ҺӘМ ЗӨЯ КАЛАЛАРЫ. АР КЕНӘЗЛЕГЕ БЕЛӘН ТАУ ЯГЫНЫҢ РУС ДӘҮЛӘТЕНӘ БУЙСЫНДЫРЫЛУЫ

...1550 ел башындагы уңышсыз яудан соң, Мәскәү кенәзлеге җитәкчеләре Казанга якын бер тирәдә тагын бер терәк пункт – яңа бер кальга төзергә кирәк дигән карарга киләләр. Сура елгасы тамагында, ханлыкның Тау ягының читендә төзелгән Васильсурск калачыгының Казан ханлыгына һөҗүм оештырганда зур файда китергәнлеге аларда шундый яңа шәһәрчек төзү кирәклеге дәлилли. Барлык соңгы яулар һәм һөҗүмнәр барышында Васильсурск кальгасы мәскәүлеләргә ышанычлы хезмәт итә. Өстәвенә, Казан тарафына ат-арбада җилдерткән очракта, ул ханлык башкаласыннан нибары бер атналык җирдә урнашкан була. С.М.Соловьев әлеге җәһәттән болай дип яза: *«Кенәз Василий төзегән Васильсурск күп файда китерде. Ул Казан ханлыгын яулау барышында беренче адым булды. Аның улы Иван, Свияжск кальгасын төзеп, икенче адым ясады. Өченче омтылышта инде ул Казанны яулап алды»*.

Шулай итеп, тагын бер ныгытманы Казанга якынрак урында төзергә кирәклеге турында фикер туа. Һәм шул кышта ук аны гамәлгә ашырырга керешәләр. Иделнең үрге өлешендәге Углич урманнарында булачак кала йортлары өчен буралар әзерләнә. Берничә йөз зур-зур көймәләргә төялгән гаскәр 1551 елның май башында юлга чыга. 18 майда кенәз П.С.Серебряный җитәкчелегендәге бер төркем искәрмәстән Казанга һөҗүм итә. Әлеге арада икенче төркем Зөя елгасы кушылган җирдәге бер калку урында әлеге буралардан йортлар төзеп куя. Шул рәвешле Свияжск (Зөя) кальгасы барлыкка килә. Төзелгән вакытта ул шәһәрчекнең патша исеме белән Иван-город дип аталганлыгы да мәгълүм. Һәм шунда ук зур гарнизон туплап, Казанга даими һөҗүм хәзерлеген башлап та җибәрәләр.

24 майда Зөягә Түбән Новгородтан бертөркем боярлар һәм үз кешеләре белән Шаһгали дә килә.

М.Г.Худяков Зөя кальгасын төзергә керешер алдыннан мәскәүлеләрнең Казан шәһәренә якын-тирәләрдәге барлык су юлларын, елга кичүләрен үз кулларына төшерүләре хакында яза. Шуның өчен төрле тарафтан казаклар төркеме дә китерелә. Бу эшкә Нократ елгасы буендагы арлар (удмуртлар) иле башлыгы булган Бәхтияр Зюзин кешеләре дә җәлеп ителә.

Казан ханлыгыннан төньяк-көнчыгыштарак урнашкан, башлыча удмурт халкыннан торган бер дәүләтчек XIV йөз ахырларында Нократ-Чыпца елгалары буйларында барлыкка килә. Аны мөстәкыйль бәклек (кенәзлек) буларак оештыручылар кыпчак ыругыннан чыккан Бачман хан варислары, дип фаразлана. Казан ханлыгы оешкан чорда бәклек аның йогынтысында була. *«Бу төбәкне 1489 елда Мәскәү кенәзлеге үзенә буйсындыра»*, – дип яза тарихчы Д.Мостафина. Ягъни кенәз Иван III 1487 елда Казанны яулап, ханлыкны үз йогынтысына алганнан соң, тарихта «Арское княжество» исемен йөрткән биләмәне дә Мәскәүгә буйсындырырга өлгергән икән. Д.Мостафина шуннан татарның бериш күренекле бәк-морзалары нәселләре чыкканлыгын да билгеләп уза: Арслановлар, Касыймовлар, Яушевлар һ.б. Ләкин, ни сәбәпледер, Ка-

Ахыры. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

Безнең мирас №12 декабрь 2018



Колшәриф (Шәрифкол имам). Рушан Шәмсетдинов рәсеме

зан ханлыгының соңгы ханнары вакытында бу бәклек белән якын элемтә урнаштырылмаган. Бик тырышканда аны кабат Казан йогынтысына кайтарып та булгандыр, мөгаен. Югыйсә, идарәчеләре һәм гаскәренең бер өлеше дә ханлыктагы төп ыруг вәкилләре белән бер үк телдә сөйләшкән бит. Ә төп халкы – арлар ханлык халкының бер өлешен тәшкил иткән мордва һәм мариларга гореф-гадәтләре буенча да, сөйләм теле ягыннан да кардәш халык булган. Ләкин Сафагәрәйлеләр, 40 меңлек гаскәр белән Мәскәү кенәзлегенең чик буендагы берәр шәһәрен талап кайту яуларын оештырып та, көнчыгыш күршеләренә әһәмият бирмиләр. Максат куеп, шундый ук гаскәр белән «Арлар кенәзлеге»нә яу оештырсалар, ихтимал, күптән уңышка ирешкән булырлар иде...

1551 елда Казан ханлыгы биләмәсенең камалышта калуы идарәчеләрнең таркаулыгына мисал булып тора. Әйткәнебезчә, кайбер чыганаклар 1550 елның кышындагы дошман явы вакытында ук инде Казанны башлыча шәһәр халкы һәм Кузыйчак (Кошчык углан) җитәкчелегендәге кырымлылар белән нугай гаскәри төркемнәре генә саклаганлыгын хәбәр итәләр. Дөрес, Һ.Атласи хезмәтендә бу катнаш гаскәри берәмлектә, шәһәр һәм шәһәр яны халкын да истә тотып, егерме мең чамасы сугышчы булганлыгы искәртелә. Башка административ берәмлекләрдә тупланган көчләр ни сәбәпле Казанга ярдәмгә килмәгән соң? Ни өчен алар Зөя елгасы янәшәсендәге үрдә

яңа бер шәһәрчек калкып чыгуына каршы күтәрелмәгән? Нишләп дошман көймә-корабларының Казаннан кул сузымы ераклыктагы утраучыкка үтеп керүенә юл куйганнар? Бу сорауларга бердәнбер җавап – Казан ханлыгының Сафагәрәй тарафыннан кыерсытылган күпчелек бәк һәм морзаларының «Сафа нәселе»нә үпкә саклавы һәм ил-ватанның авыр хәлендә җитәкчелекне үз кулына алырдай Булат Ширин кебек шәхесләрнең калмавы булса кирәк.

Зөя калачыгы төзелгән җәйдә үк Тау ягы халкының бер өлешенең мәскәүлеләр ягына авышканлыгы, «Иван патшага турылыклы булу турында ант иткәнлеге» мәгълүм. *«Әүвәл туплардан, мылтыклардан атып халыкны куркыталар. Аннары антка китерәләр»*, – дип теркәгәннәр елъязмачылар. «Царственная книга» язмаларына нигезләнеп, М.Г.Худяков якын арада сугышта катнашмау һәм 3 елга салым түләүдән азат ителү шарты белән иң элек Тау ягы авылларында яшәүче чуашлар (тау чирмешләре) һәм марилар шундый адымга барган, дип хәбәр итә. Әлбәттә, бу гамәлгә аларны үзләренең аксакаллары, ыруг башлыклары этәргән. Ә соңгыларына исә шул хезмәтләре өчен бүләкләр, акчалар бирелгән. *«Правительство митрополита Макария не скупилась на щедрые подкупы»*, – дип язган шул чор кешесе.

Зөя каласында шундый мөһим гамәлләр башкарылганда Казанда нәрсәләр була соң? Төрле тарафка ирекле хәрәкәт итү юллары ябылгач, Казан халкы авыр хәлдә кала, М.Г.Худяков аеруча сәүдәгәрләрнең зур зыян күрүе хакында билгеләп уза. Казан кешеләренең күпчелеге, кырымлылар идарәсеннән котылып, *«Иван патшага баш ирга, Шаһгалине ханлыкка алырга телидер иде. Кырымлылар белән ике ара нык бозылганга күрә, соңгылары үзләрен казанлыларның русларга тотып бирүеннән нык курка башлаган иде. Төннәрнең берендә кырымлылар Кошчак углан җитәкчелегендә Казаннан чыгып качты»*, – дип яза Һ.Атласи. Бу вакыйга «Царственная книга» битләрендә һ.б. чыганакларда да теркәлгән. М.Г.Худяков китабында мондый юллар бар: *«Решился на бегство 300 человек уланов, князей, азеев и мурз, оставив свои семьи в Казани»*. Ягъни аксөякләр, шул исәптән югары дәрәҗәле гаскәри түрәләр дә качып китә. Казан шәһәре дошман көчләре тарафыннан тулаем чолганып алынган булганлыктан, качкыннарның байтагы юл сагында торган казаклар тарафыннан юк ителә. Кузыйчак җитәкчелегендәге 46 кешелек төркем исә, Нократ елгасын кичеп, Кама-Чулманга чыгарга ниятләгән вакытта казаклар һәм арлар тарафыннан кулга алына. Арлар идарәчесе Зюзин аларның барысын да Мәскәүгә озата, анда кырымлыларның күпчелеге җәзалап үтерелә.

Сөембикә өчен бу гамәлләр – иң якын киңәшчеләренең чыгып качуы тирән упкынга егылып төшүгә тиң күренеш булгандыр. Аның ул вакытта нинди авыр хәлдә калганлыгын һәркем аңлыйдыр. Һ.Атласи, рус елъязмачыларының хәбәрләренә нигезләнеп: *«Кузыйчак йорт (язмышы) өчен тырышучыларның беренчесе вә шуның илә Сөенбикәнең боерыгынча эш итүче бердәнбер башлык булганлыктан, Сөенбикәнең аны башкалардан артык күрүе билгеле иде. Казан бәкләре аның Кузыйчакны артык күрүен яратмыйлар иде»*, – дип бәян итә.

Кузыйчак төркеме качып киткәннән соң, *«Казанның олуглары ханбикә янына килә һәм: «Бикә, без хәзерендә ни эшли алабыз? – дип сорый. – Без тупланып бетмәгән гаскәребез белән дошманга каршы тора алмабыз... Кузыйчак батырны хан кебек олылый идек. Ханга ышангандай аңа ышана идек. Авыр чакта аның ташлап китүе безне куркуга салды. Тәңренең язмышыннан ул ялгыз котылмакчы булды... Безгә хәзерендә синең исемеңнән Шаһгали янына килешергә барырга кирәк. Ул безгә падишаһ булып килсен, сине үзенә хатынлыкка алсын. Аның сиңа өйләнүе соткынга өйләнү кебек булмаенча, сөйкемле бикәгә өйләнү булсын. Шулай итеп аның да йөрәге тынычланыр. Бар-*

часы да килешер», – дип үгетли Казан аксөякләре Сөембикәне. Һ.Атласи хезмәтендә китерелгән бу сүзләр «История о Казанском царстве» китабының 72-73 битләрендә теркәлгән. Димәк, Казанда калган бәк-морзаларның фикере дә Урал-суның аргы ягы тирәләрендәге җәйләвендә кызының язмышы турында уйланып яткан Йосыф бәк фикеренә тәңгәл килгән.

ШАҺГАЛИ – КАЗАН ХАНЫ. ТАУ ЯГЫ ЯЗМЫШЫ. СӨЕМБИКӘНЕ ОЗАТУ. БӘЙБАРС РАСТОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘГЕ ЯШЕРЕН ТӨРКЕМ

Түбән Новгород белән Зөя кальгасы арасында ике як илчеләрен утырткан җиңел көймәләр йөреп торган; Зөя кальгасында, Мәскәү боярларыннан һәм гаскәр башлыкларыннан тыш, Шаһгали, Казанның бертөркем бәк һәм морзалары да була; Сафагәрәй исән чакта Казаннан качып киткән бәкләрдән Хөсрәү Кастров, Чапкын Отучев, Бурнаш морза һ.б., Шаһгалинең иярченнәре белән бергә 500ләп кеше, дип яза М.Г.Худяков. Алар Зөядә үз язмышлары хәл ителүен көткәннәр.

Зөя кальгасына Казанның олуг аксакаллары һәм аерым ыруг башлыклары да килгәләп йөргән. Бу очракта ханлык тәхетенә кемне сайлау кирәклеге турында уртак фикергә килергә тырышканнар. Мондагы боярларга ханлыкның Тау ягы өлешен ханлык биләмәсенә кертмәү турында Мәскәүдән инде әмерләр бирелгән була. М.Г.Худяков хәбәр итүенчә, Кузыйчак җитәкчелегендәге кырымлылар Казанны ташлап качканнан соң, ханлыкның бәк-морзаларының һәм дин әһелләренең күпчелеге Мәскәү белән солых килешүе төзү кирәклеге фикерен яклый. Әмма алар Тау ягы өлешенең ханлык биләмәсендә калырга тиешлеген дә дәгъвалыйлар. Шул сәбәпле ике арада сөйләшүләр әлегә нәтиҗәсез кала. Мондагы боярлар һәм гаскәр башлыклары ул мәсьәләне Иван патша рөхсәтен алмыйча хәл итүдән баш тарталар. 1551 елның җәендә, Казаннан Зөя кальгасына юлланган вәкилләр буларак, сәед Колшәриф, карачы бәк Нургали Ширин, Ходайкол углан һ.б. Шаһгалине Казан тәхетенә тәгаенләү турында сөйләшүләр уздыралар. Мәсьәләне хәл итү өчен, Мәскәү каласына абруйлы делегация җибәрелгән була. Шуннан рөхсәт алынгач, Шаһгали хан буларак казанлылар тарафыннан да танылa. Казанда яңа хөкүмәт (диван) оештырыла. Аңа Булат Ширин бәкнең улы Нургали, Ходайкол углан, Бәйбарс Растов бәк, сәед Колшәриф кебек дәрәҗәле шәхесләр билгеләнә.

Әлеге хөкүмәт, ханлыкны саклап калу өчен, Үтәмешгәрәй белән Сөембикәне һәм Кузыйчак углан белән качкан Кырым бәк-морзаларының гаиләләрен Мәскәүгә тапшыру таләбен үтәргә ризалык белдерә. Шул хәбәрләрне җиткерү һәм илчелек вазыйфасын үтәү өчен, Мәскәүгә Янбарс Растов морза җитәкчелегендә вәкилләр җибәрелә.

Мәскәү таләбе буенча, яңа килешү каралмасына Сафагәрәй чорында әсирлеккә алынган һәркем азат ителергә тиеш («полону русского в неволе не держати») дигән пункт та кертелә. М.Г.Худяков әсирләр язмышын ачыклауның, азат ителгәннәрне Зөя кальгасына озатып куюның яңа хөкүмәт белән Шаһгалигә йөкләнүе «Царственная книга»ның 178 нче битендә теркәлгән, дип күрсәтә.

Ханлыкның аксөякләре һәм Казан халкының күпчелеге кебек үк, Шаһгали хан да ханлыкның зур биләмәсенең – Тау ягы өлкәсенең күрше дәүләт карамагына бирелүе белән килешми. (Бу фикер шулай ук «Царственная книга»ның 179 нчы битендә теркәлгән.) Шул ук елның 9 августында Зөя кальгасында ханлыкның яңа идарәчеләре белән Мәскәү кенәзлеге боярлары арасында солых килешүен раслау буенча сөйләшүләр була. Әлеге вакыйга алдыннан гына Мәскәүдән Зөягә яңа хөкүмәт вәкиле Алексей Адашев килеп җитә. М.Г.Худяков мәгълүматлары буенча, очрашуда, казанлылардан вәкилләр буларак, Шаһгали белән бергә Бәйбарс Растов, Касыйм

мулла һ.б. катнаша. Монда да төп бәхәс шул ук Тау ягы турында бара. *(«И с боярами казанцы много говорили... (Ранее) Енбарс Растов подписал этот договор в Москве. Но послы (из Казани) с этим не согласились...»)*. Бу мәсьәләне якын арада ханлык халкы вәкилләренең гомуми җыенында хәл итәргә, шуннан соң солых килешүен расларга, дигән нәтиҗәгә киленә.

11 августта биш яшьлек Үтәмеш белән Сөембикә, Кузыйчак угланның ике баласы һ.б. әсир ителә. Казаннан Зөягә кадәр аларны яңа хөкүмәт вәкиле Бәйбарс Растов бәк белән Галимәрдән хаҗи озата бара. Казан кешеләреннән бер төркем тоткыннарны Казансу елгасы тамагына җиткәнче озатып куя. Шунда аларны зур көймәләрдә Мәскәүгә алып китүче төркем башлыгы кенәз П.С.Серебряныйга тапшыралар. Юлаучылар, бер төн Зөядә кунгач, 12 августта Түбән Новгород тарафына кузгалалар. Тоткыннарны Мәскәүгә чаклы озатып бару бурычы Кастров бәк белән искә алынган хаҗига да йөкләнгән була.

14 августка Казансуның Иделгә кушылган урынындагы җәйләүдә зур халык җыены – корылтай оештыру карала. Шаһгали белән Мәскәү вәкилләре хәзерге Бишбалта бистәсе тирәсенә кичтән үк килеп куналар. Казанлылар тарафыннан бу җыенны алып бару Мансур сәед улы Колшәриф сәедкә, хөкүмәт (диван) башлыгы Ходайкол угланга, хөкүмәт әгъзасы Нургали Ширин бәккә һәм башка ыруг вәкилләренә йөкләнә. Җыенга тупланган халык мәскәүлеләр гаскәре тарафыннан чолгап алына. Бу җыенның төп максаты ике дәүләт арасындагы солых килешүен раслау була. Башта бер бояр Мәскәү кенәзлеге тәкъдим иткән документны укып чыга. Тау ягын ханлык биләмәсеннән бүлеп алуга каршы чыгучылар күп булуга карамастан, боярлар: *«Иван патшага алла шулай эшләргә боера»,* – дип, үз сүзләреннән чигенмиләр. Халык арасыннан: җире сезгә булсын, аннан җыелган салым безгә керсен, дигән тәкъдимнәр дә яңгырый. Ләкин әлеге караш та мәскәүлеләр тарафыннан кабул ителми. *«Договор был подписан. Горная сторона отошла к Московскому государству»*, – дип төгәлли бу җәй вакыйгаларын М.Г.Худяков.

Шушы солых килешүендә Шаһгалинең хан буларак раслануы да карала. Икенче көн иртәдән үк ул, үз карамагындагы 300 татар атлысы һәм боярлар өстәп биргән 200 кешелек гаскәре озатуында, хан сараена кереп урнаша. Мәскәүдән билгеләнгән илче-вәкил И.И.Хабаров белән сак гаскәре башлыгы һәм дьяк И.Выродков та тиздән Казанга килеп төпләнәләр. Һ.Атласи мәгълүматлары буенча, Шаһгали шул көннәрдә үк Иван IVкә тугрылыклы булуы турында *«антлы ярлык язып, кенәз Юрий Голицынны Мәскәүгә җибәрә»*. Беренче көннәрдән үк Мәскәү кенәзлегенең әсирлеккә алынган кешеләре язмышын ачыклауга керешелә. Казаннан барланган 2700 әсирне хан якын арада Зөя кальгасына озата. Соңрак аларны ханлык буенча ачыклаулар башлана. Шул чорның кайбер елъязмачылары: *«Анда барлыгы 60 мең чамасы кеше тоткын хәлендә яшәгән»*, – дип хәбәр итә. Шул ук мәгълүмат «Царственная книга»ның 184-185 битләрендә дә китерелә. Әлбәттә, бу санны аклардай да, кире кагардай да язма документларның булуы шикле. Заманында Сафагәрәй хөкүмәте дә аларны исәпкә алып мәшәкатьләнмәгән. Кайбер галимнәр, шул исәптән С.Х.Алишев та, ханлыкта гомер иткән барлык халык саны да шул күрсәткечтән бер-ике дистә мәртәбәдән югарырак булмагандыр, бу дөрес сан түгел, дип дәлилләргә тырышты.

Тау ягы җирләренең идарә үзәге буларак билгеләнгән Зөя кальгасында элеккечә үк идарәче боярлар яши һәм тиешле күләмдә гаскәр тотыла. Димәк, 1551 елның җәендә Идел буйлап Казаннан 20 чакрым ераклыкта яңа чик сызыгы барлыкка килгән, дияргә мөмкин. Бу яңа өлкәнең идарәчесе һәм гаскәр башлыгы (воевода) итеп кенәз Семен Микулинский билгеләнә. Ханлыкны яуларга билгеләнгән гаскәрнең бер өлеше кире кайтып китә.

«Соңгы алыш».
Заһир Хәкимов
рәсеме

Мондый үзгәрешләр ханлыкның күпчелек халкына да, кайбер бәк-морзаларга да ошамый. Тиздән Бәйбарс Растов җитәкчелегендә яшерен төркем барлыкка килә. Алар Нугай Урдасы вәкилләре белән хатлар алышып, Шаһгали ханны тәхеттән төшерү, Мәскәүнең И.Хохлов урынына яңарак билгеләнгән вәкиле Д.Ф.Палецкийны Казаннан куу ниятен тормышка ашырырга керешә. Ләкин әлеге төркем башында төмәнле бертуган Растовларның булуы кемнәргәдер ошамаган – сер чишелгән. Шул ук елның октябре ахыры-ноябре башларында Шаһгали хан, Мәскәү вәкиле белән килешеп, 72 кешене үтертә. Берничә көн дәвамында шәһәр буйлап тентүләр үткәрелә. М.Г.Худяков: *«Үтерелүчеләр арасында Бәйбарс белән Янбарс Растовлар, Колай морза, Кадыш батыр, Карамыш углан һәм бер сәед-мулла да була»*, – дип яза. Ә кайберәүләр исә ул көннәрдә нугай далалары тарафына качып өлгерә.

Шушы вакыйгага алдыннан гына, сентябрь аенда Шаһгали Казанның иң абруйлы берничә кешесен Мәскәүгә илче итеп җибәрә. Алар арасында яңа хөкүмәт вәкиле Нургали Булат улы Ширин бәк, Шаһгалинең үз ышанычлы вәкиле Шаһбаз бәк

Шамов, Хөсрәү Кастров бәк, хөкүмәт оешмасы сәркатибе Абдулла бакши һ.б. була. Илчелек алдына Тау ягы биләмәсен ханлыкка кире кайтару мәсьәләсен чишү, һич булмаса, аннан җыелган салымны ханлык казнасына кертүне хәл итәргә тырышу төп бурыч итеп куела. Әмма Мәскәүнең идарәче боярлары, Тау ягы халкы үз теләге белән Иван IV алдында ант итеп, кенәзлеккә кушылды, дип, ул үтенечләрне гамәлгә ашырудан баш тарталар, *«царь с Горной стороны ни одной деньги не отдаст»,* дип җавап бирәләр. Ә Казандагы үтереш вакыйгаларыннан соң, Шаһгали белән Д.Ф.Палецкий Иван IVтән әлеге илчеләрне Мәскәүдә тоткарлауны таләп итәләр, *«Нургали белән Кастров та шул ук төркем кешеләре»,* дип белдерәләр.

ШАҺГАЛИ: «МӨСЕЛМАН ШӘҺӘРЕНӘ РУС ГАСКӘРЕН КЕРТӘ АЛМЫЙМ...»

Шаһгали ханның ханлык зыялыларына карата үлем чарасы куллануы, дәүләт белән идарә итүдә Мәскәүгә карап кына гамәлләр кылуы Казан халкын янә канәгатьләндерми. Аксөякләр арасында аны тәхеттән төшерергә ниятләүчеләр саны арта. Мәскәү түрәләре һәм Зөядә төпләнгән боярлар да бу вакытта Шаһгалине хан тәхетеннән төшереп, аның урынына ханлык белән идарә итүче Мәскәү кенәзлеге вәкилен – наместникны билгеләү аша мондагы киеренкелектән чыгу юлын эзли башлаган булалар. Ханлык белән шул рәвешле идарә итүгә күчүгә ризалык белдерүчеләр арасында Шаһгали тарафыннан Мәскәүгә илче итеп җибәрелгән һәм шунда тоткарланган Нургали Булат улы белән Кастров бәкләр, Галимәрдән хаҗи да, элегрәк Мәскәүгә күчеп яши башлаган башка бәк-морзалар да, Сафагәрәй чорында Мәскәүгә чыгып качкан, шуннан кайтышлый Зөядә тоткарланганнардан Чапкын Отуч бәк, Бурнаш морза һ.б. да була. Ханлыктагы идарә һәм яшәү тәртибе элеккечә калдырылган очракта идарә башында хан урынына Мәскәү кешесе утыруын хуплаучылар арасында кайбер Казан аксөякләре дә табыла.

С.Х.Алишев Мәскәүдә булган илчеләрнең һәм шунда яшәгән бәк-морзаларның шундый адымга баруын аларның кенәзлек түрәләре һәм боярлары белән аралашу нәтиҗәсендә Казан ханлыгын яулау кирәклеге турындагы фикернең өстенлек итә баруын аңлаулары, ихтимал, котылгысыз шул чараны күпмедер вакытка кичектерү ниятеннән чыгып, шулай эшләргә мәҗбүр булулары белән аңлата.

Мәскәү кенәзлеге вәкиле, Тау ягы төбәгенең яңа идарәчесе Семен Микулинскийны Казанга наместник итеп тәгаенләргә ниятләгән булалар. Шаһгалине Казан тәхетен үз теләге белән калдырып китәргә мәҗбүр итү, Микулинскийны һәм гаскәрне Казанга кертеп калдыру максаты белән янә кенәзлекнең хөкүмәт җитәкчеләреннән булган Алексей Адашев җибәрелә. Мәскәүдәге ханлык илчеләре һәм аксөякләре исә, Казан халкына үз теләкләрен белдергән хат юллап, Терегул морзаны озатып калалар. А.Ф.Адашев Казанга 1552 елның феврале урталарында килеп җитә. Иван IV исеменнән ул Шаһгалигә Казан тәхетеннән баш тартырга куша, патша хозурына кайткач, үзенә ни кирәк булса, шуны таләп итә алачагын белдерә *(«Великий князь все отдаст, что Шах Али ни похочет»)*. Шаһгали: *«Беренче тәкъдимне кабул итәм, мондый шартларда мин биредә барыбер яши алмаячакмын. Ләкин мөселман шәһәренә рус гаскәрен кертә алмыйм»,* – дип җавап бирә. С.Х.Алишев фикеренчә, мөгаен, бу очракта ул Казан халкы баш күтәрер дә, шул чуалыш барышында үзен дә үтерерләр, дип уйлагандыр. Казанны калдырып киткәндә Шаһгали кирмәндәге дарыга зыян (су) салырга, тупларны Зөя кальгасына озатырга вәгъдә биргән, дип тә язалар. 6 мартта Зөя кальгасына күченгәндә ул, хәйләләп, үзе белән Казанның 84 морзасын һәм гаскәри түрәләрне дә ияртеп чыга һәм тиздән аларны 500ләп рус стрелец-казаклары карамагына тапшыра. Шул ук Шаһгали Мәскәү түрәләренә Казан аксөякләре

тарафыннан Нугай Урдасына яңа хан эзләргә кешеләр җибәрелгәнлеген дә әйтә, дип яза С.Х.Алишев.

А.Ф.Адашев патша боерыгының бер өлешен генә башкарып чыга ала. Казан кирмәненә кенәзлек гаскәрен кертеп урнаштыру һәм тәхеткә Мәскәү вәкилен тәгаенләү чараларын гамәлгә ашырганда көтелмәгән вакыйга була. Башта, Казан халкын үгетләп күндерү өчен, калага кечерәк гаскәри сак астында ике татар казагы җибәрелә. Казан халкы, килеп туган вазгыятьне тулырак аңлату өчен, Чапкын Отыч белән Бурнаш морзаларның шәһәргә җибәрелүен үтенә, алар аңлатканнан соң яңа түрәне тану турында ант итәчәкбез, дип ышандыра. Икенче көнне шәһәргә шул морзалар белән бергә бояр И.Черемисинов та җибәрелә. Ханлык хөкүмәте вәкилләре белән кайбер аксөякләр ант итәргә әзер булганлыкларын белдерәләр. 8 мартта Бурнаш морза белән бергә Зөя кальгасына Ходайкол углан җитәкчелегендәге ханлык хөкүмәте вәкилләре дә С.Микулинскийны Казанга озата барырга дип киләләр. Шәһәрдә И.Черемисинов, Чапкын Отыч һәм мылтыклы 70 атлы казак аларны көтеп кала. 9 мартта Казан тарафына зур гаскәр кузгала. Гаскәр башлыклары И.Шереметев, Ромодановский, П.Серебряный, Казаннан килгән кунаклар һәм ике-өч көн элек Шаһгали алдап Зөягә алып килгән бәк-морзалар озатуында булачак наместник С.М.Микулинский да Казанга илтүче көймә-корабларга кереп утыралар. Бишбалтага җитеп, көймәләрдән төшкән арада берничә кеше Казан тарафына алданрак китә. Болар Чура Нарыйкның бертуганы Галикәй морза, Ислам белән Көбәк бәкләр була. Шәһәргә килеп кергәч тә алар капкаларны бикләргә боералар. Гаскәриләрне коралландырып, кирмән диварларында үз урыннарын беләргә кушалар: «*Бишбалта тарафыннан килүче гаскәргә шәһәр халкын юк итәргә боерык бирелгән. Шундый боерык булуын без андагы татар казакларыннан да, Касыйм мишәрләреннән дә ишетеп беләбез*», – дип хәбәр итәләр. Чапкын Отыч та алар сүзен хуплап, халыкны дошманга каршы көрәшергә өнди. Черемисинов белән бергә шәһәрдә калган 70 атлы казакның язмышы ачыкланмаган. С.Микулинскийны озата килгән бәк-морзаларның барысын да 12 мартта кабат Зөя кальгасына илтеп, сак астына алганлыклары билгеле. Ләкин аларның да күбесенең шуннан соңгы язмышы мәгълүм түгел.

1552 елның 9 мартыннан башлап 2 октябрь кергәнче Казанны яулау сугышы башлана.

Казан халкы баш күтәргән беренче көннәрдә үк яңа хөкүмәт оештырыла. Аның җитәкчесе, бәкләр бәге итеп Чапкын Отыч углы билгеләнә. Шул ук елдагы сугыш барышында ул һәлак була. Сәед Колшәриф белән аның чакыруы нәтиҗәсендә Нугай Урдасыннан Казан тәхетенә Ядегәр Мөхәммәд чакырып китерелә. Ядегәр – Әстерхан ханы Касыймның улы, атасы тәхеттән төшерелгәч, 1542-1550 елларда Мәскәү кенәзлегендә хезмәттә була. 1550 елның гыйнвар-февраль айларында Казанга һөҗүм вакытында Мәскәү ягыннан торып сугыша. Шуннан соң Нугай Урдасына китеп сыена. Утыз яшьләрендә ул – булачак хан төрле тарафлардан тупланган кечерәк гаскәре белән Казанга килергә чыккан була. Шул елның язында Казанга килеп кергәндә аның кул астында биш йөзләп сугышчы булганлыгы теркәлгән. Ядегәр Казанда үзен кыю сугышчы буларак таныта алган. Яуның соңгы көннәрендә әсир ителгәч, яңадан Мәскәүгә озатылган. 1553 елда чукындырылган һәм Симеон исеме белән 1565 елгача янә Мәскәү кенәзлегенә хезмәт иткән.

Казан ханлыгын 1552-1556 елларда яулау сугышы вакыйгалары күпләребезгә мәгълүм инде... Бу аяусыз сугыш барышында Казан ханлыгының бихисап халкы юк ителә... ■

ГАНИ БАЙ ХАТИРӘСЕННӘН ИСЕМДӘ КАЛГАННАРЫ

Тимерша Соловьёв[1]

Гани бай Хөсәеновны иң элек күрүем Казанда булды. Читтән килгән атаклы кеше булдыгыннан, ул көннәрдә Казанда һәркемнең агызында Гани бай иде. Ысулы җәдидчелек яки сәүдәгәрлек, йә башка бер җәһәттән һәркем аны үзенчә төрле үлчәү илә үлчи вә һәркаюсы төрлечә аның хакында сөйли иде. Аның дустлары да, дошманнары да Гани байның камил тәүфыйклы адәм икәнлегенә шөбһәләнмичә: «Гани бай гомерендә бер тамчы исерткеч эчми, тәмәке тартмый, әшәке хатын-кызлардан, кабак вә гостиницалардан ерак, кешегә каты сүз әйтми, кабахәт сүзне теленә дә алмый», – дип мактыйлар иде. Беренче күрүемнән соң минем күңелемдә дә Гани бай шул сыйфатлар илә генә урынлашып калды.

Икенче мәртәбә 1901 нче елда, май ахырларында мәрхүмне Оренбургта, үзенең йортында күрдем. (Аның бу йорты тимер юл вокзалы якынында булып, хәзерге көндә Ширинбану ханым балалары илә тора торган олуг йортның Уралга таба булган башы иде. Хәзерге зур йортның эшләнә башлануы соңрак булып, мәрхүмнең үзенә анда кереп торырга насыйп булмады.) Фатыйх әфәнде Кәримев илә барган идек. Гани бай күбрәк җон-җабага, тире-яры илә эш итүче булганга, мин аның авызыннан тире-яры, җон-җабага мәсьәләсенә вә кыргыз тормышына даир сүзләрдән башка мөһим сүзләр ишетә алмам, дип уйладым. Шулай булса да, хуҗам Әхмәт байның борадәре булдыгыннан, аның илә күрешеп чыгу нәзакәт икътизасы *(әдәплелек кушканча)* булганга, аңа сәлам биреп китим дип кергән идем. Мин фикеремдә бөтенләй ялгышканмын икән. Гани бай барып кергәч тә миңа икенче төрле тәэсир бирде. Күрешкәч, сәламәтлекләрне сорашкач, ул шундаен мөһим мәсьәләләрдә сүзгә кереште ки, тугрысы, мин хәйранга калдым. Ишетүемә күрә, укый да, яза да белми торган бер куписның агызыннан чыккан сүзләр минем ул вакытта мөселман сәүдәгәрләре хакында тоткан игътикадымны *(ышануымны)* бөтенләй җимерде. Менә аның исемдә калган сүзләре вә миңа биргән сөальләре:

Бераз утыргач, Садри әфәнде Максудов та килде. Садри әфәнде шул ел гына Казанда Учительский ышкулны бетереп чыккан, мөселманча да гыйлеме барлыгы сүзләреннән белене торган яшь учитель иде. Гани бай, Максудов фамилиясен ишетү илә, аның Һади әфәндегә кардәш түгелме идеген сорады.

– Әхмәт бай мәктәп вә мөгаллимнәргә бирә торган акчасыны әүвәлгечә биреп

[1] Тимерша Салаватулла улы Соловьёв (1875-1947) – матбагачы, журналист, «Чүкеч» журналы мөхәррире, язучы. Истәлек *«Гани бай: тәрҗемәи хәле, мәктүпләре вә аның хакында хатирәләр / Мөхәррир итүче – Борһан Шәрәф, нашире Ширинбану Хөсәенова һәм аның балалары. – Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1913»* китабыннан алынды.

барамы? Бу ел ничә мәктәп ачты? Ничә мөгаллимгә жалуния бирәсез? Мөгаллим сораучылар бармы? Булганда, табып бирә аласызмы?

Ул вакытта мин Әхмәт байның баш кантурында кассир булдыгымнан, мине бу сөальләргә җавап бирергә тиешле табып, мәрхүм миннән җавап көтеп тора иде. Ошбу очрашуымызда мосахәбә *(сөйләшү)* сәгать ярымга тартылды. Сүз фәкать уку, укыту, мәктәп-мәдрәсә тугрыларында гына булды. Шулвакыт кантурдан бер бала менеп:

– Мәхмүт Алмаев дигән кеше килгән. Казанныкы, Сезне күрмәкче була, ни әйтик? – диде. Мәрхүм:

– Алып менеңез! – дидектән соң, безгә карап: «Кем ул? Сез белмисезме ул кешене?» – диде.

Фатыйх әфәнде, Мәхмүт Алмаевның[2] мөселманча яхшы гына мәгълүматлы булуы өстенә, Истанбулда һәм Германиядә фән укып кайткан егет икәнен, яшь мөхәррирләремездән булып, киләчәктә зур өмидле бер зат улачагыны аңлатты.

Мәхмүт әфәнде керде. Гани бай үзенең һәркемгә түбәнчелегеннәнме, яхуд гыйлем ияләренә хосусый тәвазыйг *(тыйнак)* вә илтифатлы булдыгыннанмы, Мәхмүт әфәндене гаять тәгъзыйм *(хөрмәт)* илә каршы алып, самимият *(чын күңел)* илә күрештеләр. Хәл вә әхвәл сорашып, бер-берене таныштылар. Мәхмүт әфәнде Германиядәге мәктәпләрне, андагы укыту эшләренең тәртип вә ысулларыны сөйләгәндә, бигрәк тә ибтидаи мәктәпләр хакында сүз чыкканда, Гани байның зур дикъкать вә ләззәт илә тыңлап торуы, арада аңлашылмаганрак урыннарда яхуд үзенең әһәмият бирергә тиешлерәк тапкан мәсьәләләрендә кат-кат сорап, тәфсилен белергә тырышулары мине гаять тә гаҗәпкә калдырды. Бу мәҗлес миндә шулкадәр тәэсир калдырган ки, хәтта хәзер дә шул сәгатьләр хәтеремдә. Шул мәҗлес бу көн күргән шикелле күз алдымда тора.

Шунда Фатыйх әфәнде Мәхмүт әфәнденең язма шигырьләрен үзеннән сорап алып, берничәсене укыдылар вә бәгъзеләре хакында мөхакәмәләр (хөкем) ясадылар. «Казан бае бик суфый», дия башланган шигырьне тәмамынача дикъкать илә тыңлагач, Гани бай моны йәнә бер мәртәбә укып чыгуны үтенде. Бу шигырьнең тәмамы шөйләдер:

«Казан бае бик суфый,
Көн дә биш намаз укый.
Ашыйдыр «адәм ите»,
Унике сәгать йокы.
Бәгъзесе бигрәк тә бай,
Мәскәү малы тай да тай,
Акчасына да юк сай.
Гыйлем, мәгърифәт бик сай.
Мәскәүдән йөз мең алгач,
Аны кесәгә салгач,
Ул да ун меңгә калгач,
Кыладыр ул барып хаҗ.

Тимерша Соловьёв

[2] Алмаев Мәхмүт Садретдин улы (1874-1907) – шагыйрь, журналист, полиграфия белгече. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлый, Истанбулда укый, Германиядә полиграфия эшенә өйрәнә.

Мәккәне зиярәт кыла,
Яман эштән тыела.
Акча беткәч юк сила –
Төн-көне гамәл кыла.
    Мондый суфыйлар бик күп,
    Сурәтләре дә бик хуп –
    Озын җилән «мисле поп»,
    Ак бүрек һәм такыр лоб.
Моннан да яхшы бармы?
Начар йиргә һич басмый,
Кавын орлыгын ярмый...
Йөз меңнән хәбәр бармы?
    Бер уч печәнгә фәтва сорый,
    Башына чалма урый...
    Бән сүзне сөйлим тугры –
    Бунлардыр беренче угры.
Битен юса да көн дә биш,
Эш һәп[3] кешене тәфтиш...
Кеше тәфтиш булдымы эш?
«Адәм емә[4]», ат итен ешь.
    Ак бүрек миңа нипочём,
    Юк исә, синдә һич ум...
    Акчаң улса да йөз мең сум,
    Колак асмам сиңа, и, кум!»

Русиядә мөселманнар барлыкны мөнәсәбәт чыккан саен белгертеп торучы Садри әфәнде Максудовның Дәүләт Думасы кеби гали бер урында мөкатдәс мөнбәргә менеп, нотыклар сөйләрлек кеше булып йитешүенә Гани бай Хөсәенов һәм сәбәпче булды. Дәрт биреп, дәрман бирде.

«Бер уч печәнгә фәтва сорый» дигән мисрагка *(шигырь юлы)* йиткәч, моннан морад нәрсә булдыгыны истифсар итте *(тулы аңлатуны сорады)*. Шул шигырьнең хәзрәтләр хакында булган каты сүзләрен йомшартырга рәҗа итте:

– Максудыңны белгерт, әйт, аңгарт, әмма йомшаклык илә. Каты әйтмә, рәнҗетмә, – дия, бераз сүзләр бәян итте.

Мәҗлестән таралдык. Мәхмүт әфәнде дә үзенең бу кешегә исе китеп чыкканлыкны сөйләде.

Өч-дүрт көннән соң, йәнә мәрхүмнең өендә булдык. Мәхмүт әфәнде, Фатыйх әфәнделәр бар иде. Бераз утыргач, Садри әфәнде Максудов та килде. Садри әфәнде шул ел гына Казанда Учительский ышкулны бетереп чыккан, мөселманча да гыйлеме барлыгы сүзләреннән беленә торган яшь учитель иде. Гани бай, Максудов фамилиясен ишетү илә, аның Һади әфәндегә кардәш түгелме идеген сорады. Аның борадәре идеге хакында җавап алгач, Һади әфәнде хакында бераз сүз булды. Мәрхүм аны белә икән, аның илә таныш икән. Аның «Мөгаллим әүвәл» нам әлифба китабын бастырырга беркадәр (хәтеремдә калмаган, 500-700 сумнар чамасында иде) иганә биргән икән.

Сүзләр һаман әлифба, «Мөгаллим әүвәл», тәҗвид, уку, язу, укыту тәртипләре хакында бара. Әйтерсең, бу мәҗлес мәгариф нәзарәтенең ибтидаи мәктәпләрне ислах комитетымыни.

Мәрхүмнең сүзләреннән «Мөгаллим әүвәл» һәм башка мәктәп вә дәрес китаплары хакында яхшы мәгълүматы барлыгы беленеп тора иде. Һади әфәнде Максудины, киләчәктә татар педагогларыннан улачак, дия ышанып сөйләвене мин әле дә оныта алмыйм.

[3] Һәп – барлык.
[4] Емә – ашама.



В.В.Радлов

Мәрхүм, шул мәҗлестә миңа карап:

– Тимерша әфәнде! Сез учительләрдән бугай, Радловның[5] татарча, татар мәктәпләренә махсус һәндәсә *(геометрия)* һәм татарча уку китаплары («Белек» нам *(исемле)* кыйраәт китабы улса кирәк) бар. Сезнеңчә шул китаплар ничек? Сез аларны ничек табасыз? Алар безнең мәктәпләргә ярарлыклармы? – дия сорады.

Мин бераз уңайсызланып киттем. Ул китапларны күргән булсам да, анларны тикшерү, алар хакында тәнкыйть ясау вә тәкъдир итүгә йитәрлек мәгълүматым булмаганга, ихласы илә белер өчен сораган Гани байның сөальләренә җавап бирә алмыйча аптырап калдым. Бер учительнең бер сәүдәгәргә каршы нинди мәсьәләдә мөшкеллеккә төшүене исәпләп, тирән уйга киттем.

Хәтереңездә булсын ки, бу вакыйга 1901 сәнәдә иде. Ул вакытта атаклы күп мөгаллим вә мөдәррисләремезнең дә ысулы тәгълим хакында вә мәзкүр китаплар тугрысында махсус бер фикергә малик *(ия)* булмаулары һәркемнең мәгълүмедер.

Мәҗлестә Радлов әсәрләре вә башка дәрес китаплары хакында байтак сүзләрдән соң аңлашылды ки, Гани байның иң зур кайгысы – мөгаллимлеккә йитешкән мөгаллимнәремезнең юклыгы, шуңа чаралар эзләү вә шул максуд илә Каргалы шәһәрендә ачылган мувәкъкать *(вакытлы)* мөгаллимнәр курсы эшләрендә иде. Бу мөгаллимнәр курсыны барып күрергә мине дә димләде. Иртәгесен Мәхмүт әфәнде вә Гани бай – өчемез бергә Каргалыга бардык. Курста мөгаллимнәр, шәкертләр күп. Иҗтиһад илә укыганлыклары беленә. Монда мөгаллимнәрдән дә бигрәк зур иҗтиһад вә ләззәт илә дәртләнеп йөрүчеләрнең берсе Гани бай иде.

Каргалыдан кайтышлый, Гани бай Садри әфәнде хакында сүз кузгатты. Аның йәнә укырга вә мәгълүматын арттырырга теләдеген Фатыйх әфәндедән нәкыль итеп сөйләде. Садри әфәнденең дәртле булуына Гани байның да кәефе килгәнлек шундагы сүзләреннән аңлашыла иде.

– Мин булышлык кылам. Дәрте бар икән, укысын. Русчасы да, мөселманчасы да яхшы булса, ике канатлы булыр, – дия, үзенә бер ләззәт илә сөйли һәм бер гали эш эшләнәчәгенә шатлана иде.

Русиядә мөселманнар барлыкны мөнәсәбәт чыккан саен белгертеп торучы Садри әфәнде Максудовның Дәүләт Думасы кеби гали бер урында мөкатдәс мөнбәргә менеп, нотыклар сөйләрлек кеше булып йитешүенә Гани бай Хөсәенов һәм сәбәпче булды. Дәрт биреп, дәрман бирде.

Казан, 1912 сәнә, июнь 5.

*Текстны басмага **Җәүдәт Миңнуллин** һәм **Рәйсә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

[5] Радлов – Василий Васильевич (Фридрих Вельгельм) Радлов (1837-1918), шәркыятьче, тюрколог, этнограф, тәрҗемәче, академик.

Әнкара хокук мәктәбенең тарихи әһәмияте

Садри Максуди

Садри Максуди хәзерге көндә татар һәм төрек халкын берләштерүче интеллектуаль күпер булып санала. 1918 елда туган җиреннән китәргә мәҗбүр булган милләттәшебез Төркиядә мәшһүр профессор, хокук тарихы буенча китаплар авторы, Төркия Бөек Милләт Мәҗлесенең вәкиле, җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе булып таныла.

1923 елда Ататөрек, яңа Төркия Җөмһүрияте корганнан соң, иҗтимагый, сәяси, икъгисади, хокукый һәм мәдәни реформалар үткәрә, 1925 елның 5 ноябрендә Әнкарада Хокук мәктәбен ача. Әлеге мәктәпне ачуның асыл максаты – иске хокукый нормалардан ваз кичү һәм яңа хокук системасын булдыру. С.Максуди, Төркия Җөмһүриятенең беренче Президенты Ататөрекнең чакыруы буенча бу мәктәптә укытыр өчен, Парижда җайланган тормышын калдырып, гаиләсе белән Әнкарага күченә.

Хокук – милләтнең тормыш фәлсәфәсе.

Татар галиме Әнкара Хокук мәктәбендә, соңрак, 1925-1943 елларда Анка-

Әнкара Хокук мәктәбенең беренче мөгаллимнәре. Беренче рәттә сулдан икенче – Садри Максуди, өченче – Йосыф Акчура. 1925 ел

ра университетына әйләнгән әлеге уку йортында, 1943-1955 елларда Истанбул университетында төрек хокукы тарихы, төрки халыкларда хокук, Рим хокукы буенча дәресләр бирә. Аның Аурупа архивларында, китапханәләрендә булган материалларга нигезләнеп язылган «Hukuk tarihi dersleri» (Хокук тарихы дәресләре, 1927), «Türk hukuku tarihi» (Төрек хокукы тарихы, 1928), «Hukukun umumi esasları» (Хокукның гомуми нигезләре, 1937), «Umumi hukuk tarihi» (Гомуми хокук тарихы, 1941), «Hukuk felsefesi tarihi» (Хокук фәлсәфәсе тарихы, 1946), «Türk tarihi ve hukuk» (Төрек тарихы һәм хокук, 1947) исемле китаплары хәзерге көндә дә белгечләргә мәгълүм, соңгысы хәтта 2014 елда янәдән нәшер ителә. Хокук өлкәсендә башкарган эшләре, фәнни мирасы белән Садри Максуди Төркиядә, гомумән, төрки дөньяда дәрәҗәле урын алып тора.

Мөҗәддиднең карашлары бөтен халыкның, хәтта кайчак бөтен бер чорның да хәят фәлсәфәсенә әверелә. Милләт рухындагы ошбу үзгәрештән яңа хәят кагыйдәләре туа. Башкача әйткәндә, яңа хокук барлыкка килә.

Игътибарыгызга мөхтәрәм галимнең 1925 елны «Hakimiyet-i Milliye» («Милли хакимият») газетасында хокук мәктәбе ачылышы, аның Төркия һәм төрки дөнья өчен әһәмияте турында басылган мәкаләсен төрек теленнән тәрҗемә итеп тәкъдим итәбез.

Миләүшә Гайнанова

Хокук – формалашып җиткән кешелек җәмгыятенең хәят кагыйдәләре җыелмасыдыр. Кешелек хәятендә һәрнәрсә кебек хокук та даими рәвештә баскыч арты баскыч үзгәреп тора.

Хокукның мондый яңарыш вә үзгәреше хокукның нигезен тәшкил иткән хәят фәлсәфәсенең үзгәрүеннән килеп чыга. Һәр милләтнең хокук системасы шул милләтнең тормыш фәлсәфәсеннән илһам алып барлыкка килә. Шуңа күрә, хәят фәлсәфәсе үзгәргән чакта хокукый система да үзгәрә. Бер милләтнең рухында хәяткә карашның үзгәреше ни дәрәҗәдә төпле, тирән булса, ул милләтнең хокукы да шул нисбәттә җитди һәм колачлы үзгәреш кичерә. Милләтләрнең хәяткә карашы, фәлсәфәсе үзгәрү исә һәрвакыт шул милләтләрдә мөҗәддидләр (реформатор) үсеп чыккан чорга туры килә.

Милләт эчендә калкып чыккан даһи мөҗәддидләр милләтнең хәяткә карашына тәэсир итә. Алар, иске караш һәм фикерләү рәвеше урынына, яңа карашлар торгыза. Бер кешелек җәмгыятенең хәятенә тәэсир иткән даһи мөҗәддидләргә, яшәгән чорларына һәм мохитләренә карап, төрле исемнәр бирелә: хәким, каһарман, пәйгамбәр, реформатор.

Исемнәре нинди булуга карамастан, милләтләрнең хәятендә мөҗәддидләрнең роле бер үк: ул да булса, бер милләтнең, бер мохитнең тормыш фәлсәфәсен үзгәртүдән гыйбарәт.

Мөҗәддидләр – бер кешелек җәмгыяте, бер халык, бер милләт эчендә яңа хәят фәлсәфәсе урнаштыручылар. Алар яңа хәят фәлсәфәсе элементларын мохиттән, милләттән алалар. Даһи мөҗәддид бөтен милләт фәрдләренең күңелендә әле аңсыз, беленер-беленмәс кенә тырпылдап яткан теләк-омтылыш вә хис үзгәрешләрен тәгаен бер фикерләү рәвеше һәм яңа бер хәят аңлаешы итеп формалаштыра. Соңыннан, зирәклеге һәм көчле шәхси сыйфатлары ярдәмендә, бу яңа карашларны халык арасында җәелдерүгә ирешә.

Мөҗәддид тараткан фикерләрдә халык үзенең яшерен теләк-омтылышларының анык белдерелешен тапканга, мөҗәддиднең карашлары бөтен халыкның, хәтта кайчак

бөтен бер чорның да хәят фәлсәфәсенә әверелә. Милләт рухындагы ошбу үзгәрештән яңа хәят кагыйдәләре туа. Башкача әйткәндә, яңа хокук барлыкка килә.

Төркия хәятендә бүген барган үзгәрешләр – төрек кавеме тарихында тиңе булмаган бер инкыйлабтыр. Ләкин бу инкыйлаб соңгы гасырларда гареб мәмләкәтләрендә булган инкыйлабларның берсенә дә охшамаган. Безнең төрек инкыйлабы Бөек француз ихтилялы кебек саф сәяси инкыйлаб та, соңгы Русия инкыйлабы кебек икътисади вә иҗтимагый ихтилял да түгел.

Төрек инкыйлабы эчендә бөек вә мөһим бер сәяси үзгәреш тә бар. Икътисади ислахат (реформалар) һәм яңарыш – инкыйлабыбызның олуг максатларыннан берсе. Ләкин безнең инкыйлаб сәяси һәм икътисади сыйфатлары белән генә бөтен асылын ачыклау мөмкин булган бер инкыйлаб түгел. Бездә төрек инкыйлабы, ихтилял булудан бигрәк, гомуми бер милли яңарыштыр.

Төркиядә булган һәм әле дә дәвам иткән инкыйлабны мин шушы рәвешле тәгъбир итәр идем: төрек инкыйлабы – бер яктан, төрек кавеменең хәятен вә киләчәген куркыныч астына куйган факторларны һәм төрекнең бәхетле вә җитеш тормышта яшәвенә комачаулаган манигъларны алып ташлау булса, икенче яктан, тузган, яшәү куәте сүрелгән нигезләргә корылган шәрык милләтләре оясыннан чыгып, хәятен замана таләпләренә муафыйк итеп корган мәдәниятле бер гареб милләтенә әверелү юлларын тәэмин итүдән гыйбарәт.

Бөтен милли хәрәкәтебезнең төп фәлсәфәсе, рухы, өлгесе – шушы яңа максаттыр. Бу яңа максатны да ике сүз белән әйтеп бирергә була: төрекчелек һәм гаребчелек.

Милләтпәрвәр юлбашчыларыбызның бөтен сәясәт һәм хәрәкәтләрен шушы ике принцип белән аңлатып бирергә мөмкин. Төрек милләтеннән мәдәниятле бер гареб милләте ясарга телибез. Бер үк вакытта гаребнең барлык мәдәни мөәссәсәләрен кабул итәбез. Мөстәкыйльлеккә ирешү, җөмһүрият төзү безнең юлбашчылар өчен иң ахыргы максат түгел иде. Мөстәкыйльлек һәм җөмһүрият җитәкчеләребез күзаллаган бөек яңарыш һәм ислахат өчен кирәкле зарури бер җирлек иде. Бүген, рәһбәребезнең даһи акылы, могҗизави тырышлыгы һәм бик тә кирәкле казанышлары нәтиҗәсендә, күздә тотылган ислахат вә реформалар өчен уңайлы шартлар булдырылды.

Бүген халкын төрекләр тәшкил иткән, тулысынча мөстәкыйль бер төрек җөмһүрияте бар. Төрекләрнең мәнфәгатьләрен кайгырткан бер хөкүмәт, төрекчелекне сәясәтенең асылы итеп алган бер идарә бар.

Бу форсаттан файдаланып, бүген юлбашчыларыбыз, җиң сызганып, милли хәятебезне яңарту эшенә керештеләр. Һәм бу хәрәкәт торган саен көчәя һәм киңәя генә бара. Бүген Төркиядә башка бер милләтнең ни матди, ни мәгънәви ярдәменә мөрәҗәгать итмичә, һәр өлкәдә реформалар ясала. Берничә тимер юлының бервакытта салынуын; авыл кешесенең икътисади тормышына мөһим уңайлыклар кертелүен; экспортыбызның үсә баруын; сәламәтлек саклау өлкәсенең нәтиҗәле эшен; Мәгариф Вәкаләтенең мәктәпләрне күбәйтү, мәктәп программаларын миллиләштерү, телебезне өйрәнү өчен Академия кору тырышлыкларын, Аурупадан мөгаллим вә мөдәррисләр җәлеп итүен, көтебханәләр салынуны; Гадлия Вәкаләтенең (Юстиция министрлыгы) кануннарыбызны яңарту һәм мәҗәлләләр (канун китаплары) төзү хосусындагы башлангычларын; идарә эшләрендә бюрократиядән котылу омтылышларын һәм, гомумән, икътисад, авыл хуҗалыгы, мәгариф, юстиция һәм финанс эшләрендәге җанлылыкны күреп, кайсы гына тарафсыз күзәтүче куанып тойгыланмас? Кайсы төрекнең күңеле җилкенмәс? Куәтле дошманнар белән чолгап алынган төрек милләте, бөтен каршылыкларга карамастан, көч вә илһамны бары үз дәһасыннан алып, яшәү һәм үсеш юлында искиткеч тырышлык куя. Шул ук вакытта яңа хәятенең нигез

Әнкара Хокук мәктәбенең беренче укучылары

ташларын, төрек кавеменең тәрәккый итүен бер дә теләмәгән гареб мәмләкәтләренең яшәешеннән ала.

Бер милләтнең яшәү һәм үсеш көрәшенең бу кадәр колачлы һәм аңлы дәрәҗәгә җитүе җиһан тарихында бик сирәк очрый, дисәм, арттыру булмас.

Бөтен җиһанның күз алдында, даһи бер юлбашчының идарәсе астында, зәгыйфь бер шәрык милләтеннән мәдәни бер гареб милләте ясала. Төрек милләте һәрьяклап яңарыш чоры кичерә. Катгый рәвештә ышанып әйтәмен: милли хәрәкәтебезнең гәүдәләнеше, милләтнең һәр мәсьәләдә юл күрсәтүчесе, кавемебезнең рәисе җиһан тарихында бер ихтилялчы итеп түгел, ә бер кавемнең бөек мөҗәддиде буларак искә алыначак.

Хөкүмәтебезнең ислахат хәрәкәте нәтиҗәсендә, Төркиядә яңа хокук системасы корылырга тора. Бу хокук бик күп яклары белән иске хокукыбыздан аерылып торачак. Әлеге аермаларның иң мөһимнәре шулар.

Иске хокукыбызның чыганагы гарәп ислам хокукы иде. Дини ноктаи назар (концепция) бу хокукның үлчәве һәм төп критерие иде. Дини ноктаи назар мәдәни хокукта (гражданское право) гына түгел, хәтта әсас кануннарда да хакимлек итә иде.

Хәлбуки яңа хокукыбызның илһам чыганагы исә – бер яктан, төрекчелек, икенче яктан, гаребчелектер. Милләт Мәҗлесенең алты еллык эше, вәкаләтләрдә (министрлыкларда) әзерләнеп яткан ислахат программалары – һәммәсе дә әлеге төп идеяләрдән чыга, бу чыганаклардан илһам ала.

Инкыйлабның кызу активлыгы чорында милләт мәнфәгатьләрен тирәннән тоеп эшләнгән яңа хокукыбызның милли, фәлсәфи, иҗтимагый әсаслары бар.

Хокукыбызның шушы гыйльми әсасларын билгеләү һәм яктырту өчен, мәмләкәт өр-яңа рух белән җанланган бер гыйлем мөәссәсәсенә мохтаҗ иде. Хөкүмәт, бу мөһим ихтыяҗны игътибарга алып, яңа хокукыбызны өйрәнү өчен махсус бер зур мөәссәсә кора. Бу мөәссәсә – Әнкарада төзелгән Хокук мәктәбедер. Бу мәктәпнең тарихи вазыйфасы гаять зур. Ул хокук хезмәткәрләре әзерли торган гади бер уку йорты гына


TÜRKİYE CÜMHURİYETİ

Ankara Hukuk Fakültesi mezuniyet diploması

Ankara Hukuk Fakültesinde okunan derslerden imtihanları neticesinde Pek eyi derecede mezuniyete liyakat kespeden Kıbrısta doğmuş Hüseyin Cahit Beye devletin kanun ve nizamlarının tanıdığı haklardan istifade etmek üzere bu diploma verilmiştir. 20.1.1928

Fakülte reisi V. Adliye vekili

Diploma No 1

Ahmet İhsan matbaası

Хокук мәктәбен тәмамлау турындагы таныклык

түгел. Бу мәктәп җөмһүрият нигезләрен фәнни сурәттә формалаштыру вазыйфасын үз өстенә алган бер югары гыйлем мөәссәсәсе.

Әнкара Хокук мәктәбенең вазыйфасы, хокук хезмәткәрләре чыгарудан бигрәк, бүгенге идарә системабызның, инкыйлабның, җөмһүриятебезнең әсасларын билгеләү һәм бу әсасларны фәнни яктан яктырта алган зыялы һәм аңлы җөмһүрият хокукчылары әзерләү булачак.

Әлеге мәктәптән чыккан хокукчылар, җөмһүрият һәм миллият дәверенең яңа голәмасы булу белән беррәттән, төрекчелек һәм гаребчелеккә нигезләнгән яңа иҗтимагый хәят кануннарыбызның нашир (җәелдерүче) вә мөфәссирләре (аңлатучылар) булачаклар.

Төркиядә инкыйлабтан яңа хокук туачагы табигый булган кебек, бу яңа хокукны укыту өчен яңа рухлы бер мөәссәсә төзү кирәклеге дә аермачык иде.

Шәрыктагы төрек йортларында Ислам дине таралу нәтиҗәсендә Ислам фикһы хаким булганнан соң, Ислам мәдрәсәләре салынды. Мөселман төрекләр эчендә яңа иҗтимагый хәят ысулын, яңа фикһны укыткан төрек мөдәррис вә фәкыйһләре җитеште. Бүгенге яңарыш та мәйданга яңа хәят кагыйдәләре, яңа бер фикһ чыгарачак.

Бу яңа иҗтимагый хәят ысулларын, бу яңа фикһны укыту һәм тәртипкә салу өчен, Әнкара Хокук мәктәбе корыла.

Әнкара Хокук мәктәбен кору – бик тә вакытлы эшләнгән мөһим бер гамәлдер. Аның яңарыш тарихыбызда, башка гали мәктәпләр белән бергә, зур роль уйнаячагы шөбһәсездер.

Maksudi S. Ankara Hukuk Mektebinin tarihî ehemmiyeti // Hakimiyet-i Milliye. 1925. 14 Eylül.

*Текстны төрек теленнән Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты **Миләүшә Гайнанова** тәрҗемә итте.* ■

АЧЛЫКТАН СОҢ ТАТАРСТАН АВЫЛЛАРЫ

Рәүф Сабиров

Кече Чынлы авылында саламнан төзелгән хуҗалык корылмасы

Хөрмәтле укучылар! Күренекле дәүләт эшлеклесе, 1921-1924 елларда Татарстан Үзәк башкарма комитеты президиумы рәисе булып эшләгән Рәүф Әхмәт улы Сабировның 1923 елда республикабызның Спас һәм Буа кантоннарына барып, андагы икътисади, мәдәни хәлне өйрәнеп язган «Ачлыктан соң Татарстан авыллары» исемле китабы нигезендә әзерләнгән мәкаләләр циклын тәмамлыйбыз. Китапны тулысынча www.beznenmiras.ru сайтыннан укырга мөмкин булачак.

Редакция

Ахыры. Башы журналның 2018 елгы 10 санында.

АВЫЛДА СОВЕТ ЭШЛӘРЕ

Сирәк кенә булса да фәкыйрь авылларда Авыл Советлары, авылның бөтен эшен үзләре алып барып, бик артык мөһим булган салым салу, җир бүлү кебек эшләрдә генә җыен җыеп эш кылалар. Мондый Советлардан Шәйморза авылы советын күрсәтергә мөмкин. Бу Советның рәисе – яхшы укый-яза белүче партия әгъзасы, өч еллык ыстажы бар, халык каршында игътибары зур. Авыл гаять зур булганлыктан, эш ифрат күп, кәнсәләриядә ике язучы бар. Берсе – сайланып куелган сәркатип, икенчесе – ялланган эш йөртүче. Эш татар телендә йөртелә. Бөтен дәфтәрләре русча кулланмалардан карап татарчага әйләндерелгән. Авыл Советы каршында ячейка төзелеп, аның сәркатибе урынын шул ук рәис алып бара. Комиссия өчен кирәкле булган әллә никадәр материалларны безгә бик аз вакыт эчендә табып бирделәр. Авылның хуҗалыгы төрле груһларга бүленеп, әллә нинди хәлдә булганын, хәзерге көндә ничек көн иткәнен дәфтәрләрдән карап кына белергә кала. Ачлыктан үлүчеләр, кайткан качаклар, чәчелмәгән җирләр турында аеырм-аерым дәфтәрләр дә сакланып, кирәк вакытта табуны бик җиңеләйткәннәр.

Фотолар http://drogganoye.tatarstan.ru сайтыннан алынды

Кече Чынлы авылында тавык лапасы

Авыл Советларының эшенә зарар итүче тагы бернәрсә булса, ул да әле күп волостьларда татар теленең гамәлгә ашып бетмәве. Рәтләп тел белмәгән, язуын үзе генә таный торган авыл рәисе һәм сәркатипләренә русча эш алып бару, хөкүмәтнең карарларын русчадан татарчага күчерү гаять авырга туры килә. Шуның өчен дә эшләрен русча йөртүче татар авылларында Совет эшләре зәгыйфь куелган.

ВОЛОСТЬЛАРДА ТАТАР ТЕЛЕ

Татар телен гамәлгә кую турысында сүз чыккач ук безгә бик күп иптәшләр: «Бу декретлар гамәлгә ашачак түгел, бездә кеше юк, көч юк», – диләр иде. Чынлап та тел турындагы декрет озак вакытлар гамәлгә аша алмый торды, ләкин аның сәбәбе кеше юклык түгел, бәлки Татарстан өстенә килгән бөек һәлакәт сәбәпле башларның башка

эш белән мәшгуль булуы, ул хакта күп уйларга вакыт җитмәү иде. Аз гына сулу алу белән, эшкә керешелде. Тел комиссиясе үзенең нигез кагыйдәләреннән итеп татар телен түбәндәге хөкүмәт оешмаларыннан башлап гамәлгә куюны алды. Хәзер эшләрнең барышы бу нигезнең чиктән тыш дөрес булганын күрсәтә. Без ике волостьта татар теле куелышын карадык.

Волость аппаратлары бөтенләй татардан җыелган. Бөтен эшләр татарчага күчерелеп беткән. Авыллар һәм кайбер кантон отделениеләре белән ике арада язу йөртү фәкать татар телендә генә бара. Кантонның кайбер бүлекләрендә татарча белүчеләр булмаганга күрә, әле кәгазьләрнең кайберләре урыс телендә языла, ләкин алар бик сирәк була. Бу волостьлар эшчеләрне мәркәздән дә, кантоннардан да алмаганнар, алар – шул ук авыллардан чыккан, элек авылларда сәркатип булып торган яисә волостьта берәр җирдә эшләгән иптәшләр.

Әле, билгеле, җитешмәгән җирләр күп очрый. Никадәр яхшы, тырыш эшчеләр булсалар да аппаратта эшләүче иптәшләрнең техник ягыннан җитешсезлекләре бар. Вакыты белән акрынлап аларның һәммәсен курслар аркылы үткәрергә, алар урынына курс бетергән иптәшләрне җибәреп торырга кирәк булачак[1].

Кәнсәләрия дәфтәрләренең тулы булмавы, язу машинкасы кулланмау вә башка нәрсәләрнең җитешмәве эшкә зарар итә, ләкин болар бара торган эшне туктатырлык зур кимчелек түгел, һәммәсе – вакыты белән бетереләчәк нәрсәләр.

Безгә бу ике волостьның һәр икесендә комиссиягә кирәк булган бөтен белешмә сведительстволарны бик тиз бер вакыт эчендә бирә алдылар. Бу волостьларда эшчеләрнең аз вакыт эшләгән яшь эшчеләр икәнлекләрен дә хәтерләсәк, чыннан да татар телендә эш кую инде түбәндә җайга салына башлап, акрынлап аны үзебезнең югарырак катлауда, түрәләр күбрәк урыннарда да гамәлгә ашырырга вакыт җиткәнен белдерергә мөмкин булачак.

Бу волостьларның авыл арасында игътибарлары артык яхшы.

АВЫЛЛАРДА МӘГАРИФ ЭШЛӘРЕНЕҢ КУЕЛЫШЫ

Иң элек авыл мәктәпләренең тышкы хәлләренә килсәк, монда рус мәктәпләре белән татарныкылар арасында зур аерма табыла һәм рус авылында мәктәпкә махсус салынган бина булып, аның эчендә мәктәпкә кирәк булган бөтен әсбап, парталар, өстәлләр, ысчут һәм хариталар – бар да мөкәммәл диярлек. Һәр мәктәпнең кечкенә генә булса да көтебханәсе булып, анда уку китаплары һәм әсбаплары саклана һәм мәктәпнең янында кечкенә генә урында яшелчә утыртылып, җәен урыс укытучысының балалар белән шөгыльләнгәнлеге күренеп тора. Әмма татар авылларында эш бөтенләй башкача, без караган һәр авылда бишәр-алтышар, кайберләрендә тугызар данә мәчет булса да (мәсәлән, Чынлы һәм Шәйморза авылларында), мәктәпкә махсус салынган бер генә бина да юк[2]. Элек вакытта мәчет янына салынып куелган, муллаларның ат сараена охшашлырак «мәптекләр» булганнар да, инде аларның берсенең дә тәрәзә борыслары, ишекләре, түшәм сайгаклары калмый ягылып беткән. Бик күбесенең түбәләрен дә куптарып ягып бетергәннәр. Шулай ук мәктәптә махсус һичбер төрле әсбап та юк, кечкенә 4-5 кеше торырлык йортның сәкесен куптарып алганнар да, балалар шунда тезләнеп укыйлар. Кара такта урынына эстинага бер аршын чамасы калай кадаклаганнар. Өйгә шуннан башка һичбер төрле үзгәреш кермәгән. Мәктәпләрнең бик күбесе

---

[1] Рәүф Сабиров: «Татарстан Җөмһүрияте игълан ителгәнгә өч ел тулу бәйрәме көненә татар телен гамәлгә кую курслары 100 кеше чыгарды һәм хәзердә бу курсларда 200ләп курсант укып ята», – дип яза.

[2] Рәүф Сабиров: «Чынлы авылында 9 мәчет, 22 рухани бар, Шәйморзада – 6 мәчет, бер чиркәү, 16 рухани, Гусихада – бер чиркәү, 5 рухани бар», – дип билгеләп үтә.

китапханәсез һәм бер данә китапсыз. Тик кайберәүләрнең генә гади авыл йортында махсус шүрлек, ышкафларда берничә дистә «Беренче уку» һәм хисап китаплары бар.

Менә мәктәпләрнең тышкы гомум күренеше шуннан гыйбарәт. Хәзер мәктәпләрнең сан җәһәтләренә килсәк, монда да һәр авылда 50 процент бала хөкүмәт тәгаен иткән мәктәпләргә керми калачак. Бу эштә кайбер авылларда үзләре һәм укытучыларның иҗтиһадлары белән мәктәпләрнең санын арттырырга чаралар күргәннәр. Җанбакты һәм Ижбарскин авыллары укытучы сорап мөрәҗәгать иткәннәр, ләкин күп авылларда саннары 10-15кә җитмәгән руханиларны туйдырып ятудан авырсынмасалар да, берничә укытучыны тәрбияләргә, авылга бер-ике җүнле мәктәп торгызырга көчләре җитми. Табигый, авылның гомумән авыр хәлләр кичергәнен хәтердә тотып, бүген үк зур мәктәп торгызу, укытучыларның һәммәсен халыкның үз өстенә йөкләү мөмкин түгел. Хөкүмәт бу турыда зур ярдәмгә килергә, элек бөтенләй укудан мәхрүм яткан татар авылларына уку китаплары, мәктәп әсбаплары җитештерү, яхшы укытучылар хәзерләү эшен дәвам иттерергә тиеш булыр, ләкин халыкка үзенә бу хакта ныграк төшендереп, җитешмәгән җирләрен җиткерешергә, тулмаган урыннарын тутырышырга кирәк булыр. Һәр авылның укытучысы кантон калаларында укытучылар өчен ачылган сәяси курсларга киткәнлектән, без караган вакытларда мәктәпләрдә укытучыларны сирәк очратырга туры килде.

ЭШ МӘКТӘБЕНӘ ХАЛЫКНЫҢ КАРАШЫ

18-19 нчы елларны мин мәгариф органнарында эшләгәндә халыкның эш мәктәпләренә нинди яман күз белән караганын, аларга фәннең кешелек дөньясы өчен никадәр кирәклеген төшендерергә күпме көч сарыф итәргә тиеш булганын ачык белә идем. Теге вакытларда авыл каршында нигез мәсьәлә булып торган эш мәктәбен ачаргамы-юкмы мәсьәләләре хәл ителгән. Эш мәктәбе кирәк. Хәзер шул ачылган мәктәпкә нинди юллар белән һәм никадәр ярдәм тиеш, дигән мәсьәлә генә төрле авылларда төрлечә хәл ителеп ята. Монда да мөһим рольне авыл укытучысы уйнаячак. Укытучы үзе сәяси яхшы хәзерләнгән, тырыш, үз эшен җан күңеленнән сөюче булса, халык белән аралашып, алар өчен чит кеше булып калмыйча, илнең иҗтимагый тормышына катнашучы, сәяси аң җәһәтеннән алда торучы җәмәгатьнең бер әгъзасы булу сыйфаты белән кирәк киңәшләрне биреп торучы булса, эш мәктәпләрен аякка бастыруда күп хезмәтләр күрсәтә алачак. Мондый укытучыларны без Чынлы һәм Шәйморза авылларында очраттык. Бу волостьларда эш мәктәбенә караш халыкта тагы да яхшырак. Мәктәпләр утын белән тәэмин ителгәннәр. Вак-төяк кирәк-яракларын карап торырга да вәгъдәләр алганнар.

АВЫЛЛАРДА ДИН МӘКТӘПЛӘРЕ ЮК

Үткән кыш бер авылда да рәсми рәвештә дин мәктәпләре ачылмаган, ләкин һәр авылдан бер илче ходатайлар илә чыгып, волостьлардан башлап мәркәз комитетка, хәтта кайберләре Мәскәүгә, иптәш Калинин янына кадәр барып җиткәннәр. Мәсәлән, Шәйморза авылында безгә Мәскәүгә илче булып барган кешене тәкъдим иттеләр. Шунысы бигрәк кызганыч ки, бу иптәш – 30-35 яшьләр чамасындагы, Кызыл фронтларда йөреп кайткан, укый-яза белүче крәстиән. Ул Татарстан Халык комиссарлары советын һәм башкарма комитетларыннан да уңай җавап ала алмагач, Мәскәүгә барып, иптәш Калинин янына кергән. «Мәскәүдә дин мәктәпләре күп, ачык гөрләтеп укытып яталар, безгә рөхсәт итегез, дип әйттем», – ди. Җавапны халыкка бик томанлы итеп төшендергән. «Әле ул мәсьәлә хәл ителеп бетмәгән, дип әйтте иптәш Калинин», – дип сөйләгән.

Табигый, идән асты мәктәпләренә, «дини тәгълим бирүче» көчләргә каршы иң әүвәл эш мәктәбе көчләрен ныграк оештырырга, мәктәп тышындагы балалар санын азайтырга, бөтен чараларны күрергә кирәк булачак. Шуның белән бергә, авылның яшь буынын кызылармеецлар белән аралаштырып, партиянең бу эштә көчле егетләрен хезмәткә җигәргә, хөкүмәтнең дин турындагы декретына яхшырак рәвештә төшендерергә кирәк булачак.

ЗУРЛАРНЫ УКЫТУ ҺӘМ УКУ ЙОРТЛАРЫ

Авылның 50 процент кадәр балалары мәктәпкә кереп бетә алмыйча урамда калган бер вакытта зурларны укыту турында уйлау авыррак эш[3]. Ләкин авылның яшүсмерләре, кызыл казармаларда укый башлап, гыйлем вә фәннең тәмен сизеп кайткан кызыл гаскәриләр мәктәп сорыйлар. Һәр авылда яшьләрнең теләкләре: «Безгә китап булсын иде, безне дә укытсалар иде, гәзит булсын иде», – дигән сүзләрдән гыйбарәт.

Авылны бу хәлгә китерү партиягә һәм совет хөкүмәтенә кыйммәткә төште. Авылның якын киләчәктә илне үз кулына алырга хәзерләнә торган, чын советчы игенчеләр сыйныфы төзергә хәзерләнә торган катлавын игътибарсыз калдыру да уңай түгел. Шуның өчен монда бик уйлап эш итәргә кирәк булачак. Зурларны укыту эшен иң башлап үзе ихтыяр иткән авыллардан башларга кирәк булыр. Бу вакытта авылның шул ук укырга омтылучы яшьрәкләренең катнашы буенча уку түгәрәкләре төзеп, илнең үзеннән беркадәр ярдәм алырга, аннан соң инде авылның укытучысыннан һәм, мөмкин табылганда, махсус китерелгән укытучылардан кичке укулар башларга мөмкин булачак. Зурларны укыту эшен авыл йортлары белән дә бик нык бәйләргә кирәк. Хәзерге көндә авылларда уку йортлары һәм көтебханә исемендәге берникадәр йортлар очрый, ләкин ныграк тикшереп карый башлагач, аларның эчендә берничә дистә китап белән ярым өмми *(укый-яза белмәүче. – Ред.)* бер мөдирдән башка нәрсә табылмый. Мондый зәгыйфь ярым-йорты куелган көтебханәләр тирәсенә, табигый, халык җыеп булмый, аның бөтен укучысы 20-25 кеше булып, алар инде бар китапны әллә ничә кат укып чыккан булалар. Шуның өчен авылларда уку йортларын ачканда чынлап та уку йорты төсле итеп ачып, аның мөдирен мөмкин кадәр аңлырак кешеләрдән сайларга һәм шул ук иптәшкә кичекмичә курслар эшен тапшырырга кирәк.

Мин монда татар эшчеләренең азлыгын, бар яктан җитеш татар уку йортлары ачу читенлеген беләм. Шунда да тырышып эзләгәндә кешеләр табарга, уйлап эшләгәндә уку йортларын китап белән тәэмин итәргә мөмкин булыр, дип уйлыйм. Хәзерендә авылда мәгариф эше хакында уйлаганда, бигрәк тә шул ике эшкә, ягъни нинди генә юллар белән булса да мәктәпләр санын күбәйтеп, аларны китап һәм укытучылар белән тәэмин итеп, аннан кала инде зурлар өчен уку-язу белмәүчелек мәктәпләре һәм кыраәтханәләр *(уку йортлары. – Ред.)* ачарга әһәмият бирергә кирәк. Театр, халык йорты ачу кебек эшләргә хәзер көчне артык ватмаска кирәк. Иң элек нигезне нык салырга, аннан соң бина төзү хакында уйларга. Авылда исә әле бу нигезне ныгытып җиткерү өчен күп көч сарыф итәргә тиеш булачак.

Текстны басмага ***Ленар Гобәйдуллин*** *һәм* ***Рәйсә Шәрәфиева*** *әзерләде.* ■

[3] Рәүф Сабиров: «Авылларда ыстатистика төзегәндә укый-яза беләсеңме, дигәнсөальгә: «Беләм!» – дип җавап бирүче крәстиәннәрнең, аеруча хатыннарның, бөтенләй өмми булганы беленде. Без югарыда мәчет янына салып куйган иске мәктәпләрнең биналары җимерелгәнне сөйләп үткән идек. Аларның йортлары гына түгел, биргән җимешләре дә тәмам җимерелеп беткән диярлек була. Кайчандыр бервакыт укый-яза алучы агайлар хәзерге көндә чын мәгънәсе белән өмми хәлгә килгәндер», – дип яза.

ЭЧКЕН ТАТАРЛАРЫ

Рафаил Исакаев

ПЕЧӘН ӨСТЕ

Болыннар чәчәктә, чикерткәләр сайрый, бал кортлары нектар һәм серкә җыя.

Печән чабу – авыр булса да, күңелле эш. Карт бабам, үзе генә белгән билгеләр буенча, печәнгә төшү көнен билгели.

Ирләр иртә таңнан, чык күтәрелгәнче, җилкәләренә чалгы салып, болынга чыгалар. Карт бабам, дога кылып, Аллаһтан хәер-рәхмәтенә ирештерүне сорый һәм беренче пакуска тотына. Аның артыннан уллары китә. Чабылган үләнне тигез матур рәтләргә салып, чалгылар чыңлый. Чалгылар үтми башласа, аларны янавыч белән үткенлиләр.

Менә чабучылар арды – якындагы каенлыкка әйрән белән сусауларын басарга, үтмәсләнгән чалгыларын таптарга киттеләр. Азрак ял иткәч, чабучылар яңадан бо-

Ахыры. Башы журналның 7 нче (2018) санында.

лынга чыктылар. Кояш торган саен югарырак күтәрелде, торган саен эссерәк була барды – чык парга әйләнде. Коры үләнне чабуы авырлашты – чалгылар тиз үтмәссезләнде, аларны еш янарга туры килде, чалгычылардан тир елга булып акты. Карт бабам бирешә башлады, ул арада төшке аш вакыты да җитте. Хатын-кызлар туклыклы ризык – зур кисәкле ит белән токмач ашы пешергәннәр. Печән чабучыларга авыр хезмәт вакытында көч-куәт кертер өчен, алдагы көнне тәкә суйганнар иде. Карт бабам итне гадел итеп бүлгәч, хатын-кызлар ашны тәлинкәләргә салдылар. Ирләр, ашка катык салып болгатып, дога укып ашый башладылар. Аштан соң төрле тәм-том белән чәй эчтеләр. Калганнар – хатын-кызлар белән малайлар ирләрдән соң утырып ашадылар.

Печәнне күп чабарга туры килде, чөнки карт бабамның гаиләсе терлекне күп асрый иде.

Кояшлы матур һава торганга, чабылган печән өч көндә кипте. Печән җыярга бөтенесе – олысы да, кечесе дә чыкты. Хатын-кызлар печәнне күчләргә җыйды, малайлар аны атлар җигелгән чүмәлә тарттыргычка салды, аннары яшүсмерләр белән бер тәҗрибәле ир билгеләнгән урында эскертләргә өйде. Кышка җитәрлек печән әзерләнгәнче, эш шулай кайнап торды.

УРАК

Авылда азрак ял һәм менә игенченең иң кайнар эш вакыты – урак өсте җитте. Август башында уҗым бодае өлгерде. Бу вакытта, 8 яшькәчә балалардан һәм картлардан кала, кырга бөтен гаилә чыга. Бөртекнең өлгереп җитүен белер өчен, карт бабам башакны өзеп алып, бөртекне тешләп карый. Әгәр бөртек ярым каты булса, игенне урып-җыярга мөмкин. Бу юлы да шулай булып чыкты. Бөртек көлтәләрдә өлгереп җитә. Димәк, иртәгә уракка төшәргә мөмкин, ди карт бабам.

Быел бөртек тулышкан, яхшы уңыш көтелә. Тамырдагы бодай белән арыш – ул әле уңыш түгел. Уңыш исә – иген, җыеп алынып, келәткә салыну. Ә моның өчен зур хезмәт куярга туры килә. Урыпҗыю вакытында тагын кояшлы көннәр кирәк.

Узган ел көзге игеннән 3 дисәтинә бодай белән 2 дисәтинә арыш чәчелгән. Арыш бераз иртәрәк өлгерде, шуңа күрә урып-җыюны аннан башладылар.

Карт бабам гаиләсе иртән кырга чыкты, дога кылганнан соң, борынгыдан килгән гадәт буенча, җир рухын мәрхәмәтлеләндерү өчен, кыр читенә бербөтен ипи белән башка ризыклар куеп калдыралар.

Гаилә башлыгы, урак алып, биек арыш сабакларын урып, беренче көлтә ясый һәм аны иген басуы читенә куя. Шуннан соң уллары, кызлары һәм киленнәре тотына. Эш кайный: ирләр арыш сабакларын ура, хатын-кызлар, аларны җыеп, көлтә итеп бәйли. Басу күз алдында үзгәреш кичерә, анда көлтә рәтләре тезелеп китә. Арыш сабаклары буталып бетмәсен өчен, җил уңаена уралар. Көлтәләр, 15-16шарлап, чүмәлә итеп куела.

Игенне урып бетергәч, көлтәләрне, юеш булса, әвенгә куялар,

киптерергә кирәкмәсә, ындырга ташып, суга башлаганчы, эскерткә өеп саклыйлар. Көзге игенне урып җыйгач, пар җирләренә көзге культуралар – арыш белән бодай чәчәләр. Чәчкәндә, элекке йола буенча, тубалга орлык белән бергә йомырка («орлык күкәе») куела. (Бу йоланың максаты турында алдарак язып үткән идек инде.) Гадәттә көзен 2-3 дисәтинә арыш һәм 5-6 дисәтинә бодай чәчелә. Һәрвакыттагыча, малайлар җирне чәчүгә кадәр дә, чәчкәч тә тырмалыйлар.

Август азагында чират сабан бодаена җитә. Көннәр кояшлы торса, урып-җыю 20 сентябрьгә төгәлләнә. Яңгырлар китсә, ул октябрь ахырына хәтле дә сузылырга мөмкин. Соңгы кишәрлекне урганда басу читендә «җир рухы» өчен бер бәйләм башак калдырыла. Ул «җир сакалы» дип атала. Игенне суга башлаганчы, язын яңадан чәчәр өчен, җир туңга сөрелә.

Туңга сөрүне октябрь урталары җиткәнче тәмамлыйлар. Ничек кенә армасыннар, «безнең» гаилә әгъзаларын игенче өчен иң мөһим эш – көлтә сугу көтә.

Шома һәм каты булсын өчен, ындырда башта мәйданчык чистартып тигезләделәр. Быел көлтәләрне киптерергә туры килмәде.

Көлтәләрне бик гади эш коралы – чабагач тәпәче белән суктыралар. Ул ашлык суктыручының иягенә кадәрле озынлыктагы таяктан (бу – сап) һәм аңа күн каеш белән беркетелгән аршын буе (0,71м) икенче таяктан (монысы – суктыргыч) гыйбарәт. Корал эшли, оста мактана, дисәләр дә, аның белән эшли белә торган җитез һәм маһир, көчле ир кирәк. Мәсәлән, өлкән ул башакларга минутына 30 тапкыр сугарга өлгерә. Әгәр 10 сәгать эшләсәң, бу авыр эш коралы белән 20 мең мәртәбә сугарга кирәк. Моны ашлык суктыручының нинди авыр хезмәт башкаруын күз алдына китерү өчен әйтүем. Башак тирәсеннән суккалый башлап, бәйләвеч турысына, аннары көлтәнең төбенә күчәләр. Шуннан соң көлтәне әйләндереп, икенче ягын суктыралар. Көлтә юешрәк булса, бу берничә тапкыр кабатлана.

Беренче суктыруда иң яхшы бөртекләр алына. Көлтәләрне, чишеп, әйләндерәләр һәм озын тешле тырма белән тарап, бөртекләрен коялар да саламын күче белән күтәреп алып китәләр. Иген бөртекләрен читкә эттереп күчкә өяләр дә икенче көлтәне салалар. Соңгы көлтәне суктырып бетергәнче шулай дәвам итә.

Хәзер инде бөртекне кибәктән аеру өчен, ашлыкны җилгәрергә кирәк. Ул болай эшләнә: күчтәге игенне агач көрәк белән сосып, җилгә каршы өскә чөяләр. Җил салам кисәкләрен һәм кибәкне, җиңел булганга, читкә очырта. Эре авыр бөртекләр күчкә, кечерәкләре исә азрак читкәрәк төшә. Иң җиңел бөртекләрне яңадан җилгәреп, чүп үләннәреннән аералар. Монысы терлек азыгына китә.

Менә игенне урып җыюдагы иң соңгы хезмәт – ашлыкны суктыру тәмамланды. Бик яхшы уңыш алынды, ул гаилә ихтыяҗын артыгы белән канәгатьләндерергә җитәчәк. Карт бабамның гаиләсе аны, әчкеннәр йоласы буенча, «ындыр боткасы» пешереп билгеләп үтте. Аның белән игенне суктыруда катнашкан бөтен кешене сыйладылар. «Ындыр боткасы» соңгы көлтәләрдән суктырылган бөртекләрдән пешерелде.

Йола боткасын ашагач, авылга кайтырга җыена башладылар. Кирәк-яраклар төялгән кәрван иртән юлга кузгалды. Җәйләүдә терлек-туар өчен әзерләнгән азык (печән, салам, фураж), кыш чыгарлык утын калды. Аларны, чана юлы төшкәч, кирәк булган саен алып кайтачаклар.

Авылда инде хатын-кызлар бәйрәм сыйлары әзерләде. Күрешү шатлыклы һәм җылы булды. Ниһаять, бөтен гаилә бергә җыелды. Мунча ягылган, ризыклар әзерләнгән, буза кайнатылган, җыеп әйткәндә, зур бәйрәм, ял, аннан соң терлек-туар карауга кагылышлы эшләр көтә. Карт бабам гаиләсендә быел сөенечле вакыйга – Нигъмәтулланы өйләндерү көтелә. Аңа 20 яшь тулды – менә дигән кияү.

ТУЙ

Ел уңдырышлы булды, бу иген сатудан гаиләнең еллык чыгымнарына һәм туй ясарга җитәрлек керем алырга мөмкинлек бирде.

Кияү белән кәләшнең эти-әниләре күптән инде быел көзен туй ясарга килештеләр. Хәзер аны эчкеннәр йоласы кушканча үткәрергә кирәк. Туйны уздыру тәртибен Р.Г.Мөхәммәтованың «Татары-мишары» («Мишәр татарлары») дигән китабында сурәтләнгәнчә китерәм.

Гаилә кору йоласы кәләшнең эти-әнисенә башкода («бәен кода») җибәрүдән башлана. Ул кияүнең туганнары арасыннан иң хөрмәтле кеше буларак сайлап алына. Урын тәкъдим иткәч, башкода, димләү уңышлы булсын өчен, астына бүреген салып утыра һәм кияүне мактый башлый, зур калым вәгъдә итә. Ниһаять, кызның этисе, «туганнар белән киңәшербез», дип әйтә.

Туганнар бу никахны хупласа, ризалык билгесе итеп, сөлге җибәрәләр. Кыз, шул мизгелдән башлап, ярәшелгән («билгеләнгән кыз») санала башлый.

Калым күләмен билгеләү («кызны калымга салу») кәләш йортында үткәрелә. Кияү ягыннан башкода, егетнең этисе һәм ике өлкән туганы катнаша. Алар яулыкка төрелгән ипи-тоз алып киләләр. Киленнең этисе каршы алырга чыга. Кунакларны кәләш әзерләгән эскәтер җәелгән өстәл янына утырталар, аңа алып килгән ипи һәм тоз куела. Сөйләшүләр башлана. Калым – акчадан, урын-җирдән, кием-салымнан, кәләш өчен аяк киеменнән һәм туйга кирәкле азык-төлектән тора. Кияүнең этисе калым акчасының бар өлешен ипи өстенә куя.

Калымның күләмен килешкәч, кияүнең өендә калым туплый, ә кәләшнекендә бирнә әзерли башлыйлар.

Тиешле нәрсәләр җыелгач, кияүнең этисе кәләшнең эти-әнисенә башкода аша фәлән көнне фәлән санлы кунаклар «Ярәш»кә йоласына (калым түләү хөрмәтенә үткәрелә торган бәйрәмгә) киләчәген хәбәр итә. Кунаклар тиешле калымны сандыкка салып китерәләр. Калымны тапшыргач, кунакларны өстәл янына чакырып, чәй, салма, ботка һәм карын мае белән сыйлыйлар. «Ярәш» йоласы вакытында кәләш, башын бөркәнчек белән каплап, дус кызлары белән башка бүлмәдә утыра. Биредә «кыз күрендерү» – кәләшне карау йоласы үтәлә. Кияүнең туганнары кәләш янына кереп, аның йөзен ачып карый һәм бүләк бирә.

Ә кияүнең булачак каенанасы, ирләр кебек үк, кәләш янына керми, ә аны үзенең өлкән килене – җиңги аша гына сәламли. Моның өчен ул чынаяктагы чәйгә балдак (алтын яки көмеш) сала. Кәләш исә, чәйне эчеп, балдакны алырга һәм булачак каенанасына дигән бүләген (сөлге яки күкрәкчә) куеп, чынаякны кире кайтарырга тиеш.

«Кыз күрендерү» йоласын үтәгәннән соң, кәләш бүләкләре (кыз бирнәсе) өләшенә: кияүнең бүләк алган һәр туганы подноска акча куя.

Безнең Нигъмәтулла белән дә шулай булды. Бу кичне кәләш Сабираның йортына иптәшләре белән Нигъмәтулла килә. Кәләшнең җиңгиенә бүләкләр биреп, алар кызлар янына керергә рөхсәт алалар. Кияүнең иптәшләре кызлар күңелен күргән арада Нигъмәтулла кәләш белән бергә булу мөмкинлеге ала.

Шуннан соң «кыз киче» була, ул «чыбылдык тегү» – кәләш караватын каплау чаршавын тегү йоласыннан башлана. Кәләшнең кыз туганнары аны «кыз ярәшү»дән бирле ялгыз калдырмыйлар. Алар кәләш янында ул ата-ана йортыннан киткәнче булалар.

«Кыз киче»ннән соң, Нигъмәтулла белән Сабираның никахын рәсмиләштерү – никах туе була. Тантана, гадәттәгечә, пәнҗешәмбе көнне башлана. Туй көнендә кияүнең туганнары бергә җыелып, кәләш йортына юл тоталар. «Туй поезды» 10 олау тәшкил итә. ■

М.Мәһдиев. 1960 нчы еллар башы

Мөхәммәт Мәһдиев *мәкаләләре*

Татарстан Республикасының халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиев 1947-1960 елларда Арча районы мәктәпләрендә укытканда һәм аннан соң Казан дәүләт университеты аспирантурасында укыганда, әлеге мәртәбәле уку йортында студентларга белем биргән чорда хәзерге «Арча хәбәрләре» газетасының (ул елларда «Яңа тормыш», «Коммунизмга») хәбәрчесе була, укучыларны мәктәп тормышы һәм район тарихындагы кызыклы вакыйгалар белән даими таныштырып бара. Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкаләләр «Яңа тормыш» газетасыннан алынды. Арча районы тарихындагы күп кенә актуаль мәсьәләләр, берничә дистә ел торгынлыктан соң беренче мәртәбә, тарихчы галимнәрдән шактый алдарак М.Мәһдиевнең менә шушы кыска гына мәкаләләрендә яктыртыла.

СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ?

(Арча районы авылларының тарихы турында)

1877 елда археологларның Казанда булган VI съездында галим И.А.Износков Мамадыш өязе авыллары турында доклад белән чыккан. Докладта авыл исемнәренең каян алынганлыгы, һәр авылның милли составы, Мамадыштан ераклыгы, халкының саны күрсәтелгән. Сеҗе авылы рәсми документларда Мурья Мусич исемендә йөртелгән. Сикертән авылының исеме Сикерткә исемле чокырга-уйсулыкка урнашканлыктан килеп чыккан дип аңлатыла. Анда барлыгы – 382 ир кеше, 349 хатын-кыз исәпләнгән. Яңа Чүриле авылы шәһәрдән (Мамадыштан) 102 чакрым, милләте – руслар, диелә докладта. Халкы 1860 елда, җир җитмәгәннән, Казан өязенең Чүриле авылыннан (хәзерге Иске Чүриле) һәм Лаеш өязенең Ключище авылыннан күчеп утырган.

Чөмә-Елга авылында 1877 елда ирләр – 320, хатын-кызлар 323 кеше исәпләнгән. Гөберчәк, Казаклар, Иске Му авылларының шәһәрдән ераклыгы 110 чакрым дип күрсәтелгән.

Нәкъ әнә шул авыллар рәтендә, Кесмәс елгасы буенда, шәһәрдән 111 чакрым ераклыкта Күкчә авылы булганлыгы күренә. Бу авыл 8-9 йортлы гына булса кирәк, ирләр саны – 20, хатын-кызлар 23 кеше исәпләнгән. Кесмәс буендагы Сикертән, яки Му елгасы буендагы Гөберчәк һәм Казаклар тирәсендә урнашкан бу авыл хәзер юк. Ул кайда булган? Кайсы авылга кушылган? Хәзергә билгесез. Шунысы характерлы: Гөберчәк авылының Казаклар авылына чыга торган урам башы халык телендә Күкчә урамы дип йөртелә. Ул тирәдә яшәүчеләрне авылның картлары әле дә «күкчәләр» дип атыйлар. Моның теге, билгесез Күкчә авылына бәйләнеше булуы мөмкин, дип уйлар-

га нигез бар. Бәлки ул кечкенә авыл Гөберчәккә күчеп килгәндер дә, шул әлеге Күкчә урамына урнашкандыр?..

1962 ел

ПИОНЕР ОЕШМАСЫ ТАРИХЫННАН

Пионерлар өчен татар телендә Мәскәүдә чыгарылган «Октябрь баласы» журналының 1932 елгы 11, 12 нче саннарында Казанбаш мәктәбе пионер оешмасының эше яктыртылган. Казанбаш пионерларының мәктәптәге, колхоздагы, гомуми торактагы көнкүрешенә журнал үзенең алты битен багышлаган. Сәхифәдә алдынгы пионерлар Фазилә Камалиева, Мансур Надршин, Зариф Солтанов, Идрис Ибәтуллинның рәсемнәре бирелгән. Шулай ук бер биттә хәзерге көнне дә шул мәктәптә эшләүче Фатыйма апа Бакиеваның да рәсеме бар. Көтек башлангыч мәктәбе мөдире Фәйзерахманова Мәхтүрә ул вакытта алдынгы пионер булган. «Сәләхиев Рамазан һәм Фәйзерахманова Мәхтүрә – иң алдынгы ударниклар», – диелә журналда. Сәхифәдә пионерларның үз мәкаләләре, хәтта бик матур гына «Кыштыр-мыштыр Мәхмүт» дигән билгесез бер пионерның шигыре дә бирелгән.

Сәхифәнең журналга урнашу тарихы түбәндәгечә: 1927-1932 елларда Мәскәүдә чыгарылган бу журналның редакторы Муса Җәлил булган. 1932 елның октябрендә Муса Җәлил Казанга килә. 29 октябрьдә балалар хәбәрчеләренең киңәшмәсе җыела һәм анда шагыйрь доклад белән чыга. Киңәшмәдә «Октябрь баласы»на Татарстан мәктәпләреннән бер мәктәпнең тормышын яктырту кирәклеге әйтелә. Казанбаш мәктәбе сайлап алына. Муса Җәлил, материал туплау өчен, «Октябрь баласы»ның күчмә редакциясен оештыра һәм ул редакция Казанбашка бара. Моның составында шагыйрь үзе дә булмаганмы? Журналда исемнәре язылган пионерлар бәлки моны ачыкларга ярдәм итәрләр?

1962 ел

АРЧА КРЕПОСТЕ ТАРИХЫННАН

Арча поселогының хәзерге почта бүлеге урнашкан тирәдәрәк тау кырыендагы иске агач башняны олы яшьтәге кешеләр хәтерлиләр әле. Ләкин ул башняның тарихы бик эчкәрегә, берничә йөз елларга китә.

Элек Арча крепосте, гомумән, җирдән эшләнгән вал белән уратылып алынган булган. Валның ике ягы тирән чокыр һәм Казанка яры белән чикләнгән. Менә шул вал өстендә, тарихчы С.М.Шпилевскийның язуына караганда, 7 башня булган. Алар нык итеп агачтан корылып, мылтыктан атар өчен «бойница»лары да булган. XX гасыр башына, билгеле, ул башнялар җимерелеп, валның да эзе югалган. Тик урыны калган бер башняны гына Казан университеты каршындагы Тарих, этнография һәм археология җәмгыяте реставрацияләргә карар биргән. 1900 елның җәендә шул максат белән җәмгыятьнең действительный члены В.Борисов килгән. Бу вакытта иске башня тәмам җимерелеп, бүрәнәләр өеме хәлендә булган. Башняны ремонтлау өчен Арчадагы һөнәрчеләрне файдаланганнар. Башня эчендә һөнәрчеләр балчыкка күмелеп калган ат, сарык, дуңгыз сөякләре, балык калдыклары, көл һәм күмер тапканнар. Шулай ук бер данә Казан ханлыгы акчасы һәм тимер пычак та чыккан.

Башня элекке хәленә кайтарылган, ләкин инде аның бүрәнәләре бик иске булган. Шулай да аны карап тору эше шәһәр старостасы Н.П.Щелкинга йөкләнгән.

Галим В.Борисов исә шул елның 27 октябрендә җәмгыятьнең гомуми җыелышында Арча крепостеның башнясы турында доклад ясаган.

1962 ел

Арткы планда – Арча шәһәрлеге урыны. Казансу аша салынган күпердә – кантон милициясе рәисе урынбасары Ю.Вацик һәм Г.Бәширов (уңда). 1927 ел

«КОЛХОЗДА БИК ЯХШЫ!»

1931 елның 15 ноябрендә «Авангард» (Кәче) колхозында чит ил кунаклары була. Делегация составында Америка Кушма Штатларыннан машинист Томас Остен, эшче Джонс Гейс, Көньяк Африкадан тегүче хатын Иона Корнелиус, Австриядән металлист Герорд, ирландияле Силлиэс һ.б. кунаклар булганнар. Алар колхозның балалар бакчасы, мәктәп, мастерскойлар белән танышалар. Бакча балалары делегация хөрмәтенә концерт бирә. Авыл тормышы белән танышкан кунаклар «Авангард» колхозчыларына:

– Сезнең киләчәк өметле, – диләр.

Ә америкалы Джон Гейс инде машинага утырганда, озата килүче колхозчыларга карап:

– Колхозда бик яхшы! – дип елмая.

«МОХТАР КАРТНЫ ЮЛДА ОЧРАТТЫМ...»

Бу юллар безнең кайсыбызга гына таныш түгел икән?! Югары Курса авылы кешеләренең кайберсе күңелләргә сеңгән Мохтар карт образын турыдан-туры үз колхозларына бәйлиләр:

– Шагыйрь Һади Такташ анда безнең колхозны күздә тота, – диләр.

Бәлки болай дип әйтүгә берәр нигез бардыр?..

Һ. Такташның «Киләчәккә хатлар» әсәре 1930-1931 елларда язылып, шагыйрьнең кинәт үлеме аркасында тәмамланмыйча калган.

1931 елның 17 февралендә Казанда Татарстан Советларының IX съезды ачыла. «Киләчәккә хатлар»ның беренчесен язып бетергән шагыйрь әлеге съездда катнаша. Ул анда шигырь белән чыгыш ясый. Съезд трибунасыннан укыган шигыре соңыннан икенче хатның соңгы өлеше булып формалаша.

Съездда «Батыр Курса» колхозыннан карт ударник Хәбибулла Мохтаров та була. Съездның президиум составында да Мохтаров фамилиясе күренә. Гомумән, бабай съезд барган көннәрдә игътибар үзәгендә булган. «60 яшьлек ударник Хәбибулла бабай Мохтаров», дип аның матбугатта рәсемнәре дә чыккан, исеме дә бик күп телгә алынган. Кеше белән уртак телне тиз таба торган Такташ бу карт белән сөйләшкәндер. Аннан соң, бу

«Казан арты» тарих-этнография музее фондында Арча шәһәрлегеннән табылган археология материаллары

көннәрдә шагыйрьнең нәкъ икенче хат өстендә эшләве дә билгеле. Яңа совет кешесенең психологиясен өйрәнүдә съездда халык белән аралашуы аңа бик нык ярдәм иткән.

Ихтимал, шагыйрь белән «махра борып» сөйләшкән Мохтар картның прототибы нәкъ шул ударник бабай булгандыр? Курса авылы кешеләренең: «Мохтар карт безнең авылныкы ул», – дип әйтүләре, бәлки, шуңа бәйледер?

1962 ел

АВЫЛ ИСЕМНӘРЕ КАЯН АЛЫНГАН?

Без еш кына бер үк исемдәге авылның төрле районнарда кабатлануын беләбез. Ул гына да түгел, бер үк тирәдә, ләкин бер-берсеннән урманы, елгасы һ. б. табигый шартлары белән бөтенләй аерым булган авыллар бер үк исем белән аталалар. Чыпчык, Бимәр авыллары – Биектау районында да, Мәтәскә – Теләче районында, Казиле Татарстанның бик күп районнарында бар.

Татарстанның элегрәк төзелгән картасын өйрәнгәндә анда күп кенә урында Кармыш исемле авылларны очратырга була. Кайберләре үзләренең исемнәрен әле дә саклаганнар (Норлат, Чистай якларында); Саба, Арча районнарында исә бу исемнәр инде үзгәргән. XIX гасыр урталарында Казанбашны Кармыш-Казанбаш дип йөрткәннәр. Соңыннан анда волость төзелгәч, Кармыш волосте дип, ә авылы Казанбаш дип йөртелә башлаган.

Кармыш дигән исемнең килеп чыгуын болай аңлатырга мөмкин: Казан ханлыгы чорында татарларның иң оешып утырган тирәләреннән читтә сакчылык крепостьлары төзелгән. (Арча, Чистай, Норлат, Саба һ. б. районнарда.) Татар халкының яшәгән урыны Арча ягында хәзерге Казанбаш тирәсендә чикләнгән. Анда сакчылык крепосте булган. Крепость чикләрне карап торырга тиеш булган. «Карамыш» (смотреть) – кешеләр яшәгән урын әкренләп «Кармыш»ка әйләнгән, ә Казан елгасының башында торучылар инде «Казан башы» булып киткәннәр.

Арчадан төньяктарак мари, удмурт халыклары яшәгән. Арча («ар» дип халык телендә удмуртларны әйткәннәр), Пошалым, Арбаш һ.б. татар сүзләре түгел.

Гомумән, Арча сүзе тарихта беренче булып 1375 елгы Новгород елъязмасында очрый. Анда күрсәтелгән елда Вятка халкының Арча крепостена килеп китүе искә алына.

1962 ел

*Язмаларны басмага **Гәүһәр Хәсәнова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

ХӘЛЕМЕЗДӘН ШИКАЯТЬ*

Шәмсетдин Күлтәси

Игътибарыгызга хәзерге Арча районы Күлтәс авылының имам-хатыйбы һәм мөдәррисе Шәмсетдин Мөхәммәд бине Нурмөхәммәд әт-Таһири әл-Күлтәсинең (1857-1932) 1903 елда басылган «Хәлемездән шикаять» исемле әсәрен берникадәр кыскартып тәкъдим итәбез. Автор, шигъри калыпка салып, үз фикердәшләренә, ягъни «дустларына» атап язган әлеге әсәрендә дуслык, бердәмлек, намус, ихласлык, кардәшлек хакының юкка чыгуына, наданлык, ялагайлык, нәфес азгынлыгы кебек сыйфатларның тамыр җәюенә шикаять белдерә, мәктәп-мәдрәсәләрдәге иҗек ысулын, схоластика белән мантыйк фәннәрен тәнкыйтьли, Коръән, хәдис, пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в.нең тормыш юлы укытылмавын әйтә. Күлтәси, шул замандагы рухи-әхлакый проблемаларны күтәрү белән бергә, имам-мөдәррис буларак, үз хезмәттәшләрен, ягъни башка дин әһелләрен яхшы гына камчылый да әле.

Әсәрне укып, хәзерге имамнарыбыз әлеге тәнкыйтьне үзләренә юнәлтелгән дип кабул итмәсләр, дигән өметтә калабыз. Заманында Шәмсетдин Күлтәси дә шундый ук өметтә булган. Әсәрнең «Игътираз», ягъни фикернең дөреслегенә сәбәпләр дигән бүлекчәсендә ул менә ниләр яза: *«Сәгый (тырышлык) вә гайрәт әрбабы (иясе) булган ирләребез безнең бу шикаять вә зарларыбыздан шикаять итмәсләр өметендәмен: милләт вә кавемебезнең тәрәккыйсе юлында һәр ләззәт вә рәхәтләрен фида иткән, хәтта бар фикерен, бар гомерен шул юлда сарыф иткән милләтпәрвәр кардәшләребез*

Күлтәс мәчете

*Күлтәси Ш. Хәлемездән шикаять / нашире: Казанда китапчы Исмәгыйль Шәмсетдинов. – Казан, 1903.

юк түгел, бардыр, ләкин гаять аз булып, мең дә бер нисбәтендә булса да бардыр. Бинаән галәйһи (шулай булгач), бу шикаятебез гомумгә вә күпкә күрәдер. Шәмсетдин Мөхәммәд».

Укучыларыбыз да «Хәлемездән шикаять»не тарихи-әдәби мирасның бер үрнәге буларак кына карап, анда әйтелгән түбәнлекләргә төшүдән сакланырлар, иншаллаһ. Без дә, алда язылачак юллар аша, Шәмсетдин хәзрәтләре кебек үк, намуслы, гыйлемле һәм гамәлләре белән милләтебезгә фидакарь хезмәт итә торган имамнарыбызның йөзенә тап төшерүдән куркабыз. Ә мәхәллә тәрәге булырдай дин әһелләребез, шөкер, әлегә күп.

Редакция

***

Заманамыз бозылмыш, халкымыз наданланмыш,
Арадин дустлык китмеш, берлек бетмеш, дустларым.
Һәркем үз нәфсе өчен, сүзен булдырыр өчен,
Иштәмез кеше сүзен, көчлек кыйлыр, дустларым.
Кардәшлек хакын белмәс, ил файдасын күзәтмәс,
Берлек нидер, аңламас, мин-мин, дияр, дустларым.
Бер акчалык үз өчен, ярты акчалык сүз өчен,
Кисер берлекнең җебен, кадер өзәр, дустларым.
Шәригать буйламыйдыр, диянәт буйламыйдыр,
Бу мөселманлыкмыдыр, карап карыйк, дустларым.
Хәлбуки динемезнең кардәшлек, дустлык аның,
Иттифакъ, берлек аның нигезедер, дустларым.
Дин кардәшен бик сөймәк, аның өчен кайгырмак,
Хакын ригая кыйлмак зур фарыздыр, дустларым.
Шәригатьнең кушканы, мәхәббәттер, бел аны,
Өлфәттер боерганы һәм берлектер, дустларым.
Алланың бик тыйганы, рәсүлнең курыкканы,
Дошманлыктыр, бел аны һәм айрылыйк, дустларым.
Бу хәлләр бездә булган, наданлык безне баскан,
Чын галимнәр азайган, сәбәп шулдыр, дустларым.
Без мескин, бичара без, кемдин үрнәк алыйк без,
Кайдан гыйлем табыйк без, кемемез бар, дустларым?
Илдә имам булганнар, галим исемен алганнар,
Бигрәк надан калганнар, имди нишлик, дустларым.
Мәктәбемездә – иҗек, мәдрәсәләрдә – мантыйк,
Ташланган ысхаластик[1], гомер череткеч, дустларым.
Иҗек укып, күп бала язу танымый кала,
Бөтенләй надан кала, бик кызганыч, дустларым.
«Һәфтияк»не иҗекләп, өч ел гомер кичереп,
Кала бер сүз белмәеп, ни үкенеч, дустларым.
Иҗектә сүз күп, диләр, мәшәкать тә күп, диләр,
Уку бик читен, диләр, бусы дөрест, дустларым.
Читен булгач – күп савап, бер сүзенә – ун савап,
Иҗектә бик күп савап, дип укыйлар, дустларым.
Әмма бу сүз гаҗәптер, моны мелла алдаптыр,

[1] Ысхоластика – иске заманнарда грекларның фәлсәфәседер ки, берникадәр гасырлар моның илә иштигаль итеп-итеп тә *(файдаланып та)* һич файда күрелмәдегеннән бөтенләй ташламышлардыр. Безнең ислам фәлсәфәчеләре шуны табып алып, аңа янә берникадәр хыял һәм уйдырмалар арттырып, хәзер дә шуның илә иштигаль итәләрдер. – *Авт.иск.*

Укытмаска сәбәптер, бер хәйләдер, дустларым.
Боларның укулары, савап өчен булсайде,
Иҗек ни хаҗәт иде, ялганлыйлар, дустларым.
Савап булса максудың, ал кулыңа тәсбихең,
Әйтеп утыр тәһлилең, иҗек нигә, дустларым.
Мәдрәсәдә торганнар, мантыйк укып йөргәннәр,
Ысхаластик белгәннәр, бик мактаныр, дустларым.
Һәрнәрсәне белдем, дип, асылына төштем, дип,
Хикмәтен аңладым, дип, лафа оралар, дустларым.
Ысхаластик күрмәсә, мантыйкны бик белмәсә,
Кеше түгел ул кемсә, дип сөйләрләр, дустларым.
Гамәленә игътибар юк, фикренә игътимад[2] юк,
Колак салыр сүзе юк, дип хурлыйлар, дустларым.
Бу көннәрдә балалар йөзләп-меңләптер алар,
Иҗекне һич белмиләр, Коръән укыр, дустларым.
Шуның кеби күп яшьләр, чук нәрсәләр беләләр,
Белгәнен аңлаталар, әйтеп-язып, дустларым.
Язганнары бик ачык, рәхәтләнеп укырлык,
Күп файдалар алырлык, аңларлыктыр, дустларым.
Безнең галим дигәннәр мантыйк укып йөргәннәр,
Күп бәхәсләр кылалар, нечкәлиләр, дустларым.
Дөнья башын эзлиләр, ахырын да күзлиләр,
Уртасыны күрмиләр, кирәге шул, дустларым.
Уртасы дигәнмез, үземездер, белегез,
Үземезне белсәк без, юл табамыз, дустларым.
Хәлемезне беләлем, башкаларны күрәлем,
Чагыштырып бакалым, тиз аңларсыз, дустларым.
Һәркем үзен таныган, Алланы ул таныган,
Хәдис тә шулай дигән, бик кирәк шул, дустларым.
Безнең мантыйк белгәннәр, аять вә хәдис күрми,
Әхлак вә тәфсир белми, бик гафилдер, дустларым.
Тарих сиярәт[3] күрмәсләр, әсляф[4] хәлен белмәсләр,
Хәлемезгә бакмаслар, гыйбрәт алмас, дустларым.
Укыган дәресләрдән, үгрәнгән бәхәсләрдән,
Кычкырыш-тавышлардан файда нидер, дустларым.
Без күргән файдалары, чыккан нәтиҗәләре,
Иттифакъсызлык бары һәм дошманлык, дустларым.
Филәсүфлек сатмактыр, дин илә уйнамактыр,
Ялган сүзләр тезмәктер, тәкфир[5] өчен, дустларым.
Кардәш сүзен ишетмәс, асылына һич төшенмәс,
Тәкфир кыйлудан кайтмас, дин кардәшен, дустларым.
Кайсы мәдрәсәләрдә мантыйк укылмас анда,
Бәхәс аз булыр анда, юаш булыр, дустларым.
Анда да артык эш юк, кирәкне укыган юк,
Файдасы аз шулай ук, әрәм гомер, дустларым.
Истибра[6], истинҗадан[7], хәез[8] илә нифастан[9],
Госел сәбәпләреннән күп узмаслар, дустларым.
Талак илә никахтан, мәет дәфен кылудан,

[2] Игътимад – ышаныч, таяныч.

[3] Сиярәт, ягъни сияреннәби – Мөхәммәт с.г.в.нең тормышы, холкы, кылган-гамәлләре турындагы гыйлем.

[4] Әсляф, ягъни сәләфләр – күз уңында сәхабәләр һәм табигыйннар тотыла.

[5] Тәкфир – динсез, дәһри санау, кемнедер кяфер атау.

[6] Истибра – бәвел итү, бәвелдән соң юыну.

[7] Истинҗа – тәрәттән соң пакьләнү.

[8] Хәез – күрем.

[9] Нифас – бала тапканнан соң чистарыну.

Атаның малын бүлүдән уза алмаслар, дустларым.
Әмма шәригать нидер, аның максуды нидер,
Аннан көткән эш нидер, укылмаюр, дустларым.
Янә гарәп телене, укый башларлар аны,
Катыштырып фарсыны һич урынсыз, дустларым.
Китаплары – фарсыдыр, «Игълял»лары – фарсыдыр[10],
Тәркиб[11] уку – фарсыдыр, төрки юктыр, дустларым.
Моның өстенә янә, күп бәхәсләр кушыла,
Күп хилафлар сөйләнә, һич файдасыз, дустларым.
Шулай нәхү-сарыфка[12], күп гомер сарыф кыйла,
Әмма яхшы гарәпчә белми кала, дустларым.
«Һәфтияк»не иҗекләп, өч ел гомер кичереп,
Калган бер сүз белмәеп кебек була, дустларым.
Хәлбуки максатлары төркидән качмак иде,
Гарәпчә белмәк иде, белми калды, дустларым.
Гарәпчәдән өлеш юк, төркине укыган юк,
Ана телен белгән юк, бик гафилбез, дустларым.
Шулай мәдрәсә хәлен яздык монда беразын,
Имди ил имамнарын язып карыйк, дустларым.
Мәдрәсәдән чыгарлар, илгә имам булырлар,
Ләкин ил өчен алар кайгырмаслар, дустларым.
Бар эше җыймак булыр, яхшы киенмәк булыр,
Йортын төземәк булыр, максаты шул, дустларым.
Азга һич разый булмас, барга канәгать кылмас,
Илдән тамгысы[13] бетмәс, күзе туймас, дустларым.
Арбасы яхшы булсын, кигәне купшы булсын,
Атның җуртагын җиксен, чабып йөрсен, дустларым.
Мондаен муллаларда ил өчен кайгы кайда?
Сабак укыту кайда, надан калдык, дустларым.
Үзе түгел, кешегә юл бирмәс укытырга,
Тырышыр туктатырга укытуны, дустларым.
Бар сүзләре мактану, гайбәт, яманат сату,
Укытучыны кагу һәм хурлаудыр, дустларым.
Дәрләү ялган аларда, яла ягу аларда,
Халык алдау анларда һәм котырту, дустларым.
Яңа ысуллы мәктәптә такталар да бар анда,
Сурәтләр дә бар анда, дип ялганнар, дустларым.
Остазларны хурлый, дип, динебезне хурлый, дип,
Баланы аздыра, дип, яла ягар, дустларым.
Иҗектән аерылмагыз, әбҗәдне калдырмагыз,
«Кисекбаш»ны куймагыз, дип котыртыр, дустларым.
Йөз кат «әлиф», «би» укыса, мең кат «әбҗәд» укыса,
Савабын багышласа, әрвахларга, дустларым.
Бар гөнаһы кичелер, тәмугтан да котылыр,
Тугры оҗмахка керер, дип алдарлар, дустларым.
Мескин гавам ышаныр, «әлиф», «би»не бик укыр,
Үлгән чакта шул булыр, телендә дә, дустларым.
Сөйгәннәре[14] тузынмак, зиннәтләре арттырмак,

[10] Гарәп телен өйрәнә башлаган фарсы балаларына җиңеллек өчен гарәпнең сарыф вә нәхү кагыйдәләрен фарсы галимнәре үзләренең ана теленә тәрҗемә кылып китаплар язмышлар. Безнең галимнәребез һаман моны аңламыйлар: балаларына бер чит телне янә бер чит тел ярдәмендә өйрәтергә тырышалар да һич файда күрә алмыйлар. – *Авт. иск.*

[11] Тәркиб – грамматика мәгънәсендә.

[12] Нәхү-сарыф – морфология-синтаксис.

[13] Тамгы – зур теләк, ач күзлелек.

[14] Мулла әфәнделәребезнең. – *Авт. иск.*

Кунак булып йөрешмәк, мактанышмак, дустларым.
Бүген кунакта – миндә, иртәгә булыр синдә,
Соңра байгурасында – эшләре шул, дустларым.
Болар шулай гыйззәттә, төрле җирдә кунакта,
Без калдык наданлыкта, мәзлум[15] булып, дустларым.
Балабыз укыган юк, язу да таныган юк,
Яза белгән күптән юк, бик мәхрүм без, дустларым.
Бу тугрыдан сүз ачсак, мулла укытмый, дисәк,
Надан калабыз, дисәк, зарланышсак, дустларым.
Безгә рәнҗи башлыйлар, каһәр укып ташлыйлар,
Җәһәннәмлек сез, диләр, бик каргыйлар, дустларым.
Бу ялкау меллаларга саран байлар дуст була,
Укытмаска булыша, саранлыктан, дустларым.
Мәктәп салырга кирәк, хәлфә алырга кирәк,
Аны багарга кирәк, шунсыз булмый, дустларым.
Бу эш саран байларга, һиммәтсез агайларга,
Бик авырдыр анларга, әҗәлдән дә, дустларым.

Шулай бик авыр булганга күрә:
Мәктәп нәрсәгә, диләр, язу нәрсәгә, диләр,
Иҗек бик савап, диләр, безгә җитәр, тидия.
Мелла өенә барсыннар, хатыныннан укысыннар,
«Кисекбаш»ны белсеннәр, шул дәвүлнә[16], тидия.
Без мәктәпкә бармадык, язу яза белмәдек,
Кешедән ким йөрмәдек, чем плохә, тидия.
Кайчагында хәзрәт тә, кунактан бушаганда,
Аштан, судан кайтканда, күз салгалар, тидия.
Зуррак балаларга, җиткәнрәк кызларга,
«Йосыф» китабын аңа, укытып чыгар тидия.

Кунактан бушанганда – сабак өенә:
Мелласы килеп керер, кил монда, кызым, дияр,
Сиңа бер күңелле җир табып уктыйм, тидия.
Бала китабын алыр, мелла янына килер,
Юлны күрсәтә барыр, бармагы илә, тидия.
Бала күрсәтмәс исә, мелласы әйтер аңа:
Юлларны күрсәт миңа, шулай, кызым, тидия.
«Йосыф» китабындагы бик кирәкле җирләре,
Кат-кат укыганнары ошбу җирләр, тидия.

Мелла, баланың бармакларына вә башка бәгъзе җирләренә күз салгалаганы хәлдә, укый башларлар бергәләп Йосыф галәйһиссәлам китабыннан Зөләйха кыйссасын:

***

Яңа үсмеш талчыбыктай бармакларың,
Энҗе-мәрҗәннән тезелмеш тырнакларың,
Кардан да аграктыр беләкләрең, –
Кул-учларың ефәктән йомшак имди.

[15] Мәзлум – изелгән, җәберләнгән.

[16] Монда шулай үзләре сөйләшкәнчә «дәвүлнә» һәм «чем плохә» дип яздык, гафу итәрсез. – *Авт. иск.*

Яңа туган айга охшаш кашың бар,
Энҗегә охшаш синең тешләрең бар,
Гаҗәп зифа ефәр кебек сачләрең бар, –
Минем кулым үрмәгә лаек имди.

Зифа буйның кара озын сачләре бар,
Мөрәвәтле[17], бик татлы сүзләрең бар,
Гамзә кыйлсаң[18] , телдән кичәр күзләрең бар, –
Керфекләрең җанымнан кичәр имди.

Якут кебек синең яңакларың,
Яшь алмадан ләтыйфрәк[19] иякләрең,
Бал-шикәрдән татлырактыр иреннәрең, –
Ике ирнең күңлемне эретер имди.

Җаным сиңа кушмак җан рәхәте,
Йөзең кояш кеби, гыйшкың каты,
Сурәтең гаҗәп зифа, сүзең җете, –
Кылыч кеби җанымнан кичәр имди.

Хакыйкать: син сабырсыз иттең мине,
Аһ, җаным, кайчан була каушу көне,
Һәрвакыт күреп торсам җаным, сине, –
Күрмәс исәм сабырым һичбер калмас имди.

Сөйлә, җаным, инде син ни санарсың,
Күңелеңдә ни кичәр, ни уйларсың,
Әйт миңа, син, кемсәдән куркамсың, –
Әллә бер дә яшьлек дәртең юкмы имди.

Ник качасың, уемыз хуш түгелмедер,
Һич кеше юк бик аулак түгелмедер,
Мин үзем дә сиңа лаек түгелмедер, –
Әллә бер дә яшьлек дәртең юкмы имди.

***

Бу укучы кыз бала унбиш яшендә була,
Йә уналтыда була, киме аздыр, дустларым.
Шуннан да ким булганы, белалмый бу китапны,
Укыйдыр «Кисекбаш»ны абыстайдан, дустларым.

Уйлап бакма әле:
Мелла яшьрәк булса, хатыны яшьлерәк булса,
Баланың да бае булса аталары, дустларым.
Ялтыравык көздәге бичара кыз хәлләре,
Бу кызга да килүе бик ихтимал, дустларым.

Тәмам

*Кереш мәкалә һәм текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

[17] Мөрәвәтле – кешелекле.

[18] Гамзә кыйлсаң – күз сирпесәң.

[19] Ләтыйфрәк – нәфисрәк.

Безнең мирас №12 декабрь 2018

ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов



МАНЬЧЖУРИЯ. ЦИЦИКАР

Бу имам белән сөйләшә башладык: «*Әнә әстахйы әнә ахун лә а'ляму лисанэл-'араб*» [Мин хайа итәм, ахун булам, гарәп теле белмим], – диде. «Ахун була торып, гарәп телен белмәвемнән хәйә итәм, оялам», – дип әйтергә теләгәнен аңладым. Бу кешене мин бик ошаттым, һич югы җаһил булуын таный. Минем әйткәннәремне аз булса да аңлый. Тәрҗемәчегә ихтыяҗ тоймыйча, бу кеше белән самими рәвештә сөйләшә башладым. Иртәгә гарәфә булганга, ахун шәкертләргә китәргә рөхсәт итте. Бу мөхтәрәм зат Тонкинда[1] укыган. Анда гарәпләр дә күп икән. Бераз тәҗвид белән Фатиха сүрәсен укый икән, аннан тыш, камәттән[2] алда өч «Ихлас» укый, пәнҗешәмбе көннәрдә исә кычкырып зикер әйтә икән. Бу имамның «бозык мәзһәпле» булуы да менә шуннан гыйбарәт икән. Минем: «Бөтен Цицикарда бердәнбер мөселман бар, анысы да «бозык мәзһәпле» икән», – диясем килде.

Корбан бәйрәмен Цицикарда үткәрдем, бик сәер хәлләр күрдем. Мин

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

[1] Тонкин – бүгенге көндә Вьетнамга керә, 1885-1945 еллар арасында Франция колониясе булган, хәзерге исеме – Бакбо (тәрҗ. иск.).

[2] Камәт – намазны башлаганда укыла (тәрҗ. иск.).

килгән көннәрдә үк инде бөтен шәкертләр һәм укытучылар ураза тоталар иде. Зөлхиҗҗәнең ун көнендә ураза тоту, алар фикеренчә, Рамазан уразасыннан да әһәмиятлерәк һәм хәтта аны тотмый калырга да ярамый. Моның кебек буш нәрсә дип әйтерлек нәрсә бар – барысын да фарыз кебек кабул итәләр. Тик үзләрендә булмаган берәр нәрсә шәригать буенча фарыз саналса да, алар өчен аның әһәмияте юк. Мәсәлән, боларда намаз бары тик укытучы ахун һәм шәкертләр генә үтәргә тиешле гыйбадәт булып санала. Тик зөлхиҗҗәнең ун көнендә бөтен мөселманнар да ураза тотарга тиеш, шулай кабул ителгән. Минем ул көннәрдә ураза тотмавыма бик аптырадылар. «*Әнтә ‘алим лә йасум*» [Галим булсаң да, ураза тотмыйсың], – дип, миңа нәфрәтләнеп карадылар.

Мөселман кешесе мондый хәлләрне күреп аптырамыйча, бу кешеләргә кызганып карамыйча нишләсен?! Дөресен әйтим: Цицикарда яшәгән көннәрем минем өчен бик күңелсез көннәр булды, беренче күрүемдә күп нәрсә күңелемә авыр килде. Намаз кылырга дип мәчеткә киләм: имам Фатиха сүрәсен укыганда бары тик ике-өч сүзен генә аңлый алам. Ах, йа Рабби! Дөньяда Исламият бу кадәр дә сәер булган бер илгә килү, боларны күрү уема да кереп чыкмаган иде. Ах, бу ни хәл?! Ислам җитәкчеләре, бу хәлләрне күрә торып, тавыш-тыннарын чыгармасалар, соңыннан, Кыямәт көнендә, ни диярләр?! Сорау алуга тартылмаячакларммы? Тартылачаклар.

Өммәт бу кадәр җаһиллеккә төшсен дә, имам булып йөрүчеләр ничек инде моннан җавапка тартылмасыннар ди?! «Әгәр мөселман кытайларның барысы да бу хәлдә булса, 80000000 мөселманның хәле бик аяныч!» – дип уйлап, бик кайгырдым. Ләкин чара юк, монда һич булмаса өч-биш ай калыр, иман һәм Ислам өйрәтер, диннең нигезләрен өйрәтер идем – тел белмим. Бик күп уйландым, тик бер генә чара да таба алмадым. Бу шәһәрдә 1500 йорт булып яшәүче мөселман халкы булып та, балаларга диннең нигезләрен өйрәтерлек бер укытучы булмаса, мөселманнарның хәле бераздан ничек булачак? Күпме генә кайгырсам, ачыргалансам да, кем аңлаячак, кем тыңлаячак?!

Әлеге «бозык мәзһәпле» имам янына күп тапкырлар бардым, сөйләштем. Ул да һаман үз җаһиллегеннән зарлана, сызлана: «Кытай мөселманнары һәлак булды! Кытайда мөселман калмады!» – ди, кайгыра, өзгәләнә.

Мин Цицикарда ике тапкыр бәйрәм намазы кылдым. Беренче тапкыр бу «мәзһәбе бозык» имам белән намаз кылдык, чөнки ул бераз исәп белән дә эш итә икән. Ике көннән соң, бәйрәм намазын мөселманнар белән бергә кылдык. Бу соңгысы турында бераз мәгълүмат биреп китим. Болар бәйрәм намазына килгәндә, барысы да кулларына утлы чыра тотып киләләр. Бу чыра яна да, ис тә тарата. Мәчеткә кергәч, ул утлы чыраларны мангал кебек бернәрсәгә утыртып куялар. Мәчет бераздан эчендә тора алмаслык хәлгә килә. Тик үзләренең, һәрвакыт бу төтен эчендә гомер сөргәннәренә күрә, исләре дә китми.

Бөтен кеше җыелып беткәннән соң, имам аягүрә торып баса, шул төтен эчендә кытай телендә вәгазь сөйли, нәсыйхәт бирә. Вәгазьләрендә корбан, аның фазиләтләре (яхшы яклары) турында сөйлиләр икән. Сүзләрен аңламасам да, вәгазьләрен ошаттым, ара-тирә кайбер аять һәм хәдисләр укуын да аңладым.

АХУНЛЫК

Кытай голәмәсендә ахун яки ахунд чин булып санала. Дөреслектә бу исем Мавәра-ен-нәһер һәм Бохара голәмәсе арасында булган. Бөтен Русия һәм Төркестан Кытаенда, Бохара һәм Хива голәмәсендә һәм Кытай илендә киң таралган бер дәрәҗә исеме. Ахун – бөтен җирдә дә голәмәгә кагылышлы дәрәҗә исеме, ләкин кулланылышы төрле-

төрле. Төркестанда шигырь сөйли белгәннәргә – шигырь куәсе булганнарга ахун диләр, Русиядә ахун – Оренбург шәригать мәхкәмәсе карамагындагы голәмәнең иң танылганнарына хөкүмәт тарафыннан бирелә торган дәрәҗә атамасы, Иранда тагын башка, тик Кытайда, күбесенчә, мәхәллә имамына ахун диләр.

Шулай итеп, Кытай илендә, Цицикар шәһәрендә бәйрәм намазыбызны кылганнан соң, укуын тәмамлаган ике шәкерткә, минем хозурымда, ахунлык дәрәҗәсе бирелде. 15 ел мәдрәсәдә укып чыкканнан соң, имамлык хокукына ия булулары турында таныклык, бер чапан белән чалма да бирделәр. Моннан тыш, әле тагын Кытай хөкүмәте тарафыннан, рәсми дәүләт йортларына барырга туры килгәндә кияр өчен, баш киеме дә бүләк итеп бирелә икән. Бу тантана мәчеттә бәйрәм намазыннан соң, күп санлы халык төркеме алдында менә шул рәвештә башкарыла:

Чуар, аллы-гөлле намазлык җәелә, остаз әфәнде кыйблага аркасын куеп намазлык башындагы урынына утыра, ахунлык биреләсе кеше намазлыкка кереп баса, нәкъ остазның каршысына килеп, ике кулын учын-учка каплап кушырып, аяк бармакларына таба юнәлтә, билен бөгеп, куллары тәмам аяк бармакларына тиярлек итеп иелеп сәламли, аннары остазга нидер әйтә дә тураеп баса, кулларын маңгаена куя, шул халәттә тагын өч тапкыр сәламли. Аңа дип хәзерләнгән, яшел постауга язылган таныклык мәчетнең ишегенә киереп беркетелеп куела. Өч көн буе таныклык шул хәлдә тора, моны «халыкка белдерү, таныту», диләр.

Мин, бер кешенең башка бер кешене алдында намазга иелгәндәй иелеп сәламләве дөрес түгел, дип әйтеп карасам да, моны минем җаһиллегемә сылтадылар, үзләрен хаклы дип санадылар.

Мондый хәлгә төшкән мөселманнарны күреп, өметсезлеккә бирелмәү мөмкин түгел. Бу хәлләр, әлбәттә, миңа бик көчле тәэсир итте. Мөселманнарны мондый хәлдә күргәннән соң, инде кытайларның Цицикардагы үз мәктәпләрен барып карыйсым да килмәде. Тик: «Бу җирләр үзәктән ерак, ә үзәктә алдынгы фикерле мөселманнар күптер, голәмә дә күбрәктер», – дип, үз-үземне юата идем. Кайчак кичләрен Ку Эн әфәнде белән сөйләшеп утырабыз. Аның да дин турында берни белмәве, башка нәрсәләр белән дә кызыксынмавы аңлашылды. Шулкадәр байлыгы була торып, бу кешенең яшәү шартлары бик начар. Аның белән бары тик сәүдә турында гына сөйләшә алабыз. Милләт, тәрәккый, дин һ.б.ш.ларда һич эше юк. Укытучылык, укыту-тәрбия турында сүз кузгатсам, шундук йокысы килә башлый. Ахуннарның, муллаларның җаһиллеге турында әйтә башласам, һич ышанасы килми.

Беркөнне миңа ярдәм итеп йөрүче Абдулла әфәндегә: «Ахун безнең голәмәне ошатмый, тик безнең голәмә дә ахун турында: «Башка мәзхәптәге кеше», – дип әйтә икән. Менә биредәге голәмә Ку Эн әфәндене инде ышандырган да, минем турында «башка мәзһәптә», дип әйткәннәр. Берни белми торган Ку Эн әфәнде алдында мине дә теге «бозык мәзһәпле» кешегә иш итеп куйганнар.

Цицикарда алты көн тордым, миңа алтмыш көн торган кебек булды.

ҖЕНАЗА

Цицикарда яшәгәндә игътибарымны җәлеп иткән тагын бернәрсә – мәет күмү йоласы булды. Мин моның бөтен мөселман кытайларда бертөрле икәнен күрдем. Берәр өйдә мәет булса, иң башта матәм игълан ителеп, бу өй хуҗасы, гаилә кешеләре, туганнары, якыннары һәммәсе актан киенә, аннары ахунга хәбәр җибәрелә. Ахун килә, барыннан да элек, үлгән кешенең бурычы калу – калмавын сораштыра. Әгәр үлгән кешенең бурычы калган булса, алачак кешеләрне

табып китерүләрен сорый, бөтен бурычларын варисларыннан түләттерә. Әгәр бурыч түләрлек хәлләре булмаса, варислар белән алачак кеше арасында бер килешү төзеттерә, шуннан соң гына җеназа башлана.

Бу мөгамәлә миңа ошады. Безнең Русия мөселманнарында голәмә моның нәкъ киресен эшли. Фидиясен, тегесен-монысын имам ала, бурычка җиткәч, яшерәләр: «Берни калмады», – диләр.

Соңыннан, мәетне алып киткәндә, үлгән кешенең туганнары һәм якыннары – барысының да кулларында таяк – нәкъ зиратка кадәр озата баралар. (Бу таяк тоту Бохарада да бар, Кытай мәҗүсиләрендә дә киң таралган.)

Бездәге кебек фидия һәм сәдака-фәлән булса да, бу бары байлар өчен генә, фәкыйрьләр өчен тиеш түгел, дип санала.

МӨСЕЛМАН БАЛАЛАРГА КЫТАЙ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ КАРАШЫ

Цицикарда мөселман балалар өчен хөкүмәт тарафыннан ачылган өч мәктәп бар. Әлеге мәктәпләрнең чыгымнарын мөселманнар үзләре түли. Мин бу мәктәпләрдә булдым, укытучыларының барысы да – мәҗүси кытайлар. Бу мәктәпләрнең мөселманнар өчен зыяны юк, дип уйлыйм, һич булмаса укырга һәм язарга өйрәнәләр. Билгеле булганча, кытайларда укый-яза белү бик зур эш булып тора, чөнки һәр иероглифны өйрәнергә кирәк. Уку һәм язу чынлап та бик авыр, бик яхшы укый һәм яза белү өчен 36000 иероглиф белергә кирәк. (Безгә исә 28 хәреф тә күп һәм авыр булып тоела.) Шулай булуга карамастан, кытайларда укый-яза белүчеләрнең саны бик күп.

КЫТАЙ ГАСКӘРИЛӘРЕ

Цицикарда яңа һәм иң соңгы технологиягә нигезләнгән кораллар белән коралланган 40000гә якын гаскәри бар икән. Гаскәриләрне өйрәтү эше турында бернинди дә мәгълүматым юк, шуңа күрә укыту-өйрәтү ысуллары турында берни әйтә алмыйм. Ләкин шуны әйтә алам: биредә офицерларның күбесе инглизләр, бер өлеше япон кешесе икән. Русия чигендә белем-тәрбия бирүчеләр болар булса, әлбәттә, укыту-өйрәтү эшенең бернинди кимчелексез алып барылуында шик юк.

Биредә торганда, мин һәркөн шуңа игътибар иттем: иртә-кич бу гаскәриләр һаман өйрәнү белән мәшгуль иделәр. Кайбер көннәрдә атарга өйрәнәләр. Гаскәриләрнең казармаларын барып күрдем, ашауларын, яшәү шартларын күрдем, гаять тәртипле иде.

Мин Цицикарда булганда: «Гаскәриләрнең чәчләрен кисү турында Пекиннан фәрман килгән икән дә, гаскәриләр моны кабул итмәгәннәр», – дигән сүзләр йөрде. Кытайлар чәчләре һәм тырнаклары белән бик горурланалар. Тырнакларын да кисмиләр. Чәч кисүне исә баш кисү дип кабул итәләр. Бу турыда тагын да тулырак мәгълүматны Пекинга баргач бирермен, дип уйлыйм.

ХАРБИН

Харбин – Маньчжуриянең иң зур шәһәре. Харбин Кытай иленә керә, элеккеге исеме – Фудзядян. Бирегә килеп урнашкач, руслар Харбин дип аталган җирдә бер шәһәрчек төзегәннәр. Бераздан Харбин өч мәхәлләгә бүленгән: Яңа Харбин, Иске Харбин һәм Пристань. Фудзядян да аерым шәһәр. Кайчандыр Харбин бөтенләе белән руслар кулында булган, түрәләр барысы да рус, Русиянең эчке төбәкләрендә мөгамәлә ничек барган булса, биредә дә шулай барган.

Тик хәзерге көндә инде алай түгел. Харбин күпме генә Русия идарәсе астында булса да, кирәге чыкса, кытай түрәләре дә эшкә катнаша алалар. Бигрәк тә кытай кешесе белән рус кеше-

Харбин шәһәре

се арасында бәхәс, гауга чыкса, ничек кенә булса да, нинди мәхкәмәгә генә мөрәҗәгать ителсә дә, кытай кешесе хаклы чыга. Фудзядянга исә, рус түрәләре бөтенләй дә катнаша алмыйлар. Бүгенге көндә русларның башкарма көчләре һәм идарәчелекләре Харбинда да бик зәгыйфь.

Харбинның Пристань дигән өлешен Татарстан дип атап булыр иде. Олы урам буйлап, уңында, сулында никадәр зур бина булса – барысы да татар өйләре, татар кибетләре. Бу мәхәллә – Харбинның сәүдә үзәге. Биредә кытайларның да зур сәүдәгәрләре бар, русларның Чурин фирмасы гаять зур сәүдә белән шөгыльләнә. Тик татарлар шәһәрчекнең иң уртасында, иң дәрәҗәле урынын биләп торалар, бөтен урамны ике яклатып тотканнар. Шуңа күрә, Харбиндагы кардәшләребез белән никадәр генә горурлансак та урынлы булыр.

Якында гына мәчетләре бар, мәктәпләре бар, гаять күркәм мәдрәсәләре һәм имамнары бар: димәк, диннәрен дә хәтерләреннән чыгармаганнар. Руслар Ерак Көнчыгышка таба хәрәкәт итә башлагач, татарлар да калышмады. Руслар кайда төпләнсәләр, безнең татарлар да, барып, шунда чатыр кордылар.

Кытай сугышыннан соң, руслар Маньчжуриянең бөтен җирендә, бөтен шәһәрләрендә төпләнделәр. Нәкъ Порт Артурга кадәр Ерак Көнчыгыш тимер юлының һәр ике ягын рус колониясе дип атарлык иде. Харбинны да ул вакытларда Русиянең бер шәһәре дип атарга мөмкин иде. Ләкин бераз вакыт үткәч, япон сугышыннан соң, бөтен Маньчжуриядә русларның бернинди дәрәҗәсе дә калмады. «Харбинда да бөтенләй калмады», – дип әйтергә була. Бигрәк тә моннан ел ярым элек, Владивосток порты итеп Порт Франк игълан ителгәч, бөтен чит ил товарлары чик үтү хезмәте аша керә башлады. Маньчжурия исә ачык калды. Шулай итеп бөтен рус сәүдәсе торгынлыкка дучар ителде. Харбин белән Фудзядян арасында бер елга ага һәм аның аша салынган күпер бу шәһәрләрне берләштерә. Тик Харбинда Русиядән китерелгән шикәр 18 капик (тиен) тора, Фудзядянда исә 12 тиен. Хәзер бәлки 10 тиен дә булгандыр. 10 фунт шикәр аласы кеше өчен Фудзядянга җигүле ат белән барып кайту 40

Харбин. Базар яны күренеше

тиенгә төшә, шулай булган очракта да 40 тиен янга кала. Мондый товарларда Русия сәүдәсе сугып миңгерәүләтелгән кебек булды. Японнар да, үч иткән кебек, Порт Артурны ачтылар, бөтен Маньчжурияне япон товарлары белән тутырдылар.

Шул рәвешле руслар икътисади яктан да японнарга җиңелгән булып чыкты. Харбин – бүген рәсми рәвештә Кытай мәмләкәте. Русларның анда калуы вакытлыча икәнлеге ап-ачык билгеле. Хәзерге көннән үк кытайлар Харбинга үз мәмләкәтләре итеп карыйлар.

Мин Харбинда Хөсәен Агишев әфәнденең өендә кунак булдым. Хөсәен әфәнде – 25 яшьләр тирәсендәге, Европаның бөтен җирен күргән бер яшь кеше. Энесе Заһидулла Берлинда яши икән. Бу ике бертуган бик эшчән, тумыштан сәүдәгәр, берсе – дөньяның көнчыгышында, икенчесе – көнбатышында – *ләхул-хәмд вәлминнә* [мактау һәм миннәт/шөкер бары тик Аңа/Аллаһка] – шулкадәр тырышып хезмәт куялар ки, бөтен башкаларга чын үрнәк булып торалар. Мәктәп бетермәсәләр дә, икесе дә камил дәрәҗәдә русча беләләр, ул гына да түгел, Заһидулла әфәнде – алманча (немецча), Хөсәен әфәнде инглизчә белә.

Әле 48 яшендә генә булган аталарына: «Аллаһ юлында һәм гыйбадәт кылып яшә, мәктәпләргә күз-колак булып торсаң, шул җитәр, сәүдә эшләре белән үзеңне ватма, какшатма», – дигәннәр, һәр ай аңа 2000 сум акча биреп торалар. Бу ике егетнең, Аллаһы боерса, берничә елдан соң милләтебез арасында исемнәре искә алыначак милләт хезмәтчеләре булачакларын бик нык өмет итәбез. Харбинда боларга юлдаш була алырлык яшьләребез дә бар, Аллаһының ярдәме белән, өметләребезне бушка чыгармаслар.

Харбинда яшәгәндә, мин һәрвакыт мөселманнар белән аралаштым. Шактый гына кимчелекләрен күрдем, үзләренә дә әйттем. Шуларның кайберләре турында Казанда чыга торган «Бәян-ел хак» газетында мәкаләм дә басылды. Максатым аларның мәнфәгатьләрен кайгырту иде.

Дәвамы бар

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

2019 ЕЛДА ДИНИ БӘЙРӘМНӘР ҺӘМ ИСТӘЛЕКЛЕ КӨННӘР

МӨСЕЛМАН АЙ КАЛЕНДАРЕ БУЕНЧА 1440-1441 ҺИЖРИ ЕЛЛАР

7 март – мөселман календаренда изге саналган Рәҗәб аеның беренче көне. Бу айда Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрнең, Гайсә (г.с.) пәйгамбәрнең туган көннәре һәм башка истәлекле көннәр билгеләп үтелә. Шулай ук кече хаҗ, гомрә хаҗы кылына.

7 март – Рәҗәб аеның беренче җомгасына каршы кич – Рәгаиб кичәсе дип атала. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең әти-әнисе Габдуллаһ һәм Әминәнең бергә кушылуын искә алу кичәсе дә.

2 апрель – Мигъраҗ кичәсе. Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәрнең Мәккә шәһәреннән Иерусалимга һәм аннан җиде кат күккә – Аллаһы Тәгаләнең тәхете (көрсие) янына кылган могҗизалы сәяхәте. Мигъраҗ уразасы 100 көн ураза тотуга тиңләнә.

19 апрель – Бәраәт кичәсе, ягъни «ләйләтул-Бәраәт». Бәхет һәм һәртөрле уңышлар, изгелекләр иңә торган изге көн. Нәкъ шушы төнне Аллаһы Тәгалә, һәркемнең изге гамәле һәм догаларында ялварып сораган үтенечләрен исәпкә алып, кешеләрнең язмышларын билгели.

21 май – Идел Болгарстанында Ислам динен рәсми рәвештә кабул иткән көн (310 нчы һижри, 922 нче милади ел).

6 май – изге Рамазан ае һәм Ураза башланган көн. Рамазан аенда иң кадерле кичә – Кадер кичәсе.

4, 5, 6 июнь – Гайдел-фитыр, Ураза бәйрәме.

10 август – Гарәфә көне.

Мөбарәк вә фазыйләтле 10 кичәнең ахыргы кичәсе.

Гарәфә кыяме яки хаҗиларның Гарәфә тавы тирә-юнендә торып гамәл-гыйбадәт башкару көне. Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ.

11 август – Мөбарәк Гыйд әл-Әзъхә яки Корбан гаете.

Җөмлә әһле Исламга мөбарәк, Гает корбанлыклары кабул булсын! Һәр фарыз намаздан соң Тәшрикъ тәкбирләре әйтеләчәк, иншәАллаһ. 10, 11, 12, 13, 14 август – Тәшрикъ көннәре.

30 август – Һиҗри Яңа ел. 1441 Һиҗри елның вә Мөхәррәм әл-Хәрам аеның беренче көне.

Яңа елыбызда дөнья вә ахыйрәт бәхет-сәгадәтенә алып бара, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына ирештерә торган гамәлләр кылырга насыйп булсын! Бу көнне Аллаһының ризалыгы өчен догалар, изге эш-гамәлләр кылып, хәер-садака биреп үткәрергә кирәк.

9 сентябрь – мөбарәк Гашура кичәсе көне. Мөхәррәм әл-Хәрам аеның 10 нчы көнендә Гашура бәйрәме билгеләп үтелә. Бу көннең фазыйләтләре һәм хикмәтләре бихисап. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) болай дигән: «Ибраһим галәйһис-сәлам Гашура көнендә тугандыр. Аллаһы Тәгалә аны Нәмрудның утыннан Гашура көнне коткаргандыр, юлның тугрысын да Гашура көнендә күрсәткәндер».

30 сентябрь – һиҗри тәкъвим буенча елның икенче ае яки Сәфәр әл-Хәер ае башлана. Изге вә бәрәкәтле ай булуын Аллаһы Тәгалә насыйп итсен!

8 ноябрь – Мәүлед-шәриф кичәсе

9 ноябрь – Мәүлед бәйрәме – пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) туган көн. Ул мөселман дөньясында зурлап билгеләп үтелә.

Төзүче-мөхәррир –
хаҗи ***Абдулла Дубин***.

ҮТКӘНГӘ ХАТ

Кадерлем Аяз!

Беләм, Бабасы, Синнән хатлар килмәс, ләкин, гадәтемчә, һаман үткәндәгечә яшисем килә! Син бит елның шушы айларында һәрвакыт диярлек иҗат йортларында, яисә командировкаларда була идең. Үзем, гаиләдәге кым-кырыч эшләремне ташлап, вакытымны сиңа хат язарга багышлый идем. Бүгенге көндә эш-мәшәкатьләр мине каударлап тормаса да, үземчә, синең мирасыңны барлау шөгыле уйлап таптым...

Бабасы, 2013-2016 еллар аралыгында синең мирасың булып калган язмаларны 6 томнан торган «Сайланма әсәрләр» атамасында бастырып чыгардык. 10 томлык чыгарырга омтылып караган идем дә, шушы кадәресенә канәгатьлек кылуны мәслихәт таптылар, югарыдагылар, диюем. Бу томлыкларны нәшер иттертүчеләргә дә мин мең-мең рәхмәтлемен! Татарстанның мәдәният министры Айрат Миңнемулла улы Сибагатуллин үтенечемә теләктәшлек күрсәтүче изге кеше булды! Әгәр минем компьютерда баскан язмаларымны Миләүшә ханым Хәбетдинова җанландырмаса, алар дөнья күрә алмаячаклар иде. Татарстан китап нәшрияты безнең хезмәтләребезне хуплап каршы алмаса, мондый гамәлләр тормышка ашырылмаячак иде, Бабасы! Менә шундый хәлләр, шундый гамәлләр белән

үз-үземне юатып йөри торгач, синең 90 еллык юбилееӊ да килеп җитте, һәм үтеп китеп тә бара, еллар санын алга таба ваклыйбыз. Син мине үз яныңа чакырырга ашыкма әле, картым, яме, эшләр табыла тора ич. Нәшер ителгән байтак әйберләрне мин Дәүләт архивына тапшырдым. Үзең дә шундый киңәш бирә идең, шулай бит?! Әле бастырылмаганнары аннан да күбрәк, аларының хәстәрен күрәсе бар...

Бабасы, 90 еллык юбилееӊ Мәдәният министрлыгы тарафыннан, театр әһелләре дөнясында, Казан федераль университеты башлангычы белән югары дәрәҗәдә билгеләп үтелде. Аллага шөкер, дибез гаиләбез белән! Ничек куанмаска: Мәдәният министрлыгы тарафыннан матди ярдәм күрсәтелеп, Венгриядән Арпад Галгоци, Германиянең Гиссен университеты профессоры Марк Кирхнер, Төмән университеты профессоры Хәнисә Алишина, Германиянең Регенбург университеты профессоры Гундо Йоханнес Хаусман, Санкт-Петербург галимәсе Ида Андреева (университетта сезнең белән янәшә группада укыган), венгрияле Йолант Нагин Пинтер (аның әти-әнисе ГУЛАГ мәхшәрен кичкән кешеләр, үзе шул чорда 1954 елда туган), хәзерге көндә Мәскәүдә яшәп иҗат итүче Ринат Мөхәммәдиев килгән иде. Венгриянең Казандагы консулы Адам Штифтер, Казакъстан Республикасының Казандагы консулы Еркин Тукумов, Мордовия Республикасы дәүләт педагогика университеты профессоры Владимир Рогачев, Кыргызстан-Россия Славян университетының халыкара мөнәсәбәтләр институты деканы Салават Усмановлар конфрениягә чакырулы булдылар. Синең белән гомер иткәндәге гадәтемчә, аларны йортыбызда кунак та итеп кабул иттек. Дустың Галгоцины, документальләштереп тә калдырырга теләп, кинога төшерделәр. Бирсен Ходай! Амин!

Бабасы, шулай итеп, мин ноябрь аеның яртысын, синең әсәрләр буенча куелган спектакльләрдә йөреп, кайдадыр оештыру эшләре башкарып, уздырып та җибәрдем.

Әсәрләреңнең чит телләрдә яңгыравы безне бик куандыра! Фатих Кутлу, Синең амәнәтеңә тугрылык саклап, «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән...», «Яра», «Язгы кәрваннар» әсәрләрен төрек телендә, китаплар итеп, Төркиядә бастырып чыгарды! «Мәхәббәт һәм нәфрәт турында хикәят»еңне, «Берәү» повестеңны инде тәрҗемә итеп тәмамлады. Аны Бер Аллам ярдәменнән ташламасын! Аларны да Төркиядә нәшер итү мөмкинлеге тудырылса иде, дип дога кылам! Амин! «Берәү» повестеңның тәрҗемәсен тәмамлагач, Фатих миңа әйтә: «Ай-һай, Аяз абый беренче повестьларында ук инде төпле фикерле язучы икәнлеген күрсәткән икән!» – ди. Шулай булдың шул, әйеме! Бабасы, тагы бер сөенеч! Синең әсәрләрең буенча Төркиядә диссертация яклаган төрек галиме Абдүлкадир Чәкич Фатих Кутлу тәрҗемә иткән «Өч аршын җир» повестеңны инглиз теленә тәрҗемә иттергән һәм бүгенге көндә редакцияләү эше бара икән. Синең тирән йөрәк яраң «Өч аршын җир» Көнбатыш илләрендә дөнья күрәчәк! Иманым камил, бу хәбәргә син дә бик нык сөенәсеңдер. Галгоци «Йәгез, бер

дога!»ны маҗар (венгр) телендә ике мәртәбә нәшер итеп, сатып бетерделәр инде, өченче мәртәбә дә нәшер итәргә уйлыйлар бугай. Ул халык вәкилләре ГУЛАГ тоткынлыгында бик газап чиккән икән шул!.. «Йәгез, бер дога!»ны немец, инглиз телләрендә дә нәшер итәргә җыенулары ишетелә... Инде килеп, хакаслар «Өч аршын җир» әсәреңне өченче ел (2016) сәхнәләштергәннәр иде. Синең 90 еллыгың уңае белән алар да Казанга килделәр, Кәрим Тинчурин театры бинасында шәпләп спектакльләрен күрсәттеләр. Минем шул спектакль алдыннан борчылуларымны сиздең микән син? «Хакас телен аңламаган тамашачыны ничек җыеп булыр икән?» – дип борчылдым шул, Бабасы! Гаҗәп, татар тамашачысы театрга шундый әвәс халык инде ул! Һәр артистка букетлар тапшырдык, тамашачыга, сәхнәгә менеп, рәхмәтемне белдердем! Дөрес эшләдем дип уйлыйм, Бабасы, шулаймы, ялгышмыйммы? Икенче көнне үзләрен өйгә кунакка чакырдым. Болары ай башындарак булса, ахырга чит ил кунаклары җыйналды. Менә шундый-шундый хәлләр, Бабасы!

Бу хатны әзрәк хәл ала төшкәч, 18 ноябрь көнне язып утырам. Кичә Рәшат улым килеп керде дә, аңа бер вакыйганы сөйләдем. «Венгр телендә чыккан китапны бер дустым, урта кул язучыга күрсәтеп, милләт сөенечен уртаклашырга теләгән», – дим. «Шуннан?» – ди Рәшат. «Улым, – мин әйтәм, – алган да шуган, язучыбыз, Аязның чоры үткән инде, җитәр аңа, уллары акча түләп, ялլап, бер галимәне эшләтәләр», – ди икән. Рәшат кычкырып көлеп җибәрде: «Менә бу татарча! Менә бу татарча! Татар татарны ашамаса, ачка үләр иде. Шушы язучының телне бетерик дип кычкыруы дип аңларга кирәк ич моны!» – ди. Исең-акылың китәрлек, Бабасы! Синең халкыңа әйтер сүзең булган, бүген әйтелгәндәй яңгырый торган фикерләр ярылып ята. Милләт, милләт, дип җан аттың, беркемнән көнләшмәдең, язучылардан фикерле әсәрләр көттең. Андый әсәрләр дөнья күрсә, читәнгә менеп әтәч булып кычкырдың! Шулайдыр шул, татарлык – тарлыктыр шул! Кызганыч, берзаман Мөхәммәт Мәһдиевне күккә чөеп мактап, әсәрләрен анализлап мәкалә яздың, шунда безнең гаилә дустыбыз, күренекле әдип: «Аяз, ялгышасың Мәһдиевне күккә чөеп мактап, үзеңнең дәрәҗәңне төшерәсең!» – дигән иде. Ә син һич кенә дә алай дип уйламадың, мактавыңа куандың! Син нинди киң күңелле, олы җанлы, фикерле, затлы язучы булдың! Синең аша милләтебезнең телгә мөнәсәбәтен җылытырга тырышып, Миләүшә Хәбетдинова театр декадасын Нияз Игъламов белән җан-фәрманга, кулга-кул тотышып эшләде, ә конференциягә чит ил кунакларын чакырып, татарның кунакчыллыгын, акыл ияләренә байлыгын күрсәтергә тырышты. Сүз уңаеннан әйтим әле, Бабасы, син гел миңа Рәүф Игъламовны: «Акыллы кеше!» – дип мактый идең. Хәзерге көндә ул да синең янга күчте, ләкин дәвамчы улы Ниязны «акыл иясе» итеп калдырды! Бирсен Ходай!

Бабасы, әгәр татарның Бөек Тукае булмаса , татар үзен халыклар арасында ничек тотар иде икән? Тукай үз гамәлләрен мәңгелеккә калу максатын куеп башкармагандыр, дип уйларга кирәк.

Нәкыя апа Арпад Галгоци белән

Тукайның рухы шатлансын, үзе тыныч йокласын! Тукайга кирәкме ул бөеклек? Ул бөеклек татар милләте өчен бик кирәк. Бөекләребез күбрәк булсачы! Шул вакытта гына телебезнең абруен күтәрә алабыз ич без! Бирсен Ходай! Амин!

Бабасы, Син Тукай премиясе алучыларга карата битарафлык күрсәтми идең. Син миңа: «Карчык, мин яшәгән чорда ике генә кешегә минем рөхсәттән башка премия бирделәр!» – ди торган идең. Язучылар берлеге җитәкчеләре премия бирелү мәсьәләләре кузгалганда гел синең белән киңәшәләр иде. Хәзер нindидер битарафлык киттеме, дип фаразлыйм. Син булмагач, миңа аңлатып бирүче юк. Югыйсә, Синең Бөек язучы икәнлегеңә дә сүз тидерә алыр иде микән Тукай бүләге лауреаты?! Җитмәсә: «Уллары яллап галимә тоталар», – ди икән җир бит! Син булсаң, Адлер Тимергалин, Фәүзия Бәйрәмова һәм Айдар Фәйзрахманов әллә кайчан ул бүләккә лаек дип табылган булыр иде бит! Йөрәк әрни, Бабасы! Тукай бүләген бирүче комиссия әһелләре Адлер Тимергалинның һәм Фәүзиянең әсәрләреннән, Айдар Фәйзрахманов иҗатыннан хәбәрдар түгел микәнни?! Берсе генә хәбәрдар булса да, чаң кагар иде бит?! Ни кызганыч?!. Урының җәннәттә булсын, кадерлем! Минем әле фани дөньяда озаграк, сау-сәламәт яшәвемне телә! Амин!

Хатының Нәкыя ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

Күренекле шагыйрь һәм тәрҗемәче, бөек Тукайның замандашы Сәгыйть Сүнчәләй (Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләев) 1889 елның 14 (иске стиль белән – 2) августында Саратов губернасының Хвалын өязе Иске Мастак (хәзер Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районына карый) авылында ярлы крәстиян гаиләсендә туа.

Дәүләт террорының иң кызган чорында Ленинград өлкәсе УНКВДсының 1937 елның 9 октябрендә Соловкида узган күчмә утырышы С.Сүнчәләйне атарга дигән хөкем карары чыгара. Карар шул елның 27 октябрендә Соловки концлагере территориясендә гамәлгә ашырыла.

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙ

(1889-1937)

Кем җылый?

Кем җылый, аһ, кем җылый, ул кем — адәмме, җенме ул?
Кем җылый, кем? Илме, җилме? Ник җылый соң төнлә ул?
Кимме ул, мескинме ул? Әллә ятим, әллә гариб...
Ник җылыйсың, әйт, җаным, ник син җылыйсың, нәрсә дип?

Төн караңгы, төн усал, салкын, явыз, дәһшәтле төн...
Кем син, әйт, кем син? Җаным! Төнлә җылыйсың ни өчен?
Төн усал, бәгърем, җылавыңны синең ул аңламас,
Аңласа да — җә көләр, җә көлмәс, әмма санламас.

Төн көләр, төн вәхши ул, яхшым, көләр ул, рәнҗетер!
Кил миңа, кил-кил, җаным, кер куйныма, шикләнмә, кер!
Мин кочыйм, син бәгъремә ныграк кысыл — бәгърем җылы.
Ул җылы әл дә, җаным! Ул әл дә шул мәзлум колы...

Кил, кочыл, ныграк кысыл... рәнҗе, җыла, тик каргама,
Ләгънәт әйтмә, әмма зарлан, зарлан әгъла мәүлаңа...
Төн усал, бирмәм сине, бирмәм аңар, көлдертмәмен,
Агъла, бетсен ул зәһәрле яшь, ләкин сүндертмәсен.

Күзләреңнең яктысын сүндермәмен, сүнмәс, җаным!
Күзләреңне мин үбәрмен, күзләрең үлмәс, җаным!
Куй башыңны, куй минем күкрәккә — әл дә күкрәгем
Нык минем, агълап бетер, әйбәт шигырьләр сөйләрем.

Тәмле җырлар җырларым, җырлап сөярмен мин сине,
Әкрен-әкренләп сүнәр моңлы йөрәгең янгыны.

Тукай рухы

Йоклый безнең тәхте пай — ямьле Казан!
Йоклый мәсҗедләр, Сөембикә, Кабан!

Тәхте пайның йоклый һәр багбостаны,
Йоклый хәсрәтле шәһәр каберстаны...

Йокламый бер рух — газиз рух бу кичә!
Ул оча: аннан үтә, моннан китә...

Ул Казан өстендә гел җырлап оча,
Киң хыял берлә Казанын ул коча.

Кич саен сагына Казанын изге җан,
Җырлый ул гел: «Аһ, Казан! Ямьле Казан!»

Җырлый-җырлый мескинем хәсрәтләнә,
Энҗе яшьләр күзләрендә әйләнә...

Мин качтым

Төн караңгы, күк болытлы — күктә бер йолдыз да юк;
Көзге җил салкын, Идел өсте суык, дулкын суык.

Мин йөзәм, берни дә күрми күзләрем... Әзрәк өшим;
Вәхши дулкыннар мине кыйный. Телим нур — нур телим!

Алда юк бер нур! Беләм мин: артта – якты, артта бар
Бер түгел, мең нур! Ләкин әйләнмимен, бакмыйм аңар —

Ул шәһәргә! Ул мохиттән мин качам! Якты шәһәр —
Алда нур... анда җылы... анда күңелле шәүләләр...

Инде мин кайтмам кире — тартма мине, залим агым:
Буш мәшәкать! Аһ, шәһәрме? Мин аны күрдем, җаным!

Мин беләм инде аны бик шәп! Шәһәр ул — ул тәмуг!
Анда юк чын юл, иман, чын нур! Җаным! Чын анда юк!

Анда нурлар, шәүләләр – ялган! Гомер — ялган! Гомер!
Анда яшь, кан; анда... хуш, якты шәһәр! Раббым! Шөкер!

Унда нур күрәм — хәер, йолдыз ул да! Үтәм!
Төн, суык. Киттем, җаным, Раббым, кичер, көч бир! Йөзәм! ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

МӘГЫЙШӘТ*

Садри Максуди

V

[...] Бирү вәгъдәсе куелгач, күп уйланганнан, егълаганнан соң, Фатихка хат язарга исенә төшеп, Рәбига шушы хатны язды: *«Җаным, Фатихым! Мөбарәк хатыгызны алдым, газизем, бүген тәмам бирергә вәгъдә куеп җибәрделәр. Безнең әткәйләр, башкалар әткәсе кеби, шәфкатьле, балаларының сәгадәткә ирешүен теләүче түгелләр икән! Һәр икебезнең гомергә рәхәтебезне җуярга сәбәп булалар, ахры. Әнкәйгә разый булмаганымны белдереп карадым, миһербанлы әнкәем, бичара, үзе дә бер дә бирәсе килми, әткәйгә җалынып карады, күндерү мөмкин булмады. Сөекле Фатихым! Шулай ук аерылырбыз микәнни? Һәрвакыт, кайчан гына сиңа барып тора башлармын икән, дип уйлый идем. Синең кәефең өчен һәр эшкә разый булачак идем, бәхетсез икәнмен, моңа кадәр генә дөнья мине бәхетле кеби алдап торган икән. Газизем, миндә бер чара да юк. Ахыр өмидем синдә калды. Сез – ирсез, бу эшне бетерергә, туктатырга бер чара табарсыз. Сез дә бер чара таба алмасаңыз, хуш, сау бул, сөеклем. Безгә дөньяда рәхәт булмас инде!»*

Фатихка Рәбиганың бу хаты бик каты тәэсир итте. [...] Язу өстәленә утырып, өч хат язды. Өмиде шул хатлар илә эшне туктату иде. Хатларның берсе Рәбигага, [...] калган ике хатның берсе Хөсәен абзыйга, берсе кемгә икәне мәгълүм түгел иде.

VI

(Халидкә бирү вәгъдәсеннән бер көн соңра)

Бүген, кешегә фаш итми генә, Рәбигага никях булып, кичкә кияү керәсе булганга, Хөсәен байлар йорты эчендә, шау-шу өстеннән генә караганда, гүя шатлык иде. Бичара Рәбига бер бүлмәгә яшерелде. Моңа сәбәп гакыллы җаучы булды: андаен вакытта котыртучылар күп була, имеш, шуңа күрә кыз янына кеше кертергә ярамый, имеш. Рәбига бичараның ялгыз бер бүлмәдә егълаудан башка шөгыле юк иде. Рәхимле Латифә абыстай кызының бу хәлен игътибарга алды, Рәбиганың ятып елаганын күреп, туры җаучыга: «Ай-һай, Маһруй абыстай, бу эш хәерле булыр микән?

---

*Ахыры. Башы журналның 11 нче (2018) санында.
Әсәр «Садретдин бин мелла Низаметдин әл-Максуди. Мәгыйшәт. Милли роман. Казан, Берадәран Кәримевләр матбагасы, 1900 ел» исемле китаптан кыскартып бирелә.

Кыз бик җылый», – дигәч: «Яшь кызга җыламый китү үзе килешми, Латифә, ...хәзер еласа, кияүгә баргач, көләр. Безнең әнкәй әйтә торган иде: кияү керәсе көн елау – киләчәктәге бәхет галәмәте, дип».

Кияү керергә берничә сәгатьтән ары калмагандыр, ыгы-зыгы эчендә Фатихның Хөсәен абзыйга язган хаты Латифә абыстай кулына иреште. Латифә абыстай Хөсәенне бер бүлмәгә чакырып, кемнән икәнен сөйләгәч, хатны Хөсәенгә бирде. *«Хөрмәтле Хөсәен абзый, миһербанлы Латифә абыстай! Гафу итегез, кызыгыз Рәбига илә елдан артык мөнәсәбәтебез булып, арабызда бер-беребезнеке булырга вәгъдәләребез дә бардыр. [...] Бер кешенең вәгъдә вә гакаидле сөйгәне ул кешенең әткәсенә шәригатебездә дөрес түгелдер, ягъни Рәбига минем гакаидле зәүҗәм булганга, әткәйгә асла дөрес булмыйдыр. Шуның өчен тиздән бу тугърыны әткәйгә белдерегез, юкса, кызыгызны харап иткән өстенә, гөнаһлы буласыз. Фатих Алтынбаев».*

– Ах, оятсыз! Шыпырт кына, эчтән тынып калмастан, оялмыйча хат яза тагын! Менә җүнсез!... Яратышсалар, бер оят, оялмаенча, ул эшне белгертү – икенче оят! Намуссыз икән!.. Бер малай сүзенә карап, Халид агайга кыз бирүдән каласы, имеш?!

Кияүнең килер сәгатьләре йитте. Капка төбенә көтәргә кешеләр куелды. Рәбиганы, көчләп киендереп, кияү керәсе бүлмәгә җаптылар. Бервакыт: «Кияү килде!» – дигән хәбәр булды. Гаҗәп! Килгән кеше чалмалы, төсе дә Халид агайга охшамый иде. Килгән карт, кыз бүлмәсен сорамый, Хөсәен агайның үзен сорады, бу да гаҗәп! Ахырында беленде: килгән кеше кияү түгел, хәзрәт, имеш! Хөсәен чыгуга, янә бер карт чабып килеп керде! Хәер, бусының кияү булырлыгы да бар иде: сачын ап-ак итеп кенә ике яклап нечкәрткән, камчат бүрекне кыегайтып башына элгән, киң якалары чыккан иде. Бу Халид агай иде. Хөсәен, хәзрәт, Халид агай ишегалдында бергә җыелдылар. Хәзрәт, Хөсәен агайга карап: «Халидкә, кияү булып кергәнче, әйтәсе сүзем бар. Син безне аерым бер җиргә алып керсәнә», – диде.

Бүлмәгә керделәр, ишек бикләнде. Хәзрәт: «Халид, Хөсәен, син дә, тыңлап торыгыз! Мин сезгә бернәрсә укыймын», – дип, кесәсеннән бер язу чыгарып, укый башлады. *«Фазыйләтле остазым! Сезнең кеби адәмләргә хат язмак ни дәрәҗә әдәпсезлек идекене белсәм дә, язачак мәсьәләм бик мөһим булганга, сөкүт итеп калу мөмкин булмады. Бу хатны язмасам, берничә кеше гомергә вәйран булачак вә ничә кеше гөнаһлы булачакка күрә, мөнәсәбәтсезлек булса да, язарга җөрьәт иттем. Гафу боерыгыз! Бу көннәрдә, җәнабыгызның димләве буенча, әткәбез алачак кыз Рәбига – минем гакаидле зәүҗәмдер. Бер кешенең зәүҗәсен башкага бирергә һичкемнең ихтыяры юктыр. Шәригатьтә кызның ризасы олугъ шарт булып та, никях вакытында кыздан ник соралмый икән? Алма кебек кызларны дөньяда бер кат торып бетергән картларга бирергә шәригатебез куша микәнни? Остазым, бу мәсьәлә күптән каралып, хәл ителеп бетәргә тиеш иде. Ничә-ничә кызлар, маймун (маймыл) кеби картларга китеп, дөньяда гаилә сәгадәте, зәвеҗ (ир-хатын) мәхәббәте дигән нәрсәләрнең ни икәнен дә белмәенчә калдылар. Бичара Рәбиганы да, әткәйнең дәүләтенә кызыгып, Хөсәен агай вәйран итмәк эсти (тели). Гомумән, остазым, бу хатны алгач та, бу мәсьәләне ничек булса да бетерергә тырышсагызчы. Хөсәен абзый да, әткәм дә синең сүзеңнән чыкмаслар иде.*

Эстәсәгез, зәүҗәм булдыкына исбатка гакаидебез дә булганга, шаһитларыбыз да хәзердер...

Фатих бин Халид Алтынбаев».

Менә Фатихның өченче хаты шушы икән.

Халид, башын түбән иеп, бик күңелсезләнеп: «Хат, хат», – дип, тик утыра. Хөсәен:

«Хәзрәт, юк сүз ул, юк сүз, мин үз кызымны үзем беләмен, нинди шаһит булсын да, нинди гакаид булсын! Хәзрәт, шул малай сүзенә карап, эшне боза күрмә!»

Хәзрәт: «Юк, Хөсәен, бу эш булган булырга тиеш. Мин кызыгызны бик елый дип ишеттем. Гакаидләре, шаһитлары бәлки юктыр да, алай булса да, кыз илә егетнең күрешкән, утырышкан булуында шик юк. Күрешкән булгач, бар да Халидкә янәдән башка төрле хәрам буладыр. Эшне хурлыкка калдыруда файда юк. Кирәк булса, шаһитларын да табармын, дигән. Ләкин алай хасиятләндерүдә мәгънә юк».

Бу сүзләрне ишеткәч, Хөсәен агай, ишекне ныклабрак җабып, хәзрәткә актык сүзен әйтте: «Хәзрәт, булган эш булсын ла, сәдакасыннан эш калмас иде, шәригать үз кулыгызда, зинһар, бер җаен тапсагыз ла», – дип карады. Хәзрәт: «Әй, Хөсәен, син наданлыгыңа барасың. Ярамагач ярамый инде, синең аз-маз сәдакаң илә кеше шәригать алыштырамы соң?!» – диде.

Халид: «Юк инде, Хөсәен, бу эш булмады. Бу эш минем хурлыкка каласымга гына булган эш икән!»

Хәзрәт: «Инде әле әллә ни булмаган. Әле яхшы килеп өлгердем. Остазбикә, эшне бозмасын, дип, хатны бирми торган. Сез болай итегез инде: әле бу мәсьәлә халык арасына чыкмагандыр. Никях мәҗлесендә ят кеше юк иде. Мин хәзер Халидтән кызны аерыйм, Фатихның зәүҗәсе булган булса, никях вакыйгасы да булмаган буладыр. Алай булса да, аерыйк. Иртәгә, йә берсекөнгәме яхшылап туй ясап, Рәбиганы Фатихка никяхлыйк. Халык эшнең ничек булганын сизми дә калыр».

Халид: «Хәзрәт, мин ни әйтергә дә белмим», – диде.

Хөсәен: «Бу эш булмый торган булгач, бик яхшы булыр иде. Кыз баланы бар да бер тапшырасы. Халид абзый, шулай итик алайса», – дип куйды.

Хәзрәт үз сүзендә нык торды: «Халид, син белмәгәч, кем белер? Угълыңны өйләндерү, өстәлеккә, фарыз. Өйләндер. Шушы Рәбиганы сөйгәненә алып бир! Бу эш өчен бер дә ачуланма! Бу – яшьлек бәласе. Фатихка алып бирсәгез, халык бүгенге йөрүләрне кабул мәҗлесе дип кенә белер дә калыр. Менә мин дә аерыйм да, китим, Халид, сез дә кайтыгыз. Әле иртәгә күрешербез».

Шушы әмерләрдән соң, Рәбиганы Халидтән аергач, кияү булып килгән Халид агай, кияүне кертмәскә килгән хәзрәт – һәр икесе кайтып киттеләр. Бичара Рәбига котылды.

VII

Хәзрәтнең һәр ике якны да димләве, нәсыйхәтләп йөрүе аркасында, шул атна эчендә бик зур туй ясалып, Рәбиганы Фатихка никяхладылар. Халид агай, никадәр разый буласы килмәсә дә, язмышына каршы килә алмады. Ниһаять, ике адәм кулы тимәгән, яшь чәчәк кебек балалар бер-берсе илә кавыштылар. Зөфаф кичәсендәге шатлыклар, куаныч вә сөенечләргә чик юк иде. [...] Гомер буена бик садыйк, бик мәхәббәтле зәвеҗ вә зәүҗә булачакларына мең төрле вәгъдәләр куештылар.

Угълына яхшы, инсафлы кыз булынганнан – Хәлимә абыстай, кызының Фатих кеби бер акыллы егеткә китүенә Латифә абыстай – һәрбере бик шат иделәр. Инде Хөсәен абзый да бу эштән бик мәмнүн иде. Халид агай карт кеше булып, берничә еллардан барча малы Һәдия илә Фатихка калачагын уйлап, Фатих яшьрәк тә булганга, Халидтән дә артыграк файда итү мөмкинлеге булуын аңлады. Рәбига илә Фатихның парлануыннан куанмаган бары Халид агай иде. Сакал-мыек төзәтеп, бүрекләрне кыңгыр салып кияү булып барып та, кыз янына керә алмаенча кайтуына хурланганы күңеленнән китмәгән иде. Чөнки никадәр генә халыкка фаш булмады, дисәң дә, Рәбиганы башта Халид ала башлап та, соңра Фатихка туй ясалганын белгән кешеләр дә бар иде.

Фатих һәр көн зәүҗә мәхбүбәсе янына йөри иде. Фатихның киенеп китүләре, шатланып кайтулары һәрбере Халид агайга үзен мәсхәрә итәр өчен, аның ачуы килсен өчен йөргән кебек күренә иде. Шуның өчен Халид агай угълына һич сәбәпсез көннән-көн дошманлашмакта иде. Хадид агай, яшь хатын ала башлаганчы, ачучан, борчулы кеше түгел иде. Әмма шул өйләнә башлаганнан соң холкы бөтенләй бозылды, бар эше ачуланып, сукранып йөрү була башлады. Хезмәтчеләрне һич гаепсез ачулану, йорт җәмәгатьләрен һич сәбәпсез орышу-тиргәү гадәте булып китте. Йорты эчендә бигрәк тә ачуланганы Фатих иде. Ул бичараны шулкадәр тыгыз тота башлады ки, хәтта газета карарга да рөхсәт бетте, китап укыганны күрсә, буран чыгара иде.

Беркөн Халид агай Фатихны ачуланып, сәүдә дәфтәрләрен тикшереп утырганда, почтальон сурәтле «Нива» газетасын китереп ташламасынмы?! Фатих, шулвакыт һич гаебе булмаса билә, җиргә керергә разый булыр иде. Халид агайга эчендә сакладыгы ачуны, дошманлыкны чыгарырга җай чыкты: [...] бик ачуланып, хәтта кулларын күтәреп: «Зачим такуй газит таччиш! Мой сын ни урыс бит, такуй партрит русский таччиш!» – дип, русның артыннан кычкырып калды. Бу йортка газета кертүеннән шулкадәр эшләр чыгасы хәтеренә дә килмәгән рус чыгып котылганына куангандыр. Бәлки моннан ары картрак мөселман булган йортка газета кертергә шикләнгәндер дә. Рус котылды, әмма Фатих, бичара, бик авыр хәлдә иде. [...] Халид агай бу эш өчен угълы Фатихны эстәдеге кадәр сүкте, теләгән кадәр гарьләде. Кәефен җибәреп, күңелдән китми торган ямьсез сүзләр бар да әйтелде. [...] Һай, бичара Фатих! Әле ярый, җуанычы сөекле Рәбигасы бар иде, юкса, бичарага дөньясы бигрәк кәефсез булыр иде.

[...] Халид агайның күптәннән эчендә тоткан дошманлыгының газета мәсьәләсеннән соң очы чыкты: газета вакыйгасыннан бер көн соңра өстендәге киемнәре илә Фатихка ата йортыннан чыгарга әмер булды. Туган йортта торырга рөхсәт бетте, Халимә абыстайның җалынуы да файда бирмәде. [...] Фатих, бичара, кесәсендә булган берничә сумнар илә, туган йортыннан чыгып китте.

Әмма аның кеби егетлек патшасы, яшьлек үрнәге бер егет харап булырмы?! Һич! Фатихның, эткәсе йортыннан чыгып берничә көн торгач, иң беренче шөгыле әнкәсе Хәлимә абыстайга бабасыннан калган йортта торырга, банкада аның исемендәге акчаны алып, эш кыйла башларга эш йөртү булды. Хәлимә абыстай [...], ире Халид ачуланачагыннан да курыкмаенча, йортының һәм акчасының улына булуына куанып, разый булды. Бу кадәр акчаның угълы кулына калып, кызы Һәдиянең малсыз калу хәвефе дә юк иде. Чөнки Һәдиягә Халидтән калачак мал да йитә иде. ...Фатих, анасы йортына кереп, алдыгы акча илә үзенә күрә эш кыйла башлагач та, һаман һәр көн кич Рәбига янына бара иде. Үз хәленнән үзе мәмнүн иде. Атасы йортыннан чыкканга кайгыру юк, бәлки сөенә иде.

[...] Халид агай угълы Фатихның болай үзалдына эш кыйла башлавына бик эче пошты. Бердән, угълының газапланып йөрмәвенә, килеп керергә җалынмавына, икенчедән, Фатих чыкканнан соң сәүдә эшләренең тәртибе бозылганга бик кайгыра иде. ...Бу йортта Фатих булмаганнан соң, Халид агайның ачуын ала торган кешесе Хәлимә абыстай булып калды, чөнки йортын һәм акчасын киңәшми угълына биргәненә бик ачулана иде... Бервакыт Хәлимә абыстайга Фатихка барып йөрергә дә рөхсәт бетте! [...] Көннәрдән беркөн Хәлимә, угълыны бик күрәсе, хәлен беләсе килеп, Халид өйдә югында Фатихка барган иде [...] Халид агай, ерткыч хайван кеби булып, Хәлимәне ачуланды – тиргәде, хәтта гомерендә булмаган эш – берничә йодрык та эләктерде. Ачуы илә белештерми: «Тагы да Фатихка барасы булсаң, миннән «талак!» – дип ычкындырып куйды. Бу «талак» дигән сүз Хәлимәгә бик авыр бу-

лыр, дип уйлаган иде, кайда ул авыр тоелу, хәтта «талак» дигән сүзне ишеткәч, шатланган кеби булды, чөнки карт көнендә яшьтән сөйгән иреннән бу кадәр хурлаулар күрергә тәхәммеле калмаган иде. Иртәгесен Халид өйдә юк бер вакытта Хәлимә абыстай угълы Фатихка күчмәсенме?! Халид агай берсе көндә белештерми ычкындырган бу сүзенең әҗере нигә барганын белеп үкенде... Файдасыз... Хәлид агай никях яңартачак булды, әмма Хәлимә абыстай күнмәде. Хәзрәт димләп карады, файда булмады, чөнки Хәлимә абыстай, яңадан килсә дә, Халиднең иске борчулары, сәбәпсез каһәрләүләре туктамаячагын белә иде. Халид агай да, Хәлимәнең риза булмаганын белгәч, бик җалынасы килмәде. Шул көннән башлап кырык елдан артык җәмәгать илә торып үгрәнгән Халид абзыйга ялгыз көн итәргә туры килгән иде. [...] Ике хатын илә кыйланып, иркәләнеп гомер итәргә фараз кыйлып йөргәндә, бер хатыныннан да мәхрүм калмак, хәтта угълыннан да язмак бик авыр тоелган иде. Халид абзый башта сер бирмәскә тырышып йөрде, хәле никадәр читен булса да, угълына кайтып керергә әмер итмәде, җәмәгатенә яңадан никях илә килүне яхшылап әйттермәде.

Берничә вакытлардан соң гакыллы Фатих, әткәсенең хәле авыр булачагын белеп, газиз әткәсен кызганып, үзе һич кайтып керәсе килмәсә дә, үзен йортка кертергә үтенеп, атасын яңадан алырга димләп, әнкәсен күндерергә вәгъдә куеп, озын бер хат язып карады. Халид агай күнмәде. [...] Фатихтан хат алгач, бераз кәефләнеп китеп: «Менә шулай, җалынырсың! Алайса көн итеп булмыймы?! ...фәлән», – дип йөрде, [...] әлеге хатны кабул итмәгәч, Фатих янә үтенеп язар, дип уйлаган иде. Кешенең фикерен каян беләсең, бер кәррә хат язып, [Фатихның] өстеннән бурычы төшкән иде.

Халид агай ялгыз ашар, эчәр, кунар иде, чөнки кызы Һәдия дә әнисе белән бергә киткән иде. Аның кайтып торырына никадәр тырышса да, мөмкин булмады. [...] Халид агай бигрәк тә ашаган-эчкән чакларда уйга калып, моңаеп, ялгызлыктан җаны борчыла иде. Ашый-эчә торган бүлмәдә [...] искедән яратып алган Мисыр күгәрченнәренең гөрләүләре һәрбере Халид агайга: «Ай-һай, Халид! Кая китте элекке тормышың? Кадерен белмәдең! Инде сиңа байлык ни файда бирә?» – дигән кебек тоела иде. Бигрәк тә пар матур тавышлы күгәрченнәрнең матур-матур гөрләүләре: «Гакылсыз карт, мәхәббәтле хатыныңны ташлап, өйләнмәкче булдың, бер күңелдән ике мәхәббәт чыкмак мөмкинме?! Үзең адәм булып та, шуны аңламадыңмы? Сиңа бездән гыйбрәт алу кирәк иде. Бонча еллар гөрләшеп яшибез. [...] Без өчәү булса идек, бу рәхәт мәгыйшәтебез булмас иде. [...] Рәхәт, тыныч мәгыйшәт – пар яшәмәктәдер», – дигән кеби ишетеләдер иде. Кайсы бүлмәгә керсә – анда бушлык, кая барса – анда тынлык, ирексез, картның күңелен йомшатып, хафасын зурайта иде. Хыялый адәм кеби, кинәттән куркучан, уйчан була башлады. Намазга барганда-кайтканда бик моңаеп йөри иде, әүвәлге кеби хатын-кызга карап, ваксынып йөрүләр беткән иде.

Бара торгач, ялгызлык, үкенүләр Халид агайны гакылга китерде. [...] Дөньяның рәхәте – бала-чагаң, яшьтән алган, яшь мәхәббәт багълаган җәмәгатең илән тату тору, аларны рәнҗетмәенчә гомер итүдә икән... Ни өчен мин үз баламны үзем гарьләндереп куып чыгардым? Кеше балалары эчеп тә йөри. Әлхәмделиллаһ, угълымда андый эшләр юк иде. Угълымны үзем чыгарып җибәреп тә, аның өчен нигә Хәлимәгә ачуландым? Аны ник аердым?

Халид агай, ничек итсә итеп, Хәлимәне яңадан алырга уйлап йөргәндә, бик каты авыру эләгеп китеп, түшәккә егылды. [...] Әткәсенең авыруын ишеткәч, Фатих һәр көн икешәр килә торган иде. Һәдия дә әткәсе яныннан китмәде. Фатих берничә докторлар да китертеп карады, файда күренмәде, һәрбере өмит булмавын сөйләделәр. Фатихның эчкерсез булуына, хезмәт итәргә торуына Халид абзыйның күңеле бик йомшап, угълын кочаклап-кочаклап догалар итә иде. Авыруының унберенче көне

хәле бигрәк авыр кеби булды. Иртә торгач та, Халид агай угълын чакырып, елап: «Угълым, хәлем бик авыр, ахры, бу авырудан терелеп гомер итүләр булмас инде. Үлсәм үләрмен, Ходай Тәгалә иман илә үтәргә насыйп итсен. Ләкин бер эшкә бик эчем поша, күңелем кырыладыр: әнкәң хәзер дә миннән аерылган кеби торадыр. [...] Хәлимәгә яшь мәхәббәтем бетәсе юк, кыяматкә дә үзем илә барачак. Ходa насыйп итеп, җәннәткә кергәч тә, Хәлимә илә бергә булуны телимен. Ләкин, угълым, никяхымда калмагач, Хәлимә минем илә булмас, дип бик куркамын. Аның илә бәхилләшеп үтәр идем. [...] Әйтеп карасана, улым! Яңадан никяхка күнмәс микән?!» – диде. Фатих бу сүзләрдән соң, күңеле бик йомшап, яшьле күзләре илә әнкәсенә барып сөйләде. Хәлимә абыстай, күнмәү, разый булмау кайда, куанып, елап, разый булганын сөйләде. Никадәр җан бизгән кеби булса да, яшь мәхәббәт күңелдән китмәгән иде. Тол калса да, Халид агай никяхында калуны кальбе эсти иде. Хәлимә абыстай тиздән Халид агай йортына килде, тиз генә хәзрәт килеп, никяхларын яңартып китте. Бичара үлем түшәгендәге Халид агай илә Хәлимә абыстай бәхилләштеләр, елаштылар.

VIII

Халид агайның вафатыннан соң, Фатих әниләре илә бәрабәр атасы йортына күчеп тора башладылар. [...] Фатих илә Рәбиганың күңелләре рәхәт иде: мәхәббәт вә дуслыклары ниһаятьсез иде, бер-берсен күргән саен күрәсе, сөйләшкән саен сөйләшәселәре килә иде, һич бер-береннән туя алмас иделәр.

Фатих, зәүҗәсенең остазбикәдән үгрәнгән гыйлеме илә канәгатьләнми, һәрвакыт төрле нәрсәләр укыта иде, [...] бик яхшылап ислам тарихын, исламда булган зур адәмнәрнең ничек булганнарын, динебезгә, өммәтебезгә нинди файдалар китергәнен һәрберен өйрәтте. Фатих зәүҗәсенә күп сүзләр сөйләп, сораган бер сүзләренә [...] бик озын-озын бәянлар илә җавап биреп, Рәбигасының гыйлемен көннән-көн арттыра, фикерен киңәйтә иде. [...] Берничә вакытлардан соң, Рәбига бик тәрбияле, бөтенләй галимә бер ханым булып киткән иде. Рәбига, китаплар, газеталар укуны бик яраткан кеби, үзенә тиешле булган хезмәтләрне дә бик әда итеп, каенанасына, иренә, бөтен өй җәмәгатенә яраклы, аларның рәхәтенә тырышкан тәрбияле бер йорт анасы булып киткән иде.

Эшләре алда булып, зәүҗәсеннән дә уңганга, Фатих бик шат иде. Ходай Тәгалә, бара торгач, бу ике мәхәббәткә бер матур угълан багышлады. Фатихның искедән яраткан бер исеме бар иде, угълы булса, Рәшидбәк кушмак уенда иде. Әй, кечек Рәшид бик бәхетле бер бала икән! Чөнки Рәшиднең киләчәге бәхетле булмак өчен бер атасының галим фикерле булуы гына җитмәс иде, Рәшиднең кечкенәдән тәрбияле булып, яхшы сүзләр ишетеп үсеп, киләчәктә бер зур адәм булмакы өчен, Фатихтан бигрәк, Рәбиганың галим вә тәрбияле булуы бик зур шарттыр. Угълының бик тәрбия илә, ислам рухы илә үсеп, галим, диндар, һиммәтле, милли бер кеше булып, милләткә, дингә теле, фигыле вә малы илә файда итәрлек бер адәм булуын Ходадан тели иде.

Текстны басмага филология фәннәре докторы, профессор, Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнү институты әйдәп баручы фәнни хезмәткәре ***Әлфинә Сибгатуллина*** *әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

«Яңгыр җиле» яңгыр вәгъдә итә

Мөдәррис Әгъләм

«Нәни Гигант» белән (Зөлфәт Мөдәррис Әгъләмне шулай атый иде) бер елларда яшәп, бер юллардан йөреп, якыннан аралашып калуыма шатмын. Без алар белән, кул сузымы ераклыкта, дигәндәй, күршеләр булып та яшәдек. Зөлфәтләр белән Казанда, Мөдәррис белән язучыларның Аккош күлендәге иҗат йортында. Хәтта бер өй, бер коридорның терәлеп торган бүлмәләрендә.

Мөдәррис һәрвакыт җитди. Башы язылачак шигырьләр белән шыплап тулган. Шуңа күрә, беркем белән дә күп сөйләшеп, «суган сатып» тормый. Соңгы елларда Шаһгали (Сөембикә ханбикәбезнең көчләп ярәштерелгән ире) турындагы поэмага материал туплавы турында да әйткән иде. Фаилнең вафатын да бик авыр кичерде ул. Эчтән сызып, эчтән янып:

«...Аккош күле. Сулый иҗат йорты,
Җиңәлмәде ул төн яктылыкны,
Җыр тантана итте өстәлдә...» –

дип язды ул, үзенең Фаил Шәфигуллин ядкәренә багышланган «Тәрәзәдән төшкән ут» исемле шигырендә.

Хәтерлим, 1984 елның көзе. Берничә шагыйрь һәм берничә җырчыны Казанның Мехчылар клубына очрашуга чакырдылар. Шунда миңа сүз бирер алдыннан, Мөдәррис, «Яңгыр җиле» исемле китабымны кулына алып: «Яңгыр җиле» яңгыр вәгъдә итә. Фаил Эльмирага үзенең җенен калдырып китте», – дигән иде. Бераздан ул бу китапка карата үзенең бәяләмәсен дә язды. Ләкин язма матбугатта басылмыйча калды.

– Үзеңдә торсын, – диде ул, беркөнне «Ялкын» журналындагы эш бүлмәмә шушы материалны кертеп. – Китап чыгарганда бастырырсың.

Иҗатым турындагы язмаларның кайберләре быел чыккан «Каюм коесы» исемле китабымда дөнья күрде, тик күләм чикле булу сәбәпле, «Нәни Гигант»ның «фәрманы» үтәлмәде. Аның «Уйлый ла күңелем төрлесен» дигән мәкаләсен урнаштыру белән чикләнергә туры килде.

Язылуына утыз елдан артык вакыт үтсә дә, әлеге язма укучы өчен дә кызыклы булыр, дип уйлыйм.

Мөдәррис сүзе бит ул!

Эльмира Шәрифуллина

«Яшь шагыйрьнең беренче[1] китабы». Бу серия астында инде берничә дистә шигырь китаплары чыкты. Белүемчә, ул Фәннур Сафинның китабы белән башланган иде. Китапның исеме дә алдан күргән кебек мәгънәле иде: «Кеше юлга чыга». Сериянең башлангычы булган бу китап исеменә аңлатма бирүнең кирәге дә юк. Чынлап та бик күпләр шигъри олы юлга чыктылар. Бу исем астында беренче китабын чыгарган Фәннур Сафин бүген Муса Җәлил, Әхмәт Ерекәй, Сибгат Хәким, Мостафа Ногман, Гөлшат Зәйнашева кебек, җыр шигырен үстереп җибәреп, җыр яратучы халыкның үз шагыйренә әверелде.

Әмма дистәләгән китап арасында вакыт уза-уза хәтердә калганнары берничә генә: Эдуард Мостафин, Зиннур Мансуров, Нурия Измайлова, Лена Шакирҗанова, Наил Зәйнуллин. Бик тә санап китәсе килә, тик санарга чама юк. Калганнары йә уртакул, йә уртакулдан да түбән... Шуңа күрәдер дә бу әйберләр, «Яшь шагыйрьнең беренче китабы» дәрәҗәсенә күтәрелә алмыйча, аннан-моннан җыйган җыентык хәлендә җир белән күк арасында асылынып калдылар. Акыл бар, шигъри техника бар, олы вәгъдә һәм зурга ымсыну бар – китап юк! Матур-матур шигырьләр бар, шул шигырьләрдән әвәләнгән җыентык бар, китап юк! Чөнки шагыйрь юк. Ә шагыйрь бирергә килә! Хәтта кәгазь дә бирергә түгел, алырга килгәннәрне бик тиз сизеп ала. Шуңа күрә дә ак кәгазь бит ул! Үзен пычратканны ул да яратмый.

...Әлбәттә, һәркемнең күңел сагышы – үзенчә, күге – үзенчә.

Мөдәррис Әгъләм Казан педагогия көллиятендәге кичәдә чыгыш ясый. Утырганнар: Госман Садә (сулдан беренче), Рәйсә Яхина һәм Марат Гайнетдинов. 2002 елның 14 марты

[1] Беренче лирик шигырьләр китабы, дип аңларга кирәк. Чөнки 1976 елда балалар өчен «Безнең зоопарк» исемле китабым чыккан иде.

Шигырь китапларын укыганда күңелгә шундый уйлар килә... Бармы соң бу шигъри тәртипкә салынган юлларда күңелнең әнә шундый көтелмәгән, сәер капризлары, серле борылышлары? Бармы аларда шатлык һәм кайгыларның бергә кушылып дулавыннан хасил булган ярсу шарламалар? Шуларның барысын да тоясы, күрәсе, үзеңнеке итеп кичерәсе килә.

Яңгыр җиле... Табигатьнең гаять серле халәте... Капылт кына исеп куйган бу җилдә барысы да бар: яңгыр көткән тереклекнең кузгалуы да, өмет тә, моң да...

Шигъри хис тә – күңелдә табигатьнең шундый бер халәте буларак туа».

Бу – шагыйрь Зөлфәт. Шагыйрә Эльмира Шәрифуллинаның «Яңгыр җиле» исемле китабына шагыйрьнең кереш сүзеннән.

Зөлфәт кадәр вакчыл, үз-үзенә микроскоп белән карар дәрәҗәдәге таләпчән шагыйрьнең сүзләренә ышаныр-ышанмас кына, беренче битне ачам. Күземә юлыккан беренче юлларны укыйм:

«Һәлак булган бәхет өчен туган бала.
Сугыш – үлем, сугыш – кабер, сугыш – яра...
И, кешеләр, кабер казыйк сугышка да!»

Кинәт кенә каяндыр хәтер төбеннән Саҗидә апа Сөләйм螺нованың кырыс һәм кешелекле шигырьләре калка. Халыкта «бала йоннары кабарган» дигән бер төшенчә яши. Бу юлларны укыганда әлеге тәгъбирнең юкка гына әйтелмәгәненә ышанасың. Китапка гади күзәтү генә язарга мөмкин, андый күзәтүне яза да торалар – анысы булыр-булмас тәнкыйтьчеләр эше. Бу очракта мин, шагыйрь буларак, үз сүземне әйтми кала алмыйм. Кешелекнең һәлакәткә иң якын торган вакыты. Әлеге хакта партиябез, хөкүмәтебез һәр көн искәртеп тора. Шагыйрәнең сүзләре бу көннәрдә тагын да көчлерәк яңгырый:

«...Булды хәлләр...
Дошман безнең иңдә
Сынамаган корал калмады.
Чикләребез янды,
Йортларыбыз...
Иманыбыз, ләкин,
Иманыбыз,
Иманыбыз безнең
Янмады!»

Әнә шул коммунистик иманга бирелгән шагыйрәнең һәрбер сүзе күңелдә яши икән – бу халык уе, халык фикере, халык сүзе. Бер ачы хакыйкать бар. Шагыйрь халыктан башлана да халыкта дәвам итә.

Биредә – шагыйрә. Шуңа да без аның үз җенесе исеменнән язылган юлларны егетшагыйрә юллары дип кабул итәбез:

«Тупасланган иде безнең куллар
Сез сугышта йөргән чакларда.
Җир тырнашып кара җирне сөрдек,
Калмас өчен җирдә ятларга».

Монысы – җилләр сүзе. «Ятлар». Бу төшенчә элек-электән бездә читкә киткән

кешенең сөйгән яры чит кешегә калуы белән аңлашыла. Ә биредә бөтенләй башка мәгънәдә. Идел буена кадәр килеп җиткән шомлы афәт – дошман явы. Менә ул ятлар! Әнә шул ятлар кулына калмас өчен җир тырмашып кара җирне сөрүче әниләрнең йөрәктән суырылып чыккан сүзләре бу!

Эльмира Шәрифуллина исеме шигърияттә электән күренгәләсә дә, тулы тавыш белән күзгә күренер дәрәҗәдә соңгы берничә елда үсеп китте. Тыныч кына аккан элекке шигъри юлларында, нәкъ менә Зөлфәт әйткән «күңелнең көтелмәгән сәер капризлары, серле борылышлары, шатлык белән кайгыларның бергә кушылып дулавыннан барлыкка килгән ярсу шарламалар» пәйда булды. Матбугат, шигырь сөючеләр бу үзгәрешкә битараф калмады. Шигырьләре газета-журналларда басылды, эфирдан яңгырады, сүзләренә көйләр язылды, шагыйрьләр секциясендә тикшерелеп, уңай бәя алды. «Яңгыр җиле» дип исемләнгән бу әйбәт китапның үткән юлы әнә шул. Һәрбер беренче китапның үткән юлы әнә шул тәртиптә бара. Әмма бу юлда Эльмира Шәрифуллина күзәтүче генә булмады, үзе дә үзгәрде, үсте. Яңадан-яңа шигъри үлчәмнәргә мөрәҗәгать итте. Бертөрлелектән качу аңа яңа шигъри уңышлар алып килде. Еш кына яшь шагыйрьләр, үзләренең беренче уңышлы шигырьләреннән соң, үзләренең шул шигырьләренә ияреп яза башлыйлар. Шигъри калып бер үк – ул шагыйрьне ирексездән үзен-үзе кабатлауга алып китә. Күңелдәге һәрбер хиссиятнең, һәрбер үзгәрешнең үз шигъри калыбы булырга тиеш. Сөйләмгә корылган эпик әсәрләрдә бертөрле үлчәм әле акланырга да мөмкин. Ә кешенең бер рухи мизгелен тасвирлаганда бу тәҗрибә «чиләктә он иләү, иләктә су ташу» кебек мәгънәсез бер хезмәттер.

«Яңгырлардан, җилләрдән соң
Гомер көзендә шулай
Сискәнеп куямы күңел,
Әбиләр чуагыдай».

«Гомер көзе»

«Саҗидә апа,
Ап-ак керләреңне
Чайкагансың икән тирәндә.
Ак сурәтең калды күңелләрдә,
Пакь эзләрең
Яшел чирәмдә».

«Саҗидә апа»

«Бишкә төрлән,
Әмма хыянәттә
Яклау эзләп мескен җаныңа,
Төрле төскә керә күрмә, балам,
Авыр хәлдә калган минутта».

«Теләк»

Учымда җилпенә, әйтерсең,
Әнисен таныды...

«Күбәләк»

Һәрберсенә үзенең агышы, үз моңы табылган. Кемгәдер ияреп язылмаган, антик дөньядан, тарих, археология, философия китапларыннан килеп кергән тел әйләнмәслек терминнар да юк. Үзебезнең халык теленнән, шул байлыкка таянып

халыкның үз шагыйренә әйләнеп киткән М.Җәлил, Ф.Кәрим, Х.Туфаннар иҗаты белән расланган хәзинәбездән үсеп чыккан кешелекле юллар:

«Нишлисең? Тукта!?» – дип хәзер
Язмышыма дәшимме? –
Керфекләремне көйдерә –
Яшемме бу,
Яшенме?»

Соңгы еллардагы шигъри хәзинәбездә чик-чаманы югалтып ике якка ташлану күзәтелә. Берсе – аның кешенең нинди генә халәтен, нинди генә кичерешләрен җырлаганда да һаман шул уңга-сулга үлчәменә (сүзләренә) дыңгычлап тутыру. Икенчесе – көтелмәгән яңа әйләнмәләр, яңа образлар ялтырап китүенә дә карамастан, бернинди киртәгә дә сыймыйча ызаныннан чыгып чәчелгән җир өстеннән дулап чапкан ат кебек, җөмләләрдән торган шигырьләр. Вакыты белән «аш төрләндерү» өчен алар кызыклы чыга. Әмма күпкә киткәч, ул сагайта башлый. Ә инде халык теленең байлыгын, аның мөмкинлекләрен түземлелек белән өйрәнүдән качарга теләгән яшьләр өчен бу яңа ачыш булып күренә.

Әнә шундый шигырьләрдән соң, Нурия Измайлованың беренче китабын сөенеп укыган идем. Менә хәзер Эльмира Шәрифуллина китабын.

Китап өч бүлектән тора. Шигъри бүлекләр шартлы рәвештә генә бүленгән дигән тәэсир кала. Шигырьләрдә төп юнәлеш – Җир язмышы өчен борчылу, Җир язмышына бәйле рәвештә кешенең киләчәге, аның дәвамы булачак балаларның олы җанлы, миһербанлы булып үсүләре өчен кайгырту. Күп очракта бу фикерне шагыйрә икенчел мәгънәгә күчереп әйтсә, кайбер очракларда публицистик кайнарлык белән декларатив формага күчерә:

«Ал кайгымны!
Син көчлерәк миннән,
Юатырдай таянычым синдә,
Таянырдай юанычым синдә,
Ярый син бар,
Җирем,
Җир генәм!»

Шагыйрә китабын «Яңгыр җиле» дип атаган. Әйбәт исем. Мәгънәле исем. Шулай ук җиргә бәйле. Яңгыр җиле яңгыр вәгъдә итә. Эльмираның бу китабы исеме кебек җиләс, исеме кебек вәгъдәле. Киләчәктә без аның җылы яңгырларын да көтеп калабыз.

1984 ■

Шагыйрь Бәдрүш Мокамай

БАТЫРОВЛАР ГАИЛӘСЕ

Линария Бәдретдин кызы Батырова, бер тын алгач:

– Мин 1 сыйныфны Дүртөйленең 1 нче мәктәбендә тәмамладым, – дип, сүзен дәвам итте. – Тәүге укытучым Анна Васильевна Сазонованы бик яраттым. Соңрак авырып китте бугай, икенче укытучы укыта башлады. Анысын яратмадым инде, мәктәпкә бармас өчен елый идем. Аннары без Веялочный заводка[1] күчендек. Андагы башлангыч мәктәптә әни укытты.

Мәктәпне тәмамлагач, әни мине Уфага, авыл хуҗалыгы институтына укырга керергә кыстады. Ләкин анда укыйсым килми иде. Имтиханнарны тапшыра алмыйча, шатланып кайттым. Әнинең кәефе кырылды, каядыр хатлар да язып карады. «Бер ел буе нәрсә эшләрсең инде», – дип кайгырды.

Зинаида Алексеевнаның[2] ире Шәриф абый мине Баргызбаш урта мәктәбенә укытучы итеп урнаштырды. Әлбәттә, мин балаларны ярата идем, укучылар белән уртак тел таптым, әмма 10 сыйныф тәмамлаган кыздан нинди укытучы чыксын? Дәресләргә әзерләнергә, план төзергә, дәфтәрләр тикшерергә кирәк. Әнинең ничек эшләгәнен дә күреп үстем, хәтта: «Беркайчан да укытучы булмаячакмын!» – дип ант эчкәнем булды.

1956 елның җәендә Дөртөйлегә комсомол путевкасы буенча «Шкаповнефтьстрой»га эшкә чакыру килеп төште. Мин, сеңелем Эмманы ияртеп, шунда юл тоттым. Безне Приют бистәсеннән арырак Ык елгасы буена алып барып урнаштырдылар. Анда палаткаларда яшәдек. Карьерда таш ваттык, аны машиналарга төядек.

Бераздан Приют тулай торагыннан бүлмә бирделәр. Беркөнне безнең тулай торакка Хәлим белән Җиһангир исемле ике дус егет килде. Хәлим мине күреп гашыйк булса да, бу хакта сүз әйтмәде, фәкать даими килеп йөри башлады. Бераздан аралашуга, бергә урам йөрүгә күчтек. Баштарак очрашасым килмәсә дә, соңрак бик яхшы кеше булуын һәм гомеремне бары тик аның белән генә бәйләргә теләвемне аңладым.

Алай да, ул вакытта кияүгә чыгарга ниятем юк иде әле. Көннәрдән беркөнне шундый вакыйга булды. Мине комсомол оешмасы секретаре урынбасары итеп сайладылар. Взнослар җыям, лотерея сатам, үзем тулай торакта тәрбияче булып та эшлим. Лотерея билетларының берничәсе сатылмый калды. Язгы көннәр бу, ташу киткән чак. Сәркатип Ык-Вершина авылында иде. Анда бару өчен Ык һәм тагын бер елга аша кичәргә кирәк. Өстемә – плащ, аягыма итек киеп, соңгы сеанс кинодан соң сәркатип янына барырга булдым. Каршыма машиналар очрый. «Бу караңгыда кая барасың?»

[1] Башкортстанның Дүртөйле районындагы авыл. Бүгенге көндә Җилгәргечләр исемен йөртә.
[2] Архипова (Исхакова) Зинаида Алексеевна – Клавдиянең (Бәдрүш Мокамайның хатыны) сеңлесе.

Бәдрүш Мокамайның фронттан язган хатлары

– дип, туктап сорыйлар. Кая барганымны белгәч: «Ык-Вершинага үтә алмаячаксың, елга ташыган, кире борыл», – диләр. Шундый мөһим эш белән кузгалгач, кире борыламмы соң? Юк, әлбәттә. Юл пычрак, озак бардым, караңгы төште. Елга янына барып җиттем. «Кешеләр яисә машиналар елганың аръягына ничектер чыга бит. Димәк, мин дә чыгачакмын», – дип уйладым. Елгага аягымны сузган идем генә, су мине үзенә суырып алды. Котылырга тырышып, итекләремне шудырып төшердем, өстемнән плащымны салдым. Көчле елга агымы мине йомычка кебек бөтереп кенә йөртә: әле су төбенә китәм, әле өскә калкам. Кырыйга йөзеп, яр буендагы бозга тотындым. Ләкин, ул ватылып, тагын агып киттем. «Көчем дә бетеп бара, туңдым да, аяк-кулым тыңламый башлады. Елга Октябрьскига кадәр барып җитә, дип сөйлиләр. Мәетемне шул тирәдә табып алырлар инде. Үлемем турында әнигә хәбәр итсәләр, ул акылдан язачак», – дип уйлыйм үзем. Шулвакыт соңгы көчемне җыеп, яңадан ярга таба йөзеп киттем, ниһаять, яр буендагы бозга тотындым. Бусы нык булды. Шулай үзебезнең якка үрмәләп чыктым. «Кая барырга?» – дигән уй төште. Аяк-кулымны көзән җыера башлады. Якында гына бер авыл барлыгын беләм. Ләкин анда кадәр барырга, аны табарга кирәк бит әле. Бераз баргач, ике землянка күрдем. «Болай булгач, исән калам!» – дигән уй башымнан йөгерде. Берсе янына килеп, ишек шакыдым. «Ишек ачык, керегез», – диләр. Ә минем кулым шакыраеп каткан, һич күтәрелми! Үкереп елаган бала тавышы ишетелде. «Курыкмагыз, ишекне ачыгыз, кулларымны көзән җыера, үзем ача алмыйм», – дидем. Алар мине бусагадан уздырды. Хатын-кыз җыелышты. Арадан берсе кырлы стакан тутырып көмешкә салып бирде: «Эч!» – дип боерды. Өстемне салдырып, коры кием-салым бирделәр, аяк-кулларымны уып, караватка төреп яткырдылар. Көмешкәдән йомшарып, йоклап киткәнмен. Иртән торгач, нәрсә булганын сораштыра башладылар. Барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирдем. Землянка хуҗасының улы Хәлим һәм Җиһангир белән бергә эшли икән. Тегеләргә барып хәбәр итте. Хәлим башка сменада булып, минем янга Җиһангир килде. Аны

кочаклап елый башладым. Хатыннар: «Кияү егетемени?» – диләр. «Юк», – димен. Башымнан кичкәннәрне Җиһангирга да сөйләдем. Бер машина белән Приютка кайттык. Шуннан Хәлим килде, аның белән бик озак сөйләшеп утырдык... Иң гаҗәбе: шулкадәр салкын суда шулкадәр озак чупырдавыма карамастан, мин, бала чактан чирдән башы чыкмаган кеше, һич авырмадым. Таныш табиб даими тикшереп торды.

Шушы вакыйгадан соң Хәлим көн саен диярлек килә башлады. Бераздан өйләнешү турында сүз кузгатты. «Әнием өчен борчылам, ул үги әти белән яши. Аерылыша калсак, үги әти: «Кызың юньсез булып чыкты, аның белән ире дә озак яши алмады», – дип битәрләячәк. Өйләнешүгә рөхсәт сорап әти белән әнигә хат яз. Алардан уңай җавап килсә, кияүгә чыгармын», – дидем. Ул хат язды. Уңай җавап килде. «Иртәгә эшкә барма, ЗАГСка гариза бирәбез», – диде. Икенче көнне эшкә бармадым, Хәлимнең килгәнен көтеп утырдым. Ә ул... килмәде! Мин кешеләр турында беркайчан да начар уй уйламыйм. Алдады, ташлады, дигән фикер башыма да кермәде. Бер-бер нәрсә булгандыр, дип гөманладым. Чынлап та, шулай икән: эшендә авария булган. Ул вакытта телефон-мазар юк, ничек хәбәр итсен?! Гафу үтенде. Икенче көнне ЗАГСка бардык. Безгә шунда ук таныклык язып бирделәр. Шулай итеп, Хәлим Миңнегәрәй улы белән 1957 елның июнендә өйләнештек.

Озак кына мин үз тулай торагымда, Хәлим үзенекендә яшәде. Аннары аңа аерым бер бүлмә бирделәр. Кызым Эльмира тугач, ике бүлмәле фатирга күчендек...

Приют бистәсендә яшәгәндә үк төзелеш институтына документларымны тапшырдым. Ирем моны хуплады. Бераздан Бәләбәйгә, андагы яңа, әле исеме дә тәгаен билгеләнмәгән урамдагы йортка күчтек. Көтәм-көтәм, имтиханнарга чакыру килми. Институтка үзем бардым. «Без Сезгә чакыру җибәрдек, инде берничә имтихан үтте, кайда йөрдегез, ник килмәдегез?» – диләр. Мин елап җибәрдем.

Өйгә кайткач, ирем белән сөйләшеп, Бәләбәй медицина училищесына керергә булдым. Бу 1962 елда иде. Анда бик җиңел кердем. «Биш»ле билгеләренә генә укыдым. Балаларны яслегә урнаштырдык. Хәлим миңа бу вакытта бик нык ярдәм итте. Сабыйлар авырып лекцияләрне калдырсам, бергә укыган кызлар дәфтәрләрен алып киләләр, ә ирем дәресләрне күчереп яза иде...

1966 елда Хәлимгә бер танышы, Бөгелмәдә ТатНИПИда[3] эш бар, анда синең сыйныфташың эшли, дигән. Без, икәүләп, шул шәһәргә килдек. Ирем эш урынын күрергә китте. Мин шәһәр белән таныштым, монда кибет киштәләре сыгылып тора (Бәләбәйдә азык-төлек ягына кытлык иде.) Хәлимгә өлкән инженер вазыйфасы һәм төзелеп килә торган йорттан өч бүлмәле фатир вәгъдә иткәннәр. Бераздан без гаиләбез белән Бөгелмәгә күчендек. Авылга кайткан саен әнием генә: «Шул ач Татарияга киттегез лә», – дип көрсенә иде. Мин исә, киресенчә, һәрвакыт: «Анда һәрнәрсә бар, мул һәм җитеш тормышта яшибез», – дип сөйләдем.

Монда мин тире-венерология диспансерына эшкә урнаштым. Аннары үзәк дәваханәнең лор бүлегенә күчтем, анда егерме биш ел эшләдем, – дип, хезмәт гомерен йомгаклады Линария Бәдретдин кызы.

Батыровлар илле ике ел тигез гомер кичерә, өч бала тәрбияләп үстерә. «Балалар барысы да татарча начар белә. Мәктәптә дә татарча укыту начар оештырылган иде, ирем белән мин дә аларга ана телен өйрәтүгә җитди игътибар бирмәгәнбез. Оныкларыбыз туган телне бөтенләй белми», – дип көрсенгәндәй итте Линария Батырова.

Ире Хәлим Миңнегәрәй улы 2009 елда вафат булган.

[3] ТатНИПИ – Татар нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау институты.

Туганнар каберлегендә Бәдретдин Мөхәммәтҗановның исеме язылган таш

АТА КАБЕРЕ ЯНЫНДА

Линария Бәдретдин кызының сүзләре аның белән генә бетми әле:

– 1972 елда әтинең кабере табылу турында хәбәр килде. Әни хасталый, кан басымы югары. Аның белән киңәшләшкәч, юлга үзем кузгалырга карар иттем. Эш урынымда бу хакта әйтеп, юлга чыктым. Мәскәүгә барып җиттем. Казан вокзалыннан Рига вокзалына юнәлдем. Ике вокзал – җир белән күк аермасы иде! Биредә үзеңне Советлар Союзында дип түгел, чит илгә килеп эләккәндәй хис итәсең. Поезд да мин Мәскәүгә килгәннән бик нык аерыла, проводницалар башка, мөнәсәбәт башка...

Ригага килеп җиттем. Аннан Елгава шәһәренә кырык чакрымнан артык барасы. Поездга утырып, сәфәремне дәвам иттем. Вагонда күршемә кая һәм ни өчен баруым турында сөйләп бирдем. Ул, поезддан төшкәч, хәрби комиссариатка бару юлын күрсәтте. Минем аптырап торуымны күреп, үзе үк озатып та куйды.

Хәрби комиссариатта шулай ук яхшы каршыладылар, кунакханәгә шалтыраттылар, иртәгә әтиегезнең каберенә барачакбыз, диделәр. Елгава бик матур урында урнашкан, аны уртага бүлеп, Лиелупе елгасы ага. Шәһәр белән танышып йөрдем, истәлекле урыннарында булдым. Кунакханәдә кундым. Иртән чәчәкләр сатып алдым. Хәрби комиссариатта хатын-кыз – авыл советы рәисе көтеп тора иде. Машинага утырып юлга кузгалдык. Туганнар каберлеге Сидрабенес волостена кергән Салгалес скола утары янында, чыршы урманы эчендә урнашкан икән. Каберлек койма белән уратып алынган. Биредә 482 совет солдаты җирләнгән, барысының да исемнәре билгеле. Каберләргә яугирләрнең исем-фамилияләре язылган унбиш таш һәм бер истәлекле билге куелган.

Аның янында гына мәктәп-интернат бар. Укучы балалар каберлекләрне карап тора. Әтиемнең каберенә чәчәкләр салдым. Авыл советы рәисе кайтып китте...

Якын-тирәдә кешеләр яши икән. Ләкин ул авыл түгел, ә аерым утар (хутор) гына. Анда мине лаеклы ялга чыккан укытучылар гаиләсе белән таныштырдылар. Ире шортиктан иде. Моңа кадәр чалбарсыз йөргән ир-егетне күргәнем булмагач, бу минем өчен бик гаҗәп тоелды. Йортлары аерым тора, койма белән уратып алынмаган. Зур бакчалары бар, анда бер эздә буеннан-буена кишер, икенчесендә кәбестә, кукуруз, кызыл чөгендер, башка яшелчә үсә иде. Аларда мин бер төн кундым.

Икенче көнне хәрби комиссариат биргән машина мине алырга килде, йөртүчесе: «Кире кайтырга билетыгыз бармы? Булмаса, Елгава вокзалында ук кереп билет алыгыз, – дип киңәш итте. – Әтиемнең каберен күрергә килдем, ничек кайтып китәргә белмим, билетым юк, дип әйтегез». Вокзалга кереп ул әйткәнчә гамәл кылгач, шунда ук билет бирделәр.

Латвиягә сәфәремнән җанда бары тик уңай хис-тойгылар гына калды, анда ярдәм иткән кешеләрне бүгенге көнгә кадәр рәхмәт сүзләре белән генә искә алам.

САМАТ ШАКИР

– 1983 ел. Мин, авырып, хастаханәдә ята идем. Беркөнне телефонга дәштеләр. Ирем шалтырата. Казаннан Самат Шакир дигән язучы килде, әтиең белән кызыксына, ди. Табиблар белән сөйләшеп, төн кунарга өйгә кайтып киттем. Аның белән таңгача сөйләшеп утырдык. Ул әтием белән таныш булган, Казанда очрашканнар икән. Әти Казанда Муса Җәлил белән дә очрашкан, аңа үз шигырьләрен күрсәткән. Ул Казанны яраткан. Әниемә дә, исән-сау кайтсам, Казанда яшәячәкбез, дип язган.

Мин Самат Шакирга әти фронттан язган «Линарияга хатлар»ны бирдем. (Ул соңыннан аларның барысын да (әтинең язмаларын, хатларын) миңа кире кайтарды.) Хәбәрләшә башладык. Тиздән китап чыга, дип язды. Чынлап та, 1984 елда Бәдрүш Мокамайның Уфада, башкорт телендә «Линарияга хатлар» дигән китабы дөнья күрде. Анда Бөек Ватан сугышы турында миңа багышлап хатлар рәвешендә язылган унике хикәясе, шигырьләре, «Таня» поэмасы, «Кан өчен кан» пьесасы һәм хатлары керде. Самат Шакир китапның берничә данәсен безгә дә җибәрде. Мин аңа бу хезмәте өчен аерата зур рәхмәтлемен. «Линарияга хатлар» китабы кибетләргә чыккач, үзем дә сатып алдым, барлык таныш-белешемә, дусларыма өләштем.

1989 елда әтинең 80 еллык юбилеенда катнаштым, Каеш авылында, Дүртөйленең 1 нче һәм Иске Яндыз мәктәпләрендә булдым, чыгыш ясадым. Очрашуда галим Миңнегали Нәдергулов Бәдрүш Мокамайның иҗаты турында сөйләде, шагыйрә Зарема Әхмәтҗанова шигырьләрен укыды.

Әтиемнең 90 һәм 95 еллыклары алдыннан Дүртөйле районының Иске Яндыз мәктәбеннән татар теле укытучысы Рүзилә Баһаветдинова укучылары белән ике тапкыр безгә Бөгелмәгә килде. Алар әтинең шигырьләрен сөйләде. Мин әтием турында хатирәләремне бүлештем, фотога төштек. Шуннан соң башка кеше-караның килгәне юк иде инде. Менә хәзер сез килдегез. Бәдрүш Мокамайны онытмавыгыз өчен бик зур рәхмәт, – дип искә алды Линария Батырова.

Хушлашканда, Линария Бәдретдин кызы әтисенең «Линарияга хатлар» китабын һәм Габдулла Тукайның 1938 елда латин хәрефләре белән нәшер ителгән «Сайланма әсәрләр»ен (җаваплы мөхәррире – Муса Җәлил) бүләк итте. Бәдрүш Мокамай бу китапны яратып укыган, кайбер шигырьләрнең астына каләм белән сызып куйган. «Бу кыйммәтле китаплар әрәм булмасын, кешеләргә файда китерсен. Шуңа күрә аларны сезгә тапшырам», – диде Линария ханым...

Фәнүз Хәбибуллин ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

Гыйбрәтле *хикәятләр*

АЛТЫНГА КЫЗЫКСАҢ...

Имам Газали (рәхмәтуллаһи галәйһи) «Ихйа» исемле китабында әйтте: «Бер кеше Аллаһы Тәгаләне бер һәм бар дип белеп гыйбадәт кылучы иде. Бер кавемнең бер агачка гыйбадәт кылганын ишетеп, бик ачуланып, кулына балта алып, бу агачны кисеп екмакчы булып, өеннән чыкты.

Юлда барганда, адәм сурәтендә булып, Иблискә юлыкты. Бу кешедән:

– Кая барасың? – дип сорады.

Бу кеше, аның Иблис икәнен белмичә:

– Фәлән җирдә бер кавем бер агачка гыйбадәт кыла икән. Шуңа ачуым килеп, шул агачны кисәргә барамын, – диде. Шайтан миңа каршы:

– Хата итәсең, әгәр ул агачны киссәң, алар икенче бер агачка гыйбадәт кыла башларлар, файда итә алмассың. Кайт син, гыйбадәтеңдә бул, кеше өчен кайгырма, тиз картаерсың, – дип киңәш бирде. Бу кеше, сүзендә нык торып:

– Юк, калдырмам, – дигәч, шайтан бу кеше белән сугыша башлады. Әлеге кеше дә, шайтанны бик яхшы гына суккалап, җиргә екты.

Шайтан, хәйләгә керешеп:

– Син бер фәкыйр кеше, ул агачны кисмә, өеңә кайт, гыйбадәт кыл. Мин һәр көн баш астыңа ике алтын тәңкә куярмын, син бу фәкыйрьлектән котылырсың, һәр көн ике алтын тәңкә кулыңа кергәч, файда итәрсең, әлбәттә, бай булырсың. Әгәр Аллаһы Тәгалә ул кавемне иманга кертәсе булса, пәйгамбәр җибәреп, ул агачны кистереп, бу кавемне иманга өндәтер иде. Син үзең шул агачка гыйбадәт кылмагач, һичнәрсә юк, – диде.

Бу кеше, ике алтын тәңкәгә кызыгып, өенә кайтып китте. Иртә торса, баш астында ике алтын тәңкә тапты, янә бик шатланды һәм: «Менә бу агачны киссәм, бер тиен акчасыз, арып-талып кына кайткан булыр идем. Хәзер һәр көн ике алтынны алу өметендә торам. Кайвакытта шайтан сүзен тотсаң да ярый икән», – дип уйлап утырды.

Янә кич булып, ятып йоклады. Иртән торса баш астында алтын юк. Хатыны иртәрәк торган иде. Хатыныннан:

– Алтынны син алдыңмы? – дип сорады. Хатыны:

– Алганым юк, – дигәч, ышанмыйча, хатынын бик рәнҗетте. Янә бик ачуы килеп, үзен-үзе сүгеп: «Шайтанга ышанып, җәмәгатеңне сүгеп йөрисең», – дип, балтаны кулына алып, янә агачны кисәргә китте.

Юлда яңадан Иблис очрап, бу кешегә бәйләнеп:

– Барма, китермәм! – дип, сугыша башладылар. Шайтан бу кешене җиргә екты. Бу кеше әйтте:

– Минем сиңа әүвәл ничек көчем җиткән икән? – диде. Шайтан аңа:

– Син әүвәл вакытта Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен ул агачны кисәргә чыккан идең, инде хәзер алтын бирмәгән өчен кисәргә барасың. Шуңа күрә, ягъни Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен булмаганга, көчең җитми, – дип җавап бирде».

Бу хикәяттән беленде: Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен бер эшне эшләмәкче булсаң, шайтанның туктатырга көче җитми. Әгәр дә Хода ризасы өчен булмаса, шайтанның ул эшне бозуы вә булдырмавы бик ихтимал.

НӘЗЕР

Әүвәл заманда бер кеше: «Әгәр Аллаһы Тәгалә миңа мал бирсә, фәкыйрьләргә сәдака бирер идем», – дип нәзер әйткән икән. Аллаһы Тәгаләнең әмер белән, бер кеше моңа бер алтын тәңкә бирде.

Нәзер әйтүче кеше әлеге алтын тәңкәне алгач, күңеленнән: «Бу акчага бервакыт мохтаҗ булырмын, фәкыйрьләргә бирмим әле», – дип, уйлап, аны җыеп куйды.

Бераз көннәр үткәннән соң, әлеге кешенең теше сызлый башлады, көч-хәл белән түзеп йөрде дә, ахырда, түзә алмагач, тешен алдырды. Бу тешен алдыргач, янә икенче теше сызлый башлады, ул тешен дә алдырды.

Шул арада: «Әгәр теге алтынны фәкыйрьләргә бирмәсәң, бер тешеңне калдырмый суыртып бетерербез», – дигән тавыш ишетелде.

Әлеге кеше, бу тавышны ишеткәч, кылган эшенә тәүбә итеп, ул алтын тәңкәне фәкыйрьләргә сәдака итеп бүлеп биреп бетерде.

Инде ошбу кыйссадан беленде: нәзер иткән нәрсә фәкыйрьләр хакы була, ә фәкыйрьләр хакын бирмәсәң, малыңа яки, малың булмаса, тәнеңә зарар ирешә икән. Һәм шуның кебек зәкәт вә гошер тиеш булып, бирмәгән кешенең дә малына яки тәненә зарар килер.

КЕШЕГӘ ЧОКЫР КАЗЫСАҢ...

Әүвәл заманда бер падишаһ бер вәзирен бик сөядер иде. Бер кеше, падишаһның аны бик сөюен белеп, падишаһтан бу вәзирне ераклаштырмакчы булды. Янына килеп:

– Синең фәлән вәзирең: «Падишаһның авызы сасы икән», – дип әйтә, – диде. Падишаһ:

– Сүзеңнең раслыгын кайдан белербез? – дип сорады. Бу кеше:

– Ул вәзир синең яныңа килеп, сөйли башлагач, кулын авызына куяр, – диде.

Падишаһ вәзирне чакырды. Бу кеше шул сәгатьтә вәзирне өенә чакырып кунак итеп, күп сарымсак салынган аш ашатты.

Вәзир, бу кешедән чыккач, падишаһ катына барды. Падишаһ алдында сөйли башлагач, вәзир, «сарымсак исе падишаһка таба бармасын», дип, кулын авызына куйды.

Падишаһ вәзирнең кулын авызына куйганын күргәч, «теге кешенең сүзе раст икән», дип, каләм алып хат язды. Падишаһның гадәте шул иде: әгәр үз кулы белән хат язса, ул хат бүләк бирү өчен була.

Бу кеше, падишаһның хат язганын күргәч, «вәзиргә бүләк бирә», дип белде. Падишаһ исә вәзиргә:

– Хатны фәлән вәлигә илтеп бир! – дип боерды.

Бу кеше, «бүләкне мин алырмын», дип уйлап, вәзирдән:

– Син мәшәкатьләнеп йөрмә, хатны үзем илтеп бирим, – дип сорады. Вәзир, каршы килмичә, хатны бирде, теге кеше аны падишаһ боерган вәлигә илтеп тапшырды.

Бу вәли, тиз генә хатны укып, падишаһ боерганча, бу кешенең башын кистерде...

Көннәрдән беркөнне әлеге вәзир падишаһ янына килеп керде. Падишаһ, хәйран булып, вәзирдән:

– Син теге хатны илтеп бирдеңме? – дип сорады. Вәзир:

– Юк, ул хатны миннән фәлән кеше сорап алды, – диде. Падишаһ исә:

– Син мине сасы авызлы дип сөйләдеңме? – дип сорады. Вәзир:

– Һич сөйләгәнем юк, – диде. Падишаһ яңадан:

– Ни өчен минем белән сөйләшкәндә авызыңа кулың куеп тордың? – дигән сөаль бирде. Вәзир:

– Ул кеше миңа, синең катыңа барганда туктатып, сарымсаклы тәгам ашаткан иде, шул сарымсак исе сиңа бармасын, дип, авызыма кулым куеп тордым, – дигәч, падишаһ:

– Хәер, үзе казыган базына үзе төшкән икән, – дип әйтте.

ТӘКЪВА[1] КЫЗ

Һинд аучыларыннан бер кеше балык тотарга диңгез буена барды. Үзе белән бергә бер кызын балыкны җыеп торырга дип алып килгән иде.

Бу кеше, ятьмәсен салып, балык алгач, ул балыкларны кызына бирә торды. Ә кызы алган бер балыкны кире диңгезгә җибәрә иде.

Бу кеше, балык тотудан туктап, балык савытына карагач, анда бер балык та тапмады. Шуннан соң кызыннан:

– Бу токкан балыклар кайда? – дип сорагач, кызы болай җавап бирде:

– Әй, атам! Син миңа Расүл әкрамнан[2] ишеткән: «Балыклар Аллаһы Тәгаләнең зикереннән[3] гафил булмаса, ауга кермәс, мәгәр Аллаһы Тәгаләнең зикереннән гафил булган балык кына ауга керер», – дигән хәдис сөйләгән идең. Мин шуның өчен, ягъни Аллаһы Тәгаләнең зикереннән гафил булган балыкны ашыйсым килмәгәнгә, аларны диңгезгә җибәрдем. Атасы да: «Бәрәкалла!» – дип, буш кул белән кайтып киттеләр. Шул вакыттан соң әлеге кеше балык аулаудан туктады.

КИРЕБЕТКӘН КӘФЕРЛӘР

Разый[4] исемле галим сөйләде:

«Кыйбтыйлар[5] халкы фиргавен кавеменнән булып, Муса галәйһиссәламгә иман китермәде. Муса галәйһиссәлам ничә вә ничә могҗизалар китерсә дә: «Сихерче син, сихер белән безне ышандырмаучы буласың!» – диделәр. Муса галәйһиссәлам болар

[1] Тәкъва – үтә динле, Алладан куркучы.
[2] Расүл әкрам – Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәр. Әкрам – хөрмәтле.
[3] Зикер – Аллаһны телгә алу, исемнәрен кабатлау.
[4] Разый – Фәхреддин әр-Разый (1209 да вафат), тәфсирче галим, фәйләсуф.
[5] Кыйбтыйлар – Мисырның борынгы җирле халкы.

иманга өндәүне кабул итмәгәч, кавемгә газап теләп, дога кылды. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә, әлеге кыйбтыйларга газап итеп, туфан җибәрде. Ул туфан кичә вә көндез бертуктаусыз булып һәм кояш яктылыгын каплап, һичнәрсә күренмәс булды.

Бу хәлне вә куркынычларны күргәч, кыйбтыйлар фиргавеннән ярдәм сорадылар. Фиргавен Муса галәйһиссәламнән:

– Әй, Муса! Раббыңа дога кыл, бу газапны бездән күтәрсен, – дип үтенде.

Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгаләгә дога кылды. Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламнең догасын кабул итеп, туфан вә яңгырны туктатты да җил җибәрде. Җирдән бик тиз арада куе үләннәр үстерде. Үләннәр җиргә сыймаслык рәвештә булды.

Әлеге кыйбтыйлар, Аллаһы Тәгаләнең бу нигъмәтенә рәхмәтле булмыйча, сабырсызлык кылдылар. Аллаһы Тәгалә, көферлекләрендә калганнары өчен, чикерткәләр җибәреп, ул үләннәрне ашатып бетерде. Әлеге чикерткәләр очкан вакытта кояшны каплыйлар, шулкадәрле күп иделәр.

Бу катылыктан зарланып, Муса галәйһиссәламнән янә ярдәм сорадылар. Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә дога кылды, Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламнең догасын кабул итеп, ул чикерткәләргә җил җибәреп, барысын да диңгезгә батырды.

Кыйбтыйлар янә дә: «Калган игеннәребез ашарга җитәр», – дип, Муса галәйһиссәламгә итагать кылмыйча, кәфер булдылар. Аллаһы Тәгалә бу кыйбтыйларга янә дә газап итеп «камел[6]« исемендә бернәрсә җибәрде. Кайберәүләр аларны канатсыз чикерткә, кайсылары борга, бет, диделәр. Бу бетләр кыйбтыйларның хайваннарына бер үлән дә калдырмый ашап бетерделәр, тәннәренә кереп, корчаңгы кебек газап китерделәр.

Болар янә дә Муса галәйһиссәламнән ярдәм сорадылар. Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә дога кылды, Аллаһы Тәгалә догасын кабул итеп, ул бетләргә эссе җил җибәреп, һәлак итте.

Бу кыйбтыйларны Муса галәйһиссәлам янә иманга өндәсә дә, кабул кылмадылар, көферлекләрендә калдылар. Аллаһы Тәгалә әлеге кыйбтыйларга газап итеп бакалар җибәрде, ул бакалар кыйбтыйларның игеннәренә һәм ашларына вә түшәкләренә дә керделәр, боларга бик тарлык китерделәр.

Янә Муса галәйһиссәламнән ярдәм сорадылар. Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә дога кылды, Аллаһы Тәгалә догасын кабул итеп, бакаларны үтерде, яңгыр биреп, ул бакаларны шул яңгыр суы белән диңгезгә агызды.

Бу кыйбтыйлар янә дә Муса галәйһиссәламгә иман китермичә, көферлекләрендә калдылар. Аллаһы Тәгалә әлеге кыйбтыйларга газап итеп кан җибәрде. Бу кан эчә торган суларына вә тәгамнарына катышты. Кайберәүләр: «Аллаһы Тәгалә кыйбтыйларның борыннарын каный торган итте», – дип әйтте. Шул бәла белән җиде көн бәлаләнделәр: кан эчтеләр вә кан белән ашадылар.

Әлеге кыйбтыйлар Муса галәйһиссәламнән яңадан:

– Әй, Муса! Әгәр бу бәлане бездән алсаң, әлбәттә, сиңа иман китерербез, – дип үтенделәр. Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә дога кылып, газапны бетерсә дә, иман китермәделәр. Аллаһы Тәгалә бу кыйбтыйларны фиргавен белән Нил дәрьясына батырып һәлак кылды.

---

[6] Камел – бет.

АВЫР КӘЛИМӘ

Әбү Талибның[7] үлем авыруында Мәккә кәферләренең олылары җыелып, Әбү Талиб катына килделәр. Бу өммәтнең «фиргавене» Әбү Җаһил дә шунда иде.

– Әй, Әбү Талиб! Синең кардәшеңнең улы белән ике арабызда хакларыбыз бардыр. Син бик яхшы беләсең, үзең үлгәнче безне килештереп калдыр, – диделәр. Әбү Талиб Расүл әкрамны чакыртты. Расүл әкрам да Әбү Талиб катына килде. Әбү Талиб:

– Әй, кардәшем углы! Бу кешеләр кавемнең олылары, син алардан хакыңны кич, алар синнән хакларын кичәрләр, – дип сорады. Расүл әкрам:

– Миңа бер кәлимәдә[8] буйсынсагыз, кичәмен, – диде. Әбү Җаһил (ләгънәтуллаһи галәйһи[9]):

– Ул кәлимәдә буйсынырбыз, – дип вәгъдә итте. Расүл әкрам:

– Лә иләһә иллә Аллаһ (Бер Аллаһтан башка һич Аллаһ юк) дип әйтегез, – диде. Корәеш[10] кәферләре:

– Син гаҗәп сүз сөйлисең, бар аллаларны бер алла итмәкче буласың, – дип, тартышып киттеләр.

Әбү Талиб исә:

– Йа Мөхәммәд! Зур нәрсә сорамадың, – диде. Расүл әкрам Әбү Талибтән бу сүзне ишеткәч, иман китерүен теләп:

– Син дә бу кәлимәләрне әйтсәң, кыямәт көнендә минем шәфәгатем сиңа хәләл булыр, – дип әйтте. Әбү Талип:

– Әгәр Корәеш халкы «авыруыннан көчләнеп әйтте», дип әйтмәсә, әйтер идем, – диде.

ШӘҺАДӘТ КӘЛИМӘСЕНЕҢ МОГҖИЗАСЫ

Гайсә галәйһиссәламнең яраннары булган расүлләреннән[11] берсе сабыйлар уйный торган җирдән үтеп барганда, бу расүл шул сабыйлар белән бергә уйный иде. Бу сабыйлар арасында вәзирнең улы да бар иде. Ул бу расүлне кунак итәргә өенә чакырырга килде.

Расүл килеп, вәзир белән күреште. Вәзир, аш әзерләтеп, расүлне кунак итмәкче булды. Ашны кунак алдына кертеп куйганнан соң, бу расүл: «Бисмилләәһиррахмәәнир-рахиим!» – дип кулын сузгач, шайтаннар аш яныннан торып качтылар.

Вәзир, әлеге эшне күреп, расүлдән:

– Бу ни хәлдер? – дип сорады! Расүл вәзиргә:

– Минем Раббымның исемен зикер иткәч, шайтаннар качалар, син дә Аллаһы Тәгаләне зикер итсәң, шайтаннар качарлар, – диде. Вәзир:

– Син кем буласың? – дип сорады.

Расүл:

– Мин Гайсә галәйһиссәламнең расүлләреннән берсемен. Сезне Ислам диненә өндәргә килдем. Сиңа да, иман китереп, мөселман булырга бик вакыт, – диде.

Вәзир:

– Иман ни булыр? – дигәч, расүл:

---

[7] Әбү Талиб – Мөхәммәд пәйгамбәрнең атасы ягыннан абзасы.
[8] Кәлимә – сүз. Биредә – шәһадәт кәлимәсе.
[9] Ләгънәтуллаһи галәйһи – аңа Аллаһның ләгънәте булсын.
[10] Корәеш – кабилә исеме.
[11] Расүл – дингә өндәргә җибәрелгән кеше, илче, пәйгамбәр.

– «Лә иләһә иллә Аллаһ, Гайсә расүлүллаһ», – дип әйтеп, санәмнәргә[12] гыйбадәт кылмыйча, ялгыз Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу белән булыр, – дип җавап бирде. Вәзир дә, иман китереп, мөселман булды.

Көннәрдән беркөн вәзир падишаһ катына барып, бик күңелсез булып кайтты. Расүл, вәзирнең күңеле караңгы икәнен күргәч:

– Ни сәбәпле күңелең сынык? – дип сорады. Вәзир моңа каршы:

– Падишаһ янына барган идем, падишаһның сөекле аты үлгән, шуңа бик кәефсез утыра, аның кәефсезлеге минем күңелемне дә сындырды, – диде.

Расүл:

– Син падишаһка әйт: минем бер кунагым бардыр, ул кунак әйтәдер: «Әгәр миңа итагать кылса, падишаһның атын Аллаһның кушуы белән тергезермен», – дип әйтте.

Вәзир расүлдән бу сүзне ишеткәч, падишаһ катына шатланып барды һәм:

– И падишаһ! Миндә бер кунак бар, ул кунак: «Әгәр падишаһ мин әйткәнгә буйсынса, Аллаһның кушуы буенча атны тергезермен», – диде. Падишаһ:

– Ул кунагың килсен, – дип боерды.

Вәзир, кайтып, шәехне чакырып килде. Шәех, падишаһ өенә: «Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим», – дип әйтеп кергәндә, йорттан шайтаннар качты. Падишаһ, расүлне каршы алып:

– Минем атымны тергез, – диде.

Шәех:

– Әгәр мин әйткәнгә буйсынсаң, Аллаһ теләсә, тергезермен, – дип җавап бирде. Шәех:

– Балаларың бармы? – диде.

Падишаһ:

– Анам белән хатыным бар, балаларым юк, – дип җавап бирде. Шәех падишаһның анасы белән хатынын да чакырды, алар да шул урынга килделәр.

Шәех, атның аягын бер кулы белән тотып:

– Лә иләһә иллә Аллаһ!» – диюе булды, атның бер аягы селкенә башлады. Икенче аягын падишаһка тоттырып: «Лә иләһә иллә Аллаһ!» – дип әйт, диде. Падишаһ, атның аягын тотып: «Лә иләһә иллә Аллаһ!», – дигән иде, атның икенче аягы да селкенә башлады. Йәнә шәех падишаһның анасы белән хатынына атның ике аягын тоттырып: «Лә иләһә иллә Аллаһ!» – дип әйтегез, – диде. Болар икесе дә:

– Лә иләһә иллә Аллаһ! – дип әйттеләр исә, атның янә ике аягы да селкенә башлады.

Инде атның аяклары терелде, мәгәр гәүдәсе әүвәлге хәленчә калды. Шәех падишаһка:

– Халкыңны җыйдыр, – диде. Падишаһ шундук халыкны чакырып, һәммәсе килеп, бердән: «Лә иләһә иллә Аллаһ!» – дип әйткәч, ат терелеп торды да башын иде, янә күтәрде. Моны күреп барчасы, шулай ук падишаһлары да мөселман булды.

Хикәятләрне басмага
***Нәҗип Нәкъкаш** әзерләде.* ■

---

[12] Санәм – табыну объекты; таш, агач һәм башка нәрсәләрдән ясалган фигуралар, һәйкәлләр.

САУ БУЛ, АВЫЛЫМ!

Хәлим Җәләй

Унынчы классны тәмамлагач, Казан авыл хуҗалыгы институтына (хәзерге Казан дәүләт аграр университеты) укырга кердем. Теләгем – авыл хуҗалыгы машиналары буенча инженер-механик булу.

Абыйлар кайсы-кая таралышып беттеләр, өйдә, әни янында, төпчек малай – мин генә калдым. Укырга китсәм, авылда әни япа-ялгыз калачак иде. Шуңа күрә, авылдагы өйне сатып, Казанга күчеп килдек. Бертуган Петряевлар урамында йорт сатып алдык. Минем өчен бөтенләй яңа тормыш башланды. Яңа җир, шәһәр җире. Тик... Ярата алмадым мин аны. Беренче елда авылны сагынып гаҗиз булдым. Мәктәпне, авылны юксынып елаган чакларым булды. Ниһаять, әни, түземлеге төкәнеп, мине авылдан ат җигеп килгән Шәмсетдин җизнигә утыртты да авылга кайтарып җибәрде. Ун көн торып килдем, ун сәгать кебек тә булмады. Авыл шул ук, дуслар шул ук! Көн саен клубка чыгабыз, аулак өйләргә кич утырырга йөрибез. Авыл гөрләп тора. Нигә дип кенә Казанга кителгән соң?! Шулай да Казанга кайтырга туры килде. Хат җибәргәннәр. «Тиз кайт, – дигәннәр. – Нәгыйм өйләнә. Институтыңа илтергә бирәр справка да юнәтеп кайт».

Казанга колхоз йомышы белән сигез олау китәсе икән. Мин шулар белән китәргә булдым. Классташларым Хатыйп белән Бәдретдин дә шунда. Юлга чыкканда, күз ачкысыз буран кузгалды, барырлык түгел. Егетләр, авылны чыгып бераз баргач, кире борылырга булдылар. Кайттык кире борылып. Әй ул көнне шатлануларым! Мин бит тагын бер көн авылда булачакмын, тагын клубка чыгабыз әле! Тик икенче көнне барыбер китәргә туры килде. Буран әле бөтенләй үк басылмаган да иде. Юлда Богородское дигән авылда кунып та чыктык.

Китүен-киттем, ә күңелем бөтенләе белән авылда калды. Бүгенгә кадәр авылымны сагынып яшим һәм бу сагыну гомеремнең соңгы сәгатенә кадәр дәвам итәчәктер инде.

Миңа авыл хуҗалыгы институтын тәмамларга насыйп булмады. 1961 елда Казанда театр училищесы ачылды. Тик аңа кадәр дөнья белән шактый гына танышасы бар иде әле.

Казанга килгәч тә, Вахитов клубында, Казан киез итек фабрикасының үзешчән сәнгатендә катнашып, сәхнә тузанының «тәмен» бераз татырга өлгергән идем инде мин.

Казан киез итек фабрикасының халык телендәге исеме «Татваленка» иде ул вакытта. Әйе, бу фабрикада өч елдан артык эшләргә туры килде миңа. Бер үк вакытта институтта читтән торып укыйм. Фабрикада да эш җиңел түгел, сессияләргә, имтиханнарга да әзерләнергә кирәк. Ә күңел сәхнәгә тартыла.

Ул еллар турында берничә сүз әйтеп китмичә булдыра алмыйм. Фабрикада җыр ансамбле бик популяр иде. Кырыкка якын егет-кыз бик теләп йөриләр иде анда. Үзешчән сәнгатьнең гөрләп чәчәк аткан чагы. «Татваленка» үзешчәннәренең даны шаулады ул елларда! Сәхнә тулы – яшьләр! Сәхнә тулы – җыр, моң...

Ә Вахитов исемендәге клубка драма түгәрәгенә йөрдем. Клуб та әллә ни зур түгел, агач клуб. Сәхнәсе дә кечкенә. Әмма шул сәхнәдә күп кешеләр катнаша торган зур-зур спектакльләр куя идек. Җитәкчебез – танылган артист Һидият абый Солтанов. Камал театры артисты. Беренче спектаклебез азәрбайҗан драматургы Җ.Җаббарлының «Вафалы (ышанычлы) Сәрия» дигән драмасы иде. Мин – унсигез яшьлек малай Сәфәргали исемле картны уйнадым. Бу рольне ничек миңа биргәннәрдер инде?! Хәзер әсәрнең эчтәлеге бик хәтердә түгел. Бары тик мин уйнаган картның хәйләкәр булуы, гашыйкларның кавышуына ярдәм итүе һәм тамашачыларның яратып кул чабулары гына истә калган. Спектакльдә төшерелгән фотолар альбомымда саклана. Без бу түгәрәккә Илдус Вәлиев белән, бер көнне килеп, бергә йөри башладык. Соңыннан ул да (армиядә хезмәт итеп кайткач), театр училищесын тәмамлап, Камал театрында артист булып эшләде. Искиткеч талантлы артист иде. Тик, кызганыч, гомере генә кыска булды мәрхүмнең.

Икенче спектаклебез – «Тормыш җыры» (М.Әмир). Монда инде мин шаян-шук малай – Каюм ролен уйнадым. Тагын шуны әйтәсем килә: мәктәпне тәмамлаганда

Телевидениедә беренче мәртәбә чыгыш ясаганда. 1961 ел

буем бик бәләкәй иде. Инде институтта укыйм, ә менә кичке сеанска кинога кертмәгән очраклар булды. Берничә тапкыр... Нәкъ менә шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең «Буй бәласе» дигән шигырендәгечә. Мин ул шигырьне озак еллар сәхнәдән дә сөйләп йөрдем. Үземә бик туры килә иде шул. Моны шуның өчен язам: «Тормыш җыры»н куйгач, Һидият абый бездән китеп барды. Киткән чакта ул миңа: «Сиңа, Хәлим, укырга, чын артист булырга кирәк иде дә... Ләкин, ни кызганыч, синең буең бәләкәй. Аннары кыяфәтең дә... Югыйсә, артист булырга бөтен мөмкинлегең бар», – дигән иде.

Һидият абый киткәч, безнең түгәрәккә җитәкче булып Мәсгут абый Имашев килде. Әмма, ничек дип әйтергә, бәхет эше, дип әйтимме... Буем бер ел эчендә кинәт кенә үсеп китте. (Бер елдан соң очрашкач, Һидият абыйның гаҗәпләнеп торганы хәтердә.) Үстем, дигәч тә, пәһлеван ук түгел инде. Шулай да театр училищесы «стандарты»на туры килерлек булды бугай.

1961 елның җәендә безне, кыска вакытлы курсларда укытып, ике ай эчендә комбайнчы һөнәре биреп, чирәм җирләргә – Павлодар өлкәсенә озаттылар. Әле минем мондый ерак юлга беренче тапкыр чыгуым. Аннан яңа тәэсирләр белән баеп кайттык. Ә өйдә мине бер язу көтә иде: «Хәлим, кайтуга, Мәсгут абыйны күр».

Мәсгут абый Имашев ул чакта, язганымча, Вахитов исемендәге клубта татар драмтүгәрәгенең җитәкчесе. Тиз генә Мәсгут абый янына йөгердем. Ул инде училищега керү шартлары белән танышкан иде. Без аның белән имтиханга әзерләнә башладык. Имтихан өчен чәчмә әсәрдән өзек яки хикәя, мәсәл, шигырь өйрәнергә кирәк икән. «Әле өстәмә сораулар да булырга мөмкин, – диде Мәсгут абый. – Җырлатып та карарлар. Сәхнәдә пианино да булыр. Пианинодагы менә шушы кара клавишаларга бас. Синең тональностең шул. Кыяфәтең белән әллә ни булдыра алмассың, кыюрак бул. Главное, каушап калма».

Әле имтиханга кадәр миңа институттан документларны алырга кирәк иде. Анысы бер бәла булды. Бирмиләр. «Бездә өч ел укыдың, җибәрә алмыйбыз», – диләр. «Мин бит – заочник, читтән торып укыйм. Җибәрмәскә хакыгыз юк», – дим. Бер атна буе көн дә йөри торгач, ниһаять, документларымны бирделәр.

Училищега өч йөз алтмыш гариза кабул ителгән, диделәр. Чама белән татар группасына йөз туксан гариза була инде. Уналты студент һәм ике кандидат кабул ителәчәк.

10 ноябрь көнне – беренче имтихан. Алтмыш кеше имтихан тотачак. Имтиханнарны кичке алтыга кадәр кабул итәчәкләр. Мин эштән соң барырга булдым. Училищега барып кергәндә, коридор тулы кеше, ыгы-зыгы иде. Имтихан тәмамланган. Сәркатип,

ишектән чыгып: «Бүгенгә тәмам, соңга калучылар юкмы?» – дип сорады. Мин, ашыгып: «Мин бар», – дидем. Тиз генә пальтомны салып, шундагы урындыкка ыргыттым да ишектән кереп тә киттем.

Өстәл артында утырган абыйларның кайсыберләрен таныйм да кебек. Уртада кабул итү комиссиясе рәисе, олпат гәүдәле Ширияздан абый Сарымсаков утыра. Аның янында Шәүкәт Биктимеров, Празат Исәнбәт, Габдулла Шамуков, Рәфкать Бикчәнтәев. Бүгенгә эш беткән. Ширияздан абый, урыныннан торып, папкаларын, кәгазьләрен җыештыра башлады. Аннары миңа бер күз төшереп алды да, кәгазьләреннән аерылмыйча гына:

– Йә, нәрсәләр әзерләдең? – дип сорады.

– Һади Такташ. «Җамали белән Камали», – дим.

– Әйдә, сөйлә.

Мин, Мәсгут абый өйрәткәнчә, артык каушамыйча гына сөйли башладым. Ике җөмлә әйтүгә, Ширияздан абый, папкаларын куеп, урынына кире утырды. Башкалар да торырга ашыкмадылар. Сөйли торгач, бераз мавыгып китеп, кыюланып, өстәл янына якынлашкач, Ширияздан абый:

– Чү, чү, сабыррак, сабыррак, – дип, мине арткарак чигендерде.

– Тагын нәрсә әзерләдең?

– Әхмәт Ерикәйнең «Былбыл тирәсендә» дигән мәсәлен.

Укып бетердем мәсәлне. «Рәхмәт», – диделәр. Ә бу сүзнең хәтәр сүз икәнен мин белә идем инде. Әгәр икенче турга үтмәсәң, «рәхмәт», дип әйтеп юатып озаталар, имеш. Өметләрем челпәрәмә килгәндәй булды. Коридорга чыктым. Көтәбез. Шау-шу. Кайсы көлә, кайсы елый. Менә бераздан исемлекне чыгарып элделәр. Алтмыш кешедән сигезе икенче турга үткән икән. Үз исемемне эзлим. Исемлектә, сигезенче кеше булып, минем фамилиям тора иде. «Тагын өч көннән икенче тур», – диделәр. Миңа канатлар үскән кебек булды: «Әһә, – мин әйтәм, – тышкы кыяфәт иң әһәмиятлесе түгел икән. Икенче турга тагын да тырышыбрак әзерләнергә кирәк булыр».

Икенче тур 13 ноябрьдә үтте. Ул көнне дә чак кына соңга калмадым. Мин барып кергәндә, имтиханнан соңгы кеше чыккан иде. Сәркатип, чыгып: «Соңга калучылар юкмы?» – дип сорады. Мин тиз генә чишенеп кереп киттем. Бу юлы Ширияздан абый, мине күрүгә: «Әйдә, Җәләлов, бүген шигырьдән башла әле», – диде. Мин Шәүкәт Галиевнең «Хупҗамал» шигырен ике куплет укуга: «Ярар, җитеп торыр, ә җырлый беләсеңме?» – дип сорады. Мин, кыю гына атлап, сәхнәдәге пианино янына барып, Мәсгут абый өйрәткәнчә, кара клавишага бастым да «Тау башында балкый бер кала...» дип җырлап та җибәрдем. Бер куплет җырлагач: «Рәхмәт», – дип, мине туктаттылар. Ширияздан абый, өстәл янына дәшеп, каршысына утыртты. Кайда эшләвем, күпме хезмәт хакы алуым турында сораштырды. Мин 125 сум дигәч: «Алай икән, менә без быел театрга Мәскәүдән укып кайткан яшь артистлар кабул иттек, хезмәт хаклары 70 сум», – диде. Телемә каян килгәндер инде: «Мин бит күп акча эшләү өчен килмим», – дип әйтеп ташладым. Шуның белән сораулар бетте. «Өченче турга килеп торма, син кабул ителдең. 1 декабрьдән укулар башлана, аңарчы институтыңда да, эшеңдә дә документларыңны җайла, алдагы китек тешеңне дә куйдыр, өлгерә алсаң», – диде ул. Этюдлар эшләргә туры килмәде. Мин, канатланып, коридорга чыктым. Анда ыгы-зыгы. Менә бераздан берәм-берәм комиссия әгъзалары чыга башлады. Рәфкать абый Бикчәнтәев чыгуга, аны уратып алдылар. Өстендә бик матур ыспай пальто, башында үзенә бик килешеп торган зур йонлач бүрек. Ул, туп-туры минем янга килеп, кулымны кысты һәм бик тә җылы сүзләр әйтте. Аның ул сүзләре хәтеремдә гомерем буе саклана.

Өйгә ашыктым. Куанычым эчемә сыймый. Аны кем беләндер бүлешәсем килә. Кайтып кердем. Өйдә бәләкәй абыем Нәгыйм белән әни генә. «Абый, – мин әйтәм, – бер

сүзем бар. Безнең бәйрәмнән калган берәр нәрсә булырга тиеш, чыгар әйдә». Берәрне күтәреп куйгач: «Абый, мин институтны ташладым бит, театр училищесына укырга кердем», – дидем. Әлбәттә, бу хәбәр әнине сөендермәде. Ә абый алай каты борчылмады, киресенчә, шатланган сыман да тоелды миңа. Икенче көнне райондагы өлкән абыем Нәкыйпне чакырдылар. Ул шул көнне үк килеп җитте. Өчәүләшеп мине ачуланырга, үгетләргә тотындылар. Бик тыныч кына тыңлап торуымны күргәч, Нәкыйп абый: «Әни, сүзеңне әрәм итеп сөйләп торма, барып чыккан бу», – диде. Шуның белән әлеге мәсьәлә дә хәл ителде.

1961 елның 1 декабрендә без беренче дәрескә җыелдык. Курсыбызның җитәкчесе – Ширияздан абый Сарымсаков, укытучыларыбыз – Габдулла Шамуков, Шәүкәт Биктимиров, Хөсәен Уразиков, Вахит Хаков, Татьяна Геллер һ.б.

Көндез – дәресләрдә, ә кичләрен – көн саен театрда. Спектакльләр карыйбыз. «Спектакль карау – үзе бер дәрес», – диделәр безгә. Ә сәхнәдә нинди артистлар!.. Хәлил Әбҗәлилов, Камал III, Гөлсем Камская, Галия Булатова, Габдулла Шамуков, Фуат Халитов... Берсеннән-берсе кызыграк спектакльләр! «Зәңгәр шәл», «Беренче мәхәббәт», «Татар хатыныниләр күрми», «Казан сөлгесе», «Зифа» һ.б. Бу спектакльләрне ничәшәр тапкыр караганбыздыр, төгәл әйтеп тә булмый.

Икенче көнне караган спектакльләребез турында үзара фикер алышабыз, кызыпкызып бәхәсләшәбез. Бөек артистларыбызның уеннарын да тәнкыйтьләргә җөрьәт итәбез. Нәкъ менә мәзәктәгечә: «Студентлар беренче курста – халык артистлары, икенче курста – атказанган артистлар, өченче курста – артистлар, дүртенче курста студентлар булып укуларын тәмамлыйлар».

Ә икенче курста инде без үзебез кайбер спектакльләрдәге күмәк күренешләрдә (массовкаларда) катнаша башладык. Камал театры сәхнәсенә аяк басу безнең өчен, әлбәттә, әйтеп бетергесез шатлык иде. Әле миңа «Фаҗигале юлда» дигән спектакльдә Бу-юнг исемле хезмәтче ролен дә уйнарга туры килде. Роль зур түгел, сүзләре дә бишалты җөмлә генә, ә куаныч эчкә сыймый. Программада минем исемемне дә язарга онытмаганнар!

1964 елда «Чаткылар» (Т.Гыйззәт) спектакле куелды. Курсташларым Наил Әюповка – Рамай, Наил Шәйхетдиновка – Макар, миңа зимагур Тимергали ролен бирделәр. Без чиксез шат идек. Тимергали – зимагур егет, шахталарда эшләп кайткан, тәвәккәл, чая. Җырга, биюгә дә оста. Шушы спектакльдә бик матур бер күренеш бар. Тимерче Гаяз, сөйгәне Маһины килен итеп төшергәч, мәҗлес җыя. Без монда җырлап-биеп күңел ачабыз.

Бик тә хәтердә – бер урында тамашачы тып-тын кала, тәэсирләнеп карый һәм ахырдан кул чабып озата. Укып бетергәч, эшкә Камал театрына билгеләгәндә, бу ролемне искә алганнардыр, дип уйлыйм.

1965 елда, Бөек Җиңүнең егерме еллыгына багышлап, «Тормыш җыры» (М.Әмир) спектакле куелды. Монда миңа җырчы малай Каюм ролен башкарырга туры килде. Бу рольне уйнагач, бер дәрестә Наил Әюпов, уенын-чынын бергә кушып: «Җәләй бер аягы белән театрда инде», – дигән иде.

Без диплом спектакле итеп «Эзоп» (Г.Фигейредо) һәм «Тамырлар» (Ю.Әминов) комедиясен куярга тиеш идек. «Эзоп»ның инде күп өлеше куелган да, ләкин Ширияздан абыйның кинәт каты авырып китүе сәбәпле, эш ярты юлда тукталып калды. Без диплом эше итеп «Тамырлар» спектаклен күрсәттек. Режиссёрыбыз – Хөсәен ага Уразиков. Спектаклебез ярыйсы гына барып чыкты бугай. Наил Әюпов белән мине – Камал театрына, Наил Шәйхетдиновны Күчмә театрга (хәзерге Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры) кабул иттеләр.

Без Наил белән җәй буе, түземсезләнеп, театрда сезон башланганны көттек. Менә җәйге ялдан соң артистлар, ниһаять, эшкә чыкты. Җыелыш булды, безне, яшь артистларны, труппага тәкъдим иттеләр. Театрга кабул ителүебез белән котладылар. Ә план тактасында инде приказ эленеп тора иде. Ш.Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы» дигән трагикомедиясе куелачак. Рольләр бүленгән. Без Ринат Таҗетдинов белән Әсхәт исемле үсмер егет ролен уйнаячакбыз. Ринатның башка спектакльдә җитдиерәк эше бар иде. Аннары ул бу рольне уйнарга бик ашкынып тормаганын да сиздерде. «Мин бу роль өчен олырак инде, сиңа гына уйнарга туры килер, бәлки», – диде. Мин, әлбәттә, бик риза идем. Ләкин, һич көтмәгәндә, миңа ашыгыч рәвештә «Ата хакы – Тәңре хакы» (В.Лаврентьев) спектакленә керергә туры килде. Севка ролен уйнаучы актёр авырып киткән икән. Ә спектакль ун көннән чыгарга тиеш. Шушы спектакль белән сезон ачылачак. Рольнең сүзләре күп, Севка – төп рольләрнең берсе. Һич арттырмыйм, икенче көнне репетициягә килгәндә, ролемнең сүзләрен ятлап бетергән идем, дияргә мөмкин иде. Режиссёрыбыз Празат абый мактап та куйды хәтта. Премьера үтте. Ике көннән газетада рецензия басылып чыкты. Театр белгече Ильтани Илялова танылган артистлар белән бергә минем исемне дә мактап телгә алган, яшь актёрга киләчәктә уңышлар теләгән иде.

Ике атнадан «Зөбәйдә – адәм баласы»ның премьерасы булды. Премьера зур уңыш белән узды. Тамашачы спектакльне яратып кабул итте. Ул озак вакыт аншлаг белән барды. Талантлы артистлар Х.Уразиков, Н.Гайнуллин, В.Минкина, Н.Гәрәева, Ш.Биктимеров, Г.Камалова һ.б.ның уены тамашачылар күңеленә хуш килде, спектакльнең уңышын хәл итте.

Театрда минем беренче сезоным ярыйсы гына уңышлы булды шикелле. «Зөбәйдә – адәм баласы» спектакленнән соң «Күзләре нинди иде?»дә (Ә.Баян) – Рифкать, «Муса Җәлил»дә (Н.Исәнбәт) – Янгир, «Гүзәлем Әсәл»дә (Ч.Айтматов) – Камал, «Хуҗа Насретдин»да (Н.Исәнбәт) Атамыш ролен башкардым. Бер сезон өчен аз түгел инде бу. Шактый күтәренке күңел белән беренче сезоным тәмамланды. Алда мине нәрсәләр көтә?!. ■

СОҢГЫ ОЧРАШУ

Әгъзам Фәйзрахманов

Бу фото Рәис Кыям улы Беляевнең (1935-1996) бакыйлыкка күчүенә ике ай алданрак кына төшерелгән иде. Очрашуны Р.Беляев үзе тәкъдим итте. «Килеп кит әле, институтның киләчәге турында гәпләшеп утырырбыз. Бәлки язып та чыгарсың. Планнар шактый зурдан безнең. Башка нәрсәләр турында сөйләшеп тә эчне бушатып алырбыз», – диде ул.

Казан мәдәният институты ректоры Рәис Беляевнең эш бүлмәсе зур булса да, анда игътибарны җәлеп итәрлек затлы мебель дә, башка җиһазлар да юк иде. Барысы да бик гади-гадәти.

Исәнлек-саулык турында сорашып алгач, хуҗа уку йортының якын елларга планнары турында сөйләргә керește. Берничә яңа белгечлек ачарга җыеналар икән, институтны киңәйтү, яңа корпус төзү дә күздә тотыла. Ректор эшне җигелеп тартучы кайбер хезмәттәшләре турында да сөйләп алды. Аннары, бераз тын торганнан соң, мине шактый гаҗәпләндереп, әйтеп куйды: «Шулай да минем урын түгел бу. Миңа Чаллы масштабы җитми. Беләсең, мин бай тормыш тәҗрибәсе туплап өлгердем бит инде».

Беләм, билгеле. Якын дуслар булмасак та Рәис Беляевнең хезмәте, үсеш юлы минем күз алдында үтте. Студент вакытында ук камытның зурын киерттеләр: Казан дәүләт университеты комсомол комитетының секретаре итеп сайладылар. Юрист дипломы алганнан соң да бу вазыйфаны берничә ел башкарды әле ул. Нәкъ менә шушы елларда оештыру эшенең бөтен нечкәлекләренә өйрәнеп өлгерде Рәис. Аннары – комсомолның өлкә комитеты, партиянең Бауман район комитеты. Һәм, ниһаять, Чаллы-КамАЗ, шәһәр төзелешләре... Бөтен сәләтен тулы көчкә күрсәтә алды ул биредә. Әмма барлык планнарын гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирмәделәр шул. Казанга күчерделәр. Партия өлкә комитетында идеология секретаре булды, аннары – ректор.

Бу Рәис Кыямович белән соңгы очрашуыбыз булды. Бүгенгедәй хәтердә әле ул. Ректор бер-бер артлы берничә сигарет тартты. Аның тирән уйларга батканлыгы күренеп тора иде. Мин аңа комачауламаска тырыштым. Эреле-ваклы адымнар белән бүлмә буйлап йөрендем.

Бераздан безгә чәй керттеләр. Сөйләшмичә генә аны эчәргә

Әгъзам Фәйзрахманов Рәис Беляев белән әңгәмә кора. 1996 ел

керештек. Чокырларыбызны бушатуга, минем өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булып алды. Ректор, башын түбән иеп, үксеп еларга кереште. Бераз тынычлана төшкәч, болай диде: «Мине яраткан эшемнән, КамАЗдан аеру – әле бернәрсә. Миннән алкаш та ясадылар бит. Мәскәүгә барып эчү мәҗлесе оештырган, дип, данымны бөтен илгә тараттылар. Нинди хурлык. Бу вакыйгадан соң берничә ел үтеп китсә дә, һаман тынычлана алмыйм әле».

Матбугат хезмәткәре буларак, әлеге вакыйгадан хәбәрдар идем. Эш шунда ки, Мәскәүдә әдәбият һәм сәнгать декадасы тәмамлангач, Татарстаннан анда катнашкан бертөркем эреле-ваклы җитәкчеләр тулай торакта чәй эчеп утыралар. Кемдер, символик рәвештә тотып куяр өчен аракы да алып кергән була. Әлеге тантаналарда катнашкан бер җитәкче, мәсьәләне нык кабартып, партия өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Усмановка җиткерә. Эчү мәҗлесе оештыру турындагы мәсьәлә – киңәшмәдә, аннары өлкә комитетының бюро утырышында тикшерелә, анда катнашучыларның күбесенә «выговор» бирелә. Бу хакта республика газеталарында хәбәрләр урнаштырыла. Туфан Миңнуллинның, егетлек күрсәтеп, мәҗлесне мин оештырдым, дип раславы да башкаларны җаваплылыктан коткармый. Тик авырлык делегация җитәкчесе Рәис Беляев җилкәсенә төшә.

Әлеге фотога күз салган саен, Рәис Кыямович белән соңгы очрашуым күз алдына килә. Республика тарихында җуелмас эз калдырган олуг шәхес, безне ятим итеп, арабыздан иртәрәк китеп барды шул. Кызганыч, бик кызганыч, аны саклый алмадык. Үзебез гаепле. ■

Истә, һаман да истә!

Тел галиме, профессор Гыйбадулла Алпаровның тууына 130 ел

Атаклы тел галиме, педагог, җәмәгать эшлеклесе, профессор Гыйбадулла Хәбибулла улы Алпаров 1888 елның 3 декабрендә Башкортстанның Авыргазы районындагы Корманай исемле татар авылында туа. Уфадагы «Госмания» һәм «Галия» мәдрәсәләрендә белем ала.

Алпаровның гыйльми эшчәнлеге бик иртә башлана. Беренче мәкаләләре 1910 елда Оренбургта чыга торган «Шура» журналында күренә башлый. 1912 елда 24 яшендә «Хәреф вә имлябыз» дигән тәүге фәнни эше, 1913 елда «Татар әлифбасы» басылып чыга.

1913 елда Гыйбадулла Алпаров Казандагы Укытучылар мәктәбен тәмамлый. Троицкида балалар укытып Корманайга кайткач, 1914-1918 елларда туган ягында мәдәни-мәгърифәт эшчәнлеген җәелдерә, фәнни эзләнүләр алып бара. Шул вакытта Мәҗит Гафури белән аралаша. М.Гафури аны Башкортстан мәктәпләре өчен уку китаплары язуга җәлеп итә.

1921-1924 елларда Урта Азиядә казакъ һәм төрекмән телләренең орфографиясен төзүдә катнаша. Төрекмән галиме М.Гилдиев белән берлектә 1924 елда төрекмән мәктәпләре өчен әлифба нәшер итәләр.

Г.Алпаров 1926 елдан ТАССР Мәгариф министрлыгы һәм Көнчыгыш педагогика институтында эшли. 1926 елда Ленинградка Шәрыкне өйрәнү институтына укырга җибәрелә.

1936 елда вафат була. Кабере – Яңа бистә зиратында.

Шагыйрь Марсель Гыймазетдиновның тууына 75 ел

Шагыйрь Марсель Гыйльфан улы Гыймазетдинов 1943 елның 11 декабрендә Менделеев (элеккеге Бондюг) районының Бәзәкә авылында туган. Әтисе Гыйльфан шушы авылда 20 ел авыл советы рәисе булып эшли, Колхозлар оештырып йөри, беренче коммунист була. Әнисе Гәзизәбану өйдә балалар үстерә. Марсель Гыйльфан улы мәктәптә укыганда комсомол оешмасын житәкли, гел 5ле билгеләренә генә укып, 10 сыйныфны тәмамлагач, Алабуга пединститутына укырга керә. Аны уңышлы гына тәмамлап, Ык Тамагы авылында – мәктәп директоры, соңрак районда – интернат директоры, аннары Батыр Кул колхозында партоешма секретаре булып эшли. Бераздан аны Тукай исемендәге колхозга рәис итеп сайлыйлар. Татар Чаллысы авылыннан Мунайка авылын аерып, аерым колхоз оештырыла һәм аңа Татарстан колхозы исеме бирелә. Бу колхозның житәкчесе итеп Марсель Гыймазетдиновны куялар. Авылга газ кертеп, юллар салдырып, колхозчыларга йортлар салдырып эшләп йөргәндә, 1993 елның 19 апрелендә аның йөрәге тибүдән туктый.

Безнең мирас №12 декабрь 2018

Драматург Хәй Вахитның тууына 100 ел

Классик драматург, ТАССРның (1968) һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1978), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәй Вахит (Габделхәй Каюм улы Вахитов) 1918 елның 20 декабрендә Биектау районының Мәмдәл авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа.

1934 елда җидееллык мәктәпне тәмамлый. Шуннан соң, Казанга килеп, театр техникумына укырга керә. Ләкин ике елдан соң техникум ябыла. Габделхәй Чистай районының Яңа Роман авылына укытучы булып китә.

1937-1940 елларда Казанда музыка училищесында укый.

Бөек Ватан сугышында башыннан ахырына хәтле катнаша. Сугыштан соң Казан дәүләт консерваториясенең теория-тарих факультетын тәмамлый. 1956-1958 елларда Мәскәүдә югары әдәби курсларда укый. Шул вакыттан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр ул язучылык эше белән генә шөгыльләнә.

Хәй Вахит сугышка кадәр иҗат итә башлый. 1938-1939 елларда аның «Сорыкортлар» исемле пьесасы һәм «Дулкыннар» дигән шигырьләр җыентыгы басылып чыга.

Язучы шулай ук балалар өчен шигырьләр һәм, халык иҗаты әсәрләренә нигезләп, поэмалар да яза.

Ләкин Хәй Вахитны язучы итеп таныткан жанр – драматургия. Аның «Беренче мәхәббәт» (1960), «Кайда соң син?» (1963), «Соңгы хат» (1966), «Туй алдыннан» (1969), «Ике килен-килендәш» (1976) һәм башка әсәрләре театр сәнгатендә зур уңыш яулый һәм тамашачыларның мәхәббәтен казана.

1956 елдан ул СССР Язучылар берлеге әгъзасы.

1960 елда «Беренче мәхәббәт» драмасы өчен Хәй Вахит Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

Хәй Вахит 1978 елның 7 июлендә дөньядан китә.

Артист Барый Әшрәповның тууына 100 ел

ТАССРның атказанган артисты Барый Әшрәп улы Әшрәпов 1918 елның 28 декабрендә Мамадыш районының Ишки авылында туа.

1939 елда Мамадыш педагогия училищесен тәмамлый. 1940-1946 елларда – хәрби хезмәттә. 1950 елда Татар театр училищесын тәмамлый һәм өч ел Минзәлә театрында эшли. 1953 елда Татар академия театрына күчә.

Ул уйнаган рольләр: Кочкарев – «Өйләнү» (Н.Гоголь), Сәйфетдин – «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), Лепорелло – «Таш кунак» (А.Пушкин), Сибгат, Бәдри – «Галиябану» (М.Фәйзи), Шәкерт – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Байтирәк – «Кыю кызлар» (Т.Гыйззәт), Шәехмирза – «Американ» (К.Тинчурин), Гаделша – «Ике килен-килендәш» (Х.Вахит) һ.б. ТАССРның атказанган артисты (1976 ел).

1982 елда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

Адлер Тимергалин

АБЫЗАГАЙЛАР ХӘРӘКӘТЕ – XVIII гасыр ахырларында-XIX гасыр башларында татар руханилары арасында иҗтимагый-сәяси һәм дини хәрәкәт. Әдәбиятта *Абызлар хәрәкәте* («Движение абызов») термины да йөри. Мәсгуд Гайнетдин абызагайлар турында: «Абызагайлар – Диния нәзарәтенә буйсынудан, Указ алудан, имтиханга барудан баш тартучы демократик авыл руханилары, үз заманының укымышлылары (абызлары)», – дип яза.

Бу хәрәкәт татарлар арасында дини-реформаторлык һәм рационалистик идеяләрнең таралуына булышлык иткән. Абызлар хәрәкәтендә, мәсәлән, татар дин эшлеклесе, суфи шагыйрь Әбелмәних Каргалыйның да катнашканлыгы билгеле.

1667-1671 елларда Степан Разин, 1711 елда исә Батырша кузгалышында катнашкан мөселманнарга, Морад мулла һәм Хисаметдин Мөслими идеяләренә шушы абыз агайлар хәрәкәтенең йогынтысы зур булган.

Борынгы Болгар шәһәрен «изге ватан» итеп санау һәм торгызу идеясе абызлар хәрәкәте белән аерылгысыз бәйләнгән.

XIX гасыр башларына абызлар хәрәкәте әкренләп сүнә барып, аргы төбәкләрдә (Урал буенда, мишәрләр яшәгән җирләрдә) генә кала, ә XIX гасыр урталарына, Оренбург мөселман рухани җыелышы эшчәнлеге тамыр җәйгәннән соң, әлеге хәрәкәт юкка чыга, дияргә мөмкин.

АГАЧАТ – башкортта: киребеткән, үҗәт ат. Димәк, төркиләрдә «агач атка атландыру» фразеологизмының туры мәгънәсе дә булган икән. //*Агачатка менмә, сабыйга тимә, күккә сөянмә* – мәкаль. ...*Кайвакыт мәҗнүн кеби көлмәс вә шатланмас идем, – Син агач ат өстенә атландыручы булмасаң*. Тукай.

Гомумән, «агач атка атлану», «агач атка атландыру» (берәр кешене хәйлә белән алдалау, төп башына утырту) гыйбарәсен борынгы җырчы Гомерның «Илиада»сына (агачтан ясалган «Троя аты»на) гына бәйләп аңлату белән

Ахыры. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

Агачтан ясалган «Троя аты»

килешеп булмый, чөнки, телебездә шул ук мәгънәдәге «таякка атландыру» гыйбарәсе дә яши, – ихтимал, анысы беренчелдер әле. Өстәвенә, данайлылар троялыларга бүләк иткән атка (рус телендә «троянский конь») берәү дә атланмый һәм атлана да алмый, чөнки бу эче куыш ат корсагында данайлы сугышчылар посып ятарлык зур урын булган.

Татар телендәге «җилгә атлану» сүзе дә әлеге мәгънәви рәткә карый.

АДӘМ УЛЫ – Инҗилнең татарчага тәрҗемәсендә «Сын Человеческий» мәгънәсендә алынган. Семит телендә – *Бар-наша*. Борынгы төрки чыганакларда – *йалңук оглы* (*огланы*) дигән сүз бар (адәм баласы). Шәйхзадә Бабич үзенең «Газазил» дигән поэмасында *«инсан углы»* сүзен куллана.

Христиан теологлары фикеренчә, «Адәм улы» дигән атамада Иисус Христос күздә тотыла. //*Чынлап әйтәм сезгә: сез Израиль калаларын йөреп бетерә алмассыз, әмма Адәм Улы килер*. (Матфей, 10:23).

Чыганакларга карасак, күп кенә борынгы күрәзәчеләрнең һәм фикер ияләренең (Энох, Моисей, Барух, Ездра) җир йөзенә ниндидер бер куәтле каһарман килеп, адәмнәрне коткарачагы турында әйткән сүзләренә тап булабыз. Ләкин аларның берсе дә бу адәм улының тәрегә кадакланачагы һәм күккә ашачагы, аннары Ахыргы Көндә кабат кайтачагы турында сөйләми.

Дини текстларны борынгы телләр ярдәмендә җентекләп тикшергән проф. Габдел-Әхәд Дауүд (Давид Бенджамен Кельдани) әлеге атамада фәкать Мөхәммәд Пәйгамбәр (с.г.в.) турында гына сүз барырга мөмкин, дип исәпли.

Иоанн Инҗилендәге (Иоанн, 16:7.): *«Әмма Мин сезгә чынны әйтәмен, Минем баруым сезнең өчен яхшырак, Мин бармасам, сезгә Тынычландыручы килмәс шул; әгәр барсам Аны сезгә җибәрермен»*, – дигән сүзләр дә Гайсә пәйгамбәрдән соң дөньяга киләчәк Мөхәммәд (с.г.в.) Пәйгамбәргә нисбәт ителергә тиеш, чөнки Гайсәдән соң килгән башка Бөек зат мәгълүм түгел. ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

Сүз уравын белмәгән *үзенә сүз китерер...*

Рәсим Хәбибулла

Безнең «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә дә бик күп сүзләрнең мәгънәләре дөрес аңлатылмаган. Телебезнең сагында торырга тиешле СҮЗЛЕКтә дә сүзләр дөрес аңлатылмаган икән, ничек итеп «телебезне саклап каласы» иде, дип сүз йөртеп булсын. «Уйлар турында уйлану» («Шәһри Казан», 13 февраль, 2004 ел) исемле мәкаләмдә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н (Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1997) тәнкыйтьләп язган идем. Инде 2005 елда «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»н янә бастырып чыгаргач, тәнкыйть фикерләрен искә алганнардыр, дип шатланган идем. Әмма СҮЗЛЕКтә сизелерлек үзгәрешләр юк, дияргә була, элек 3 томлы булса, яңасы 1 генә томнан тора. Моны инде аңлатыла торган сүзне кулланып, кайбер күренекле шагыйрьләрнең, язучыларның әйткән фикерләрен төшереп калдыру хисабына, 1 том ясаганнардыр, дип уйлыйм. Менә СҮЗЛЕКтәге берничә генә сүзгә күз салыйк әле.

Акыл – *1) кешенең уйлау, фикер йөртү сәләте, аңлылык дәрәҗәсе; 2) иҗтимагый аң, иҗтимагый фикер; 3) уй, фикер, идея; 4) кешенең уйлап эш итү, үзенә, үз хисләрнә ия булу дәрәҗәсе; 5) киңәш; 6) сабак, файдалы нәтиҗә.*

Бу аңлатмалы сүзлек бернәрсә дә аңлатмады, киресенчә, акылдан язарлык итеп бөтен төшенчәләрне бутап бетерде. Әле тагы бик күп нәрсәләр язганнар. Югыйсә: **Акыл – Аллаһы Тәгалә тарафыннан кешеләргә, хайваннардан аермалы буларак, бирелгән бүләк, нигъмәт** – дип кенә язып куясы иде бит.

Тагы аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итәбез.

Фикер – 1**)** *чынбарлыкның аңдагы чагылышы;* 2*) башка килгән уй, идея, караш;* («Фикер» белән «уй» синоним сүзләр була алмый. – *Р.Х.*); 3) *исәп, ният, күздә тоту;* 4) *аң, белем;* (Кеше йә аңлы, йә аңсыз гына була ала, ягъни чирләп китеп яисә башын бәреп аңны югалтырга мөмкин. Икенче төрле әйткәндә, аң – кешенең үз халәтен билгеләүче сүз. Һич кенә дә «фикер» «аң» белән синоним була алмый. – *Р.Х.*); 5) *берәр нәрсәгә мөнәсәбәтне белдергән бәяләмә, нәтиҗә;* 6) *язмадагы яки телдән сөйләмдәге төп, әйтергә теләгән сүз.* Мәсәлән, **фикер –** ***акыл*** *белән* ***ниятне*** *кушып* ***уйлану*** *нәтиҗәсендә туган яңалык, ачыш,* дип язсаң, аңлаешлырак булыр иде.

Әйе, язучы яңа әсәрен иҗат иткәндә, галим тикшеренүләр алып барганда, депутат

закон кабул иткәндә **«фикер иясе»** булырга, ягъни аларда фикер туарга тиеш. Ә фикерне бары тик акыл гына тудыра. Ягъни фикернең **анасы – акыл.** Ә атасы? Фикернең атасы **«ният»** була. Димәк, акыл белән ният никахлашса гына фикер туа, әгәр дә акылның фикер тудыруга сәләте булса. Юкка гына Пәйгамбәребез Мөхәммәд с.г.в. үзенең бер мөбарәк хәдисендә: *«Кешенең кылган гамәлен Аллаһы Тәгалә аның* ***ниятенә*** *карап кабул итә»,* – димәгәндер. Әгәр кешенең акылы фикер тудырырга сәләтле булса, бу кешене без «фикер иясе», ягъни галим, дибез. Кызганыч ки, бүген фикер иясе булмаган галимнәр күбәйде.

Бер халыкның теле һәм мәдәнияте башка халыкныкы белән тәңгәл килә, башка халыкның гореф-гадәтләрен йолаларын, бәйрәмнәрен ашкынып-ашкынып уздырабыз икән (проводы русской зимы, раштуа, изге вәли), бу халык инде милләт булудан туктаган була.

Инде ният турында «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» безгә нәрсә аңлата икән?

Ният – 1) *нәрсә дә булса эшләр өчен алдан корылган уй-план* («Ният» белән «уй» синоним була алмый. – Р.Х.); 2) *дини. Берәр төрле теләк тормышка ашсын өчен Хуҗа Бәһаветдин (әүлия) исеменә багышлап дога уку.* (Бу икенче пункт, гомумән, аңлаешсыз һәм мөселманнар һичкайчан да Хуҗа Баһаветдин исеменә багышлап дога кылмыйлар.)

Бәлки**, ният** – *нәрсә дә булса эшләр өчен туган теләк,* дип кенә язарга кирәк булгандыр.

СҮЗЛЕКтә: **Уй** – 1) *аңны тулысынча биләп алган фикер;* 2) *фикер, акыл; 3) фикерләү нәтиҗәсе, идея; 4) ният, теләк, исәп, караш; 5) сагыш, борчу.*

Уй – *акылның эшләү халәте, акылның эшчәнлеге, акылны эшләтү процессы,* дип кенә язсалар яхшы булыр иде.

Әгәр дә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ннән китерелгән «аңлатма»ларга карасак, **«акыл», «фикер», «уй», «аң», «киңәш», «сабак», «ният», «теләк», «план»** — барысы да үзара синоним сүзләр булып чыга, ә асылда исә бу сүзләр һәрберсе үзенә бер аерым мәгънәгә ия.

Инде «Русча-татарча сүзлек»тән берәр сүз эзләп табармын, димә. Монда ким дигәндә 40% сүзнең тәрҗемәсе юк, дөресрәге, русча да, татарча да берүк. Мисал өчен, **профиль** – *профиль,* **профком** – *профком,* **профсоюз** – *профсоюз,* **процедура** – *процедура,* **процесс** – *процесс,* **профессионал** – *профессионал,* **журнал** – *журнал,* **журналист** – *журналист.* Мин монда вакыт исраф итмәс өчен «Русча-татарча сүзлек»нең (Мәскәү. «Рус теле», 1991) төрле битләрен актарып тормадым, ирекле рәвештә бер битен ачтым да берничә сүзне генә китердем. Габдерәхим Утыз Имәни, Ризаэддин Фәхреддиннәр менә шушы сүзләр белән сөйләшмәгәннәр бит инде. Бу сүзләрнең татарчасын милләтебездән мәҗбүриләп кысрыклап чыгардылар. Бер халыкның теле һәм мәдәнияте башка халыкныкы белән тәңгәл килә, башка халыкның гореф-гадәтләрен йолаларын, бәйрәмнәрен ашкынып-ашкынып уздырабыз икән (проводы русской зимы, раштуа, изге вәли), бу халык инде милләт булудан туктаган була. Әлеге дә баягы СҮЗЛЕКтән «милләт» сүзенең аңлатмасын карыйбыз: **милләт ис.** – *тел, территория, икътисади тормыш, психик үзенчәлекләр һәм культура уртаклыгы нигезендә бергә берләшкән, тупланган халык.* Асылына тирәнрәк төшенсәк, бу сүзгә саллырак һәм камилрәк аңлатма биреп булыр иде!

Кыскасы, **«Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»** һәм **«Русча-татарча сүзлек»**не өр-яңадан, бер генә сүзне дә тәрҗемәсез калдырмыйча, асыл телебезнең сүзләрен кулланып эшкәртеп бастырып чыгаруны кирәк, дип саныйм. ■

Татарстан Республикасының Милли китапханәсе

XIX ГАСЫР АХЫРЫ-XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ҺӘМ ШӘРЫК ВАКЫТЛЫ МАТБУГАТЫ ТУПЛАНМАСЫ

Китапханәнең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендәге татар һәм шәрык әдәбияты бүлекчәсендә, кульъязма һәм басма китаплар белән беррәттән, XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы татар һәм шәрык вакытлы матбугаты басмалары да саклана. Алар – гарәп, латин, кирилл хәрефләре белән Россия империясендәге төрки һәм мөселман халыклары телләрендә, шулай ук төрек һәм гарәп телләрендә чыккан газета һәм журналлар. Хәзерге вакытта тупланмада төрле тематикага караган 119 исемдәге журнал һәм 42 исемдәге газета нөсхәләре бар.

1906 г. № 40

Литературн., политическ. и коммерческ. газета „ТЕРДЖИМАНЪ", три раза въ недѣлю. Г. Бахчисарай

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

XX гасыр башының күренекле татар газеталары: 1906 елдан алып 1918 елга кадәр Оренбургта татар язучысы һәм журналисты Фатих Кәрими нәшер иткән «Вакыт», Казанда чыккан «Йолдыз» (Әхмәтһади Максуди мөхәррирлегендә һәм наширлегендә), «Казан мөхбире» (нашире – Сәетгәрәй Алкин), «Кояш», «Әл-Ислах», «Әхбар», «Бәянел-хак», «Тавыш» һ.б. – тупланманың кыйммәтле байлыгы. Шулай ук биредә кайбер саннары саклана торган «Нур» һәм «Өлфәт» газеталары – Петербургта, «Ил» газетасы – татар әдәбияты классигы һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый тарафыннан – Мәскәүдә, «Идел» – Әстерханда (мөхәррире – Габдрахман Гомәри), «Фикер» Җаек (Уральск) шәһәрендә (мөхәррире – Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин) нәшер ителгәннәр.

Танылган мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспринский 1883-1918 елларда Бакчасарайда

Безнең бай китап саклау мирасханәсенә рәхим итегез. Һәм белегез, анда күп гасырлар дәвамында кешелекнең хакыйкатьне һәм матурлыкны аңлау юлындагы иң яхшы һәм гыйбрәтле үрнәкләре тупланган. Шулай ук акыл ияләренең уртак моназара мәҗлесендә үзегезне чакырылмаган кунак итеп тә тоя күрмәгез, җаныгыз теләгән җирдән урын алыгыз. Менә шул чагында, төрле халыкларның төрле чорларда иҗат иткән шагыйрьләре, галимнәре, артистлары һәм тарихчыларының гүзәлдән-гүзәл мираслары белән күзгә-күз очрашкач, мөмкинлекләрегезнең чикләрен тәгаен билгели алырсыз һәм сезнең алда моңарчы күрелмәгән биниһая киңлекләр ачылыр.

Пьер Корнель

(Кырым) нәшер иткән, Россия мөселманнарының гомуммилли матбугат органына әверелгән «Тәрҗеман» газетасы саннары китапханәдә аеруча кадерләп саклана.

Биредә «Татарстан» (1922-1924) газетасын да, 1924 елдан соң чыккан «Кызыл Татарстан»ны да күрергә мөмкин. Хәзерге көндә аларның дәвамчысы буларак республикакүләм «Ватаным Татарстан» газетасы чыгып килә.

Мондагы «иң өлкән» журнал – 1881 елгы «Мәҗмугаи Әбүз-зыя», ул Истанбулда төрек телендә чыккан, шул заманның алдынгы фән һәм техника казанышларын яктыртуга махсуслашкан булган. Беренче татар журналларыннан 1906-1907 елларда Җаекта Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин чыгарган «Әл-гасрел-җәдид»не, 1906-1917 елларда Казанда Галимҗан Баруди нәшер иткән «Әд-дин вәл-әдәб»не, 1908-1913 елларда Самарада дөнья күргән «Икътисад»ны, 1907 елда Мәскәүдә атаклы татар язучысы Фатих Әмирхан катнашлыгында чыккан «Тәрбияи-этфаль»не аерып күрсәтергә мөмкин. Инкыйлабка кадәр һәм аннан соң нәшер ителгән татар журналлары үзләренең яктырткан тематикалары белән шактый төрле булган, мәсәлән:

– дини журналлар – «Әд-дин вәл-әдәб», «Дин вә мәгыйшәт», «Ислам мәҗәлләсе»;

– фәнни-сәяси журналлар – «Аң», «Әл-гасрел-җәдид», «Шура»;

– икътисади (экономикага караган) журналлар – «Икътисад», «Русия сәүдәсе»;

– белем бирү һәм мәгърифәтчелек мәсьәләләрен яктырткан журналлар – «Мәктәп», «Мәгариф», «Мөгаллим»;

– хатын-кыз журналлары – «Сөембикә», «Азат хатын», «Шәрык кызы»;

– балалар журналы «Ак юл»;

– сатира һәм юмор журналлары – «Карчыга», «Чаян», «Ялт-йолт», «Чүкеч» һ.б.

Һөнәри журналар да чыккан. 1927-1930 елларда Казанда Татар дәүләт академия театры нәшер иткән «Тамашачы» – шундыйларның бер үрнәге.

Тупланманың төп өлешен тәшкил итә торган журналларның күпчелеге – татар

Китап – тормыш көзгесе.

Татар халык мәкале

телендәгеләр, шулай ук кырымтатар, казакъ, азәрбайҗан, үзбәк, төрек, гарәп һәм башка телләрдә басылган кайбер журналларның берәр яки берничәшәр саннары бар. Мисал өчен, «Әл-Мәнар» («Маяк») дип аталган Мисыр фәнни журналы (XX гасыр башы), фән һәм мәгариф мәсьәләләренә багышланган «Мaариф» төрек журналы.

XX гасыр башының кайбер вакытлы матбугат басмалары, әлбәттә, зур үзгәрешләр белән, хәзер дә чыгуларын дәвам итә. Мисал өчен, «Мәгариф» дигән татар журналы шушы исеме белән 1918-1936 елларда нәшер ителгән, 1936 елдан соң «Совет мәктәбе» исеме белән чыккан, 1991 елда аңа башлангыч атамасы кайтарылды. «Безнен юл» журналын хәзерге укучылар «Казан утлары» буларак беләләр. 1924-1929 елларда Мәскәүдә нәшер ителгән «Кечкенә иптәшләр» журналының бүгенге дәвамчысы – «Ялкын» журналы.

Дәвамы бар ■

Безнең мирас №12 декабрь 2018

Симетбаш мәчете

Моннан нәкъ бер ел элек Арча районының Симетбаш авылында «Таттелеком» АҖ генераль директоры ***Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин*** *һәм аның җитәкчелегендәге егетләрнең матди ярдәме белән салынган «Нурислам» мәчетен тантаналы ачу вакыйгасы булган иде. Аллаһ йорты төбәкнең атаклы шәхесе, игенче-механизатор* ***Нурислам Шәфигулла улының*** *тууына 90 ел һәм бөтен дөньяга мәшһүр дин галиме* ***Шиһабетдин Мәрҗани****нең тууына 200 ел тулу уңаеннан салынды. Әлеге күркәм вакыйганы хәтердә яңартыйк әле!*

ТР Диния нәзарәтенең баш казые ***Җәлил хәзрәт Фазлыев:*** **«МӘЧЕТКӘ СУКМАКНЫ ӨЗМӘГЕЗ!»**

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Йа Раббым, мәчетне динебезгә хезмәт итүче биналардан кыйлсаң иде. Моны төзүчеләрнең авыл халкы алдында йөзләре ак. Әгәр шуның сукмагын кыш көне – кар, җәй көне үлән кумсә, сез гөнаһлы буласыз! Үзегез генә түгел, балаларыгыз да мәчеткә сукмакны өзмәгез!»

Арча муниципаль районы башлыгы ***Илшат Нуриев:*** **«БЕЗГӘ, БЕР МИЛЛӘТ БУЛЫП, ДУСТАТУ ЯШӘРГӘ ЯЗСЫН!»**

«Лотфулла Нурислам улының эшләре үзенә дә зур изгелек булып кайтсын! Районыбызда аның ярдәме белән дистәләгән тарихи һәм табигый объект төзекләндерелде,

яңа биналар салынды. Район халкы аңа бик рәхмәтле. Без бүген, Аллага шөкер, бер команда булып, халкыбызга, милләттебезгә хезмәт итәбез. Симетбашта шундый затлы мәчет сафка баскан икән, аның ишекләре беркайчан да ябылмасын. Үткәнен, телен, динен оныткан халыкның киләчәге юк! Безгә, бер халык, бер милләт булып, дус-тату яшәргә язсын!»

«Таттелеком» АҖ генераль директоры
Лотфулла Шәфигуллин:
«СИМЕТБАШ БАЛАЛАРЫ ГАРӘП, ТАТАР, РУС ҺӘМ ИНГЛИЗ ТЕЛЛӘРЕН БЕЛЕРГӘ ТИЕШ!»

«Безнең авылда гаять көчле кешеләр яшәгән һәм яши. Революциягә кадәрге халык санын алу мәгълүматларына караганда, Симетбашта 87 йорт булган, 257 ир-ат, 252 хатын-кыз яшәгән. Авыл мәчете карамагындагы мәктәптә 27 кыз,

25 ир бала белем алган. Бүген исә, шаяртып: «Симетбаш – артистлар һәм элемтәчеләр авылы», – диләр. Дөрестән дә, биредә ике халык артисты – Габделфәт Сафин һәм Раушания Фәйзуллина туып үскән. Кеп-кечкенә генә туган авылымның Татарстан Республикасына 11 атказанган хезмәткәр бирүе – зур горурлык. Әтием Нурисламның бертуган энесе Нургали Шәфигуллин, Бөек Ватан сугышында зур батырлыклары өчен, Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә, әмма татар ефрейторын сугышчан «Кызыл Байрак ордены» белән генә бүләклиләр.

Гыйбадәтханәнең бер өлеше мәчет булса, икенче ягы – мәдрәсә. Симетбаш балалары гарәп, татар, рус һәм инглиз телен белеп үсәргә тиеш. Күрше авыл балалары да биргә килеп белем алыр, алардан әле тагын республикабызның данлыклы шәхесләре үсеп чыгар, дип уйлыйм».

ТР Диния нәзарәте рәисенең урынбасары
Илфар хәзрәт Хәсәнов:
«АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ РАЙОН ХАЛКЫНА ТЫНЫЧЛЫК, БӘРӘКӘТ, ИМИНЛЕК ИҢДЕРСӘ ИДЕ»

«Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим. Мөбарәк мәүлед аеның җомга көнендә изге вакыйгага – шушы мәчетне ачу тантанасына җыелдык. Лотфулла әфәнде, Аллаһы Тәгалә кылган эшләрегездән, игелекле гамәлләрегездән үзе разый булсын. Раббыбыз Коръәндә: «Әй иман китерүчеләр һәм игелекле эшләр кылучылар! Иман китергәннән соң игелекле эшләр белән без үзебезгә җәннәткә алып бара торган юлны төзибез», – ди. Аллаһы Тәгалә шушы авылдан бакыйлыкка күчкән мәрхүмнәрнең рухларын шат кылса, район халкына тынычлык, бәрәкәт, иминлек иңдерсә иде».

Илфар хәзрәт Хәсәнов Лотфулла Нурислам улын, ошбу вакыйга уңаеннан, ТР Диния нәзарәтенең рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллинның Рәхмәт хаты, шулай ук «ТР Диния нәзарәтенең 25 еллыгы уңаеннан һәм мөселман өммәте үсешенә өлеш керткәне өчен» медале белән бүләкләде. Мәчеттә беренче җомга вәгазе Җәлил хәзрәт Фазлыев тарафыннан сөйләнде. ■

КУКМАРА МИРАСЫ

Киез итекләр иле

Әгәр Кукмараны үзенә күрә бер кечкенә ил дип гоман кылсак, аны, һичбер икеләнүсез, «Киез итекләр иле» дип йөртергә булыр иде.

ИГЕЛЕКЛЕ СӘҮДӘГӘРЛӘР

Мәгълүм булганча, унтугызынчы гасырда Россиядә яшәгән һәм хезмәт куйган беренче гильдия дәрәҗәсендәге сәүдәгәрләр гаять зур абруй казанганнар. Алар хәтта шәһәр хакиме вә җирле хөкемдар итеп тә сайлана алганнар. Икенче дәрәҗәдәгеләр – бургомистрлар. Болар – елга-сулыклардагы транспорт хәрәкәте белән идарә итүчеләр. Өченче дәрәҗәдәгеләр исә – кала вә сала старосталары һәм алар җирле депутат вазыйфаларын башкара алган. Бу җәһәттән, хәзерге Кукмара районына караган җирлектәге фабрикантлар һәм сәүдәгәрләр дә читтә калмаган, алар да җәмәгать тормышындагы мәсьәләләрне хәл итүдә актив катнашкан. Һәртөрле хәйрия җәмгыятьләрендә әгъзалык, җирле үзидарәдә булу хакимият тарафыннан хупланган, хәтта дәүләт эше итеп саналган. Эре хәйриячеләрне орден-медальләр белән бүләкләгәннәр, төрле чин-дәрәҗә вә мактаулы исемнәр белән олылаганнар. Мәсәлән, сәүдәгәрләр С.В.Комаров белән М.Д.Родигин 1899 елда Мамадыш шәһәре һәм өязенең халык җыенына вәкил итеп сайланган.

Кукмара авылындагы беренче мәктәп 1851 елда ачыла. Мәктәп бинасын салу чыгымнарын сәүдәгәрләр күтәрә. 1889 елда исә Кукмарада ике сыйныфлы министрлык көллияте ачыла һәм аның попечителе итеп фабрикант Н.В.Комаров билгеләнә. 1908 елда биредә 41 малай һәм 46 кызның укуы билгеле. Ике сыйныфлы, дип аталса да, уку биш ел дәвам иткән. Һөнәри белем бирүнең зур үсеш алуына мисал итеп, 1913 елда Вавилов йортында йон эшкәртү-киез басу машиналарында эшләргә өйрәтү мәктәбе ачылуын әйтергә мөмкин. Революциядән соң ул киез итек фабрикасына бирелә, соңрак исә ФЗӨ (фабрика-завод өйрәнчекләре) мәктәбе итеп үзгәртелә.

Н.В.Комаров бүләкләнгән Анна тасмасындагы Алтын медаль

1899 елда Кукмарада ун ятаклык хастаханә ачыла. Аны эшләтеп җибәрү, матди яктан ярдәм итү тулысынча җирле фабрикантлар җилкәсенә төшә.

Кукмараның сәнәгатьчелек тарихында эре эшмәкәр Николай Васильевич Комаров еш телгә алына. Бу җәһәттән аның тәрҗемәи хәлен дә берникадәр шәрехләп китү урынлы булыр. Ул 1862 елның 20

Ике сыйныфлы министрлык көллияте. 1889 елгы фото

октябрендә Кукмара авылында дөньяга килә. Вятка губернасының Малмыж каласында һөнәри белем бирү мәктәбендә укыганнан соң, әтисе белән абыйсына кушылып, Кукмарада киез итек басу һәм аны сату эшенә керешә. 1884-1886 елларда урыс армиясендә гади солдат булып хезмәт итә. 1892 елда инде ул үзләре оештырган «Бертуган Комаровлар» сәүдә йортының әйдәп баручы хуҗасына әверелә һәм бу 1918 елга кадәр шулай була да. Тик, большевиклар хакимияте урнашкач, фабрикаларын һәм йортларын аларга тапшырырга мәҗбүр була... Гомеренең соңгы елларында аның Казандагы «Татваленки» трестында эшләп йөрүе генә мәгълүм. ■

Н.В.Комаровның үз йорты каршында иганәче сәүдәгәр иптәшләре белән төшкән сурәте. 1907 елның 8 июне. Кукмара авылы. Беренче рәттә: А.А.Родигин, В.М.Микушев, А.Д.Ветошкин, Володя Комаров, Н.В.Комаров, Шура Комаров, В.Е.Куракин, М.А.Ошурков, Н.В.Черногубов. Икенче рәттә: М.Гусев, Л.Чирков, С.И.Соловьев, Н.В.Решетников, П.Я.Савиных, И.И.Молчанов, Н.Родигин. Өченче рәттә: С.С.Гусев, И.М.Шарматов, П.А.Вычужанин, А.В.Мельников, И.А.Мальчиков.

ФОТОХАТИРӘ

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин (1954-2017), «Кукмара киез-киез итек комбинаты»ның 1988-2017 еллардагы генераль директоры:

«Узган гасырның туксанынчы еллары – авыр төш кебек... Товар өчен түләмиләр, предприятие аздан гына бөлми калды. Эшчеләребез киез итекне базарларга чыгып сата иде хәтта. Аннары бартерга эшли башладык. Без, мәсәлән, вагон-вагон киез итекне мебельгә, кием-салымга, тегү, кер юу машиналарына, телевизорларга, кыскасы, мөмкин булган һәр товарга алмаштыра идек.

«Яп, фабрикаңны, азапланма юкка!» – диючеләр дә булды, рейдерларча кулга төшерергә дә маташтылар безне, үзгә продукция җитештерергә дә өндәделәр. Шөкер, бирешмәдек! Бирешкән булсам, кешеләрнең күзенә ничек карар идем соң мин?!»

Шамил Михәйдәр улы Әхмәтшин иганәсе белән чыккан китаплар



Кукмара киез-киез итек комбинатының цехларына һәм кибетенә сәяхәт



НОЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында



● Татар әдәбияты классигы Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» повесте, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатих Кутлу тәрҗемәсендә, шушы көннәрдә Төркиянең Истанбул шәһәрендәге «Палто» нәшриятында дөнья күрде.

● Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары – шагыйрьләр Газинур Морат, Марат Закир, Рифат Җамал Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск каласында сәяси репрессия корбаннарын искә алу чараларында һәм татар җәмәгатьчелеге белән очрашуларда катнашты.

● 10 ноябрьдә Казанда танылган милләттәшебез, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Алсу Сафина яңа концерт программасын күрсәтте.

● 12 ноябрь көнне Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубында танылган язучы һәм журналист Вакыйф Вәкил улы Нуриевка 60 яшь тулу уңаеннан «Җаннарны чайкар чак» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды.

● 15-16 ноябрь көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессы «Татар дөньясында этнотуризм һәм туган якны өйрәнү: хәзерге торышы һәм перспективалары» дип исемләнгән бөтенроссия фәнни-гамәли, тарихи-туган якны өйрәнү конференциясен оештырды.

● 16 ноябрь көнне Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында бик күп сынаулар узып финалга чыккан 14 кыз янә үз осталыкларын күрсәтте. «Татар кызы – 2018» дигән мәртәбәле исемгә Удмуртия Республикасы гүзәле Диләрә Гыйльметдинова лаек дип табылды. Ул асылташлар белән бизәлгән таҗга һәм төп бүләк – Lada Granta машинасына ия булды.

● 16 ноябрьдә Арча районының Түбән Мәтәскә мәктәбендә рәссам һәм шагыйрь, сугыш ветераны Фарух Әхмәдуллинның тууына 90 ел тулу уңаеннан күргәзмә ачылды.

● 15 ноябрь көнне Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Рауза Хәйретдинова бакый дөньяга күчте.

● 16 ноябрь көнне Татарстанның Беренче Президенты, ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевнең хатыны Сәкинә Шакир кызы Шәймиева каты авырудан соң вафат булды.

● 19 ноябрьдә Болгар шәһәрендә Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) туган көне уңаеннан «Мәүлед ән-Нәби» бәйрәме тантаналары башланды. Бәйрәм Коръән уку һәм Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин догасы белән ачылды. Татарстан Республикасы премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразиев кунакларны Татарстан җитәкчелеге, Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән сәламләде һәм Мәүлед бәйрәме белән тәбрикләде.

● 20 ноябрь көнне Арча районында юкка чыккан авыллар буенча беренче треккинг оештырылды. Бу сәяхәт Яңа Әтнә – Өстеял авыллары маршруты буенча узды.

● 20 ноябрьдә Казанның Кабан күле яр буенда бөек татар галиме, дин әһеле, фәлсәфәче Шиһабетдин Мәрҗанигә һәйкәл ачу тантанасы үтте. Чарада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, ТРның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һ.б. катнашты.

● 21 ноябрь көнне Арча шәһәрендә районның яшь иҗатчыларына Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык язучысы Гариф Ахунов исемендәге премия бирү тантанасы булды. Әлеге премия быел унынчы тапкыр тапшырылды. Бу чарада язучының кызы, шагыйрә Наилә Ахунова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, драматург һәм прозаик Данил Салихов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, язучы Рөстәм Галиуллин, әдипләр Вакыйф Нуриев һәм Рифат Җамал катнашты. ■

Безнен мирас №12 декабрь 2018

Мирасворд

Агач яки кура кабыгының кайры астындагы сусле катламы

Җеп эрләү өчен йон, мамыкны беркетә торган таракны такта

Акрын кыймылдаучан, ялкау (диал.)

Фарсылар патшасы

Фин-угор халкы

Борынгы Римда бакыр акча

Шагыйрь Мифтах …

Перу каласы

Сугылган башак

… Шаһиди

Язучының иҗат җимеше

Язучы … Вәлиев

Урта Азия халкы

Казакълар һәм кыргызлар кия торган колакчынсыз бүрек

Пулядан саклану чокыры

Ил башлыгы, ил хуҗасы (иск.)

Дус - …

Көлтә бәйли торган богрыч (диал.)

Хурлык, мәсхәрә

Имамов, Хаков

… Емельянов (керәшен татар шагыйре)

Скрипка сыман борынгы уен коралы

Әмирхан Еники хикәясе

«… вә Димнә» ядкаре

Нечкә билбау

«… Скала» (Милан театры)

Җылы, дымлы көндә җирдән күтәрелгән пар, томан

… Исәнбәт

Асылташ төре

Сталинның тәхәллүсе

Тукай яратып йөргән кыз

Иллюзионист Эмиль …

Грузия акчасы

Әйттем … кайттым

Бер … - үзе бер гомер

Гарәп хәрефе

Ярдәмче фигыль

«… кыз» әкияте

Урта гасыр әзербайҗан шагыйре

Хәсәнов, Идиятуллин

Тормыш ләззәтеннән ваз кичеп, теләнче хәлендә ил гизеп йөрүче

11 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Сулдан уңга: ар, әвернә, чуак, елкы, «Богау», йола, Әдип, кереш, онта, Равил, Ивик, Җамал, Лем, ләгать, бәйлек, сур, Ирек, Раев, урда, фал, «Уен», Әрә, Амга, акын.

Өстән аска: Бәркә, опера, Ра, «Рамай», ефәк, Зәйнашева, лива, Шиллер, Нил, вече, өке, рулада, Анак, ишан, Рәкыйпов, Дунай, Нильс, Рем, Литке, дуга, морза.

***Рәис Габдулла** төзеде.*

«Куман мәҗмугасы» («Кодекс куманикус»)



«БЕЗНЕҢ МИРАС»
елъязмасы / декабрь

715 ел элек (1303)

«Куман мәҗмугасы» («Кодекс куманикус») – итальян һәм алман монахлары тарафыннан төзелгән латинча-фарсыча-куманча (кыпчакча) сүзлек дөнья күрә. Анда шул чорда Хәзәр (Каспий буе) далаларында яшәгән кыпчак һәм болгар кабиләләре телендә йөргән өч меңгә якын төркичә сүз, табышмак вә мәкаль теркәлгән. Сүзлекнең күп кенә тәгъбирләре бүгенге укучыга да җиңел аңлаешлы. Әлеге мәҗмуганың сакланып калган бердәнбер кульязма нөсхәсе Италиянең Венеция китапханәсендә табыла.

630 ел элек (1388)

Туктамыш хан гаскәре, Сырдәрья елгасын кичеп чыгып, өч гасыр элгәре Төркестан күгендә якты йолдыз булып кабынган бөек суфи шагыйрь Әхмәт Ясәвинең туган каласы Ясаны яулап ала.

105 ел элек (1913)

Истанбул каласында «Төрек йорты» җәмгыяте журнал тибындагы «Хәлкъка тугры» (Халыкка тугры) дип аталган мәҗмугасын бастырып чыгара башлый.

100 ел элек (1918)

14 декабрьдә Казанда «Яшьләр йорты» эшли башлый.

90 ел элек (1928)

18 декабрьдә Татар академия театры бинасында Бөтенсоюз яңалиф комитетының Өченче пленумы ачыла.

45 ел элек (1973)

Татарстан китап нәшриятында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» романы китап булып басылып чыга.

10 ел элек (2008)

11 декабрьдә башкалабыз Казанның 103 нче мәктәбендә күренекле әдип Фәнис Яруллин музее ачыла.

Журналга ***Айдар Закиров*** *әзерләде.* ■

2018 ЕЛГА «БЕЗНЕҢ МИРАС» ЖУРНАЛЫНЫҢ БИБЛИОГРАФИЯСЕ

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

Шиһабетдин Мәрҗани. – №1. – Б.3.
Кадыйр Сибгатуллин. – №2. – Б.3.
Саҗидә Сөләйманова. – №3. – Б.3.
Габдулла Тукай. – №4. – Б.3.
Илдус Гыйләҗев. – №5. – Б.3.
Фәннур Сафин. – №6. – Б.3.
Ренат Харис. – №7. – Б.3.
Равил Фәйзуллин. – 75! – №8. – Б.3.
Р.Фәйзуллин. Триптих. – №8. – Б.3.
Илдар Юзеев. – №9. – Б.3.
Фәнис Яруллин. – №10. – Б.3.
Шәүкәт Галиев. – №11. – Б.3.
Гамил Афзал. – №12. – Б.3.

ТАРИХИ МИРАС

«Мусульманская газета»да Габдулла Тукай вафатына нисбәтле язмалар. – №4. – Б.40-43.

А.Габдукаева, Г.Мәсәгутова. Солтанайның солтаны. – №3. – Б.20-27.

А.Хәйретдинов. «Каләм-е Шәриф»ме, әллә «Каләм Шәриф»ме? – №5. – Б.15-17.

А.Хәйретдинов. Муса Бигиев: «Киләчәк – исламиятнеке». – №10. – Б.58-61.

Әүлиялар ватаны – Күбәкәй. – №1. – Б.11-16.

Б.Хәмидуллин. Казан ханлыгының язмышы. – №7. – Б.10-14; №8. – Б.8-13; №9. – Б.8-12; №10. – Б.10-15; №11. – Б.10-15; №12. – Б.12-19.

Б.Шәрәф. Гани бай. – №11. – Б.20-28; №12. – Б.20-23.

Б.Шәрәф. Мәрҗани хакында җавапларым. – №2. – Б.9-12.

В.Әхмәтов. 12 еллык татар җәнлек календаре язма һәм тел чыганакларында. – №1. – Б.34-39.

В.Имамов. Пугачев полковнигы Мәсәгуть Гомәров. – №8. – Б.14-15.

Г.Закирова. Икшермә чиркәве. – №7. – Б.52-55.

Г.Мостафина-Рәфыйкова. «Сәнәкчеләр» фаҗигасе. – №3. – Б.34-39; – №4. – Б.24-27.

Г.Рәхим. «Бүз егет» белән «Таһир-Зөһрә»не язучы кем булган? – №3. – Б.15-17.

Г.Рәхим. Татарстанда вакытлы матбугат. – №6. – Б.30-34.

Г.Ризванов. Тереләй күмелгән эшкуар һәм имам-хатыйп Хәбибрахман Арсаев. – №9. – Б.30-34.

Гарифҗан Мөхәммәтшин: «Әхлакның тамыры – авылда!» – №7. – Б.38-41.

Д.Гыймранова. «Хатыннары тәрбияле булган милләт – тәрбияле...» – №4. – Б.31-34.

З.Габдуллин. Америка мәктүбләре. – №7. – Б.36-37.

З.Мингалиев. Татар дөньясын яктырту: мәгърифәтчелектән – электр энергиясенә. – №10. – Б.52-57.

З.Нәҗметдинов. Иске Пенәгәр: метрикаларда – авылым язмышы. – №4. – Б.19-23.

И.Габдрахманов. Татар хатыны ниләр күрми? – №3. – Б.40-44.

И.Кәрим. «Тюрк-татар дюньясына нур сачкъан Тукъай!» – №4. – Б.40-43.

И.Сафин. Кулаткы суфилары. – №6. – Б.26-29.

И.Таһиров. Татарлар алгарыш юлында. – №6. – Б.8-14.

И.Һадиев, Р.Мәрданов. Иске Җөринең борынгы ядкәре. – №5. – Б.18-21.

И.Һадиев, Р.Мәрданов. Ямаширмә зиратында Алтын Урда һәм Казан ханлыгы истәлекләре. – №10. – Б.16-21.

И.Шаһиев. Гасыр дәвамында үткән юл. – №1. – Б.28-33.

Идел кичми ил булмас. – №5. – Б.10-14.

Камал. Гарәп мохитендә татар туе. – №11. – Б.37-39.

Каюм Насыйри хатлары. – №3. – Б.45-47.

Кулаткы укулары. – №4. – Б.16-18; №5. – Б.27-29.

Л.Гобәйдуллин. «Әлислях» газетасы. - №2. – Б.25-28.

Л.Мортазина. «Шул татарны күрәсе иде, нинди кеше икән?» – №7. – Б.31-35.

Л.Мортазина. Шам татарлары. – №11. – Б.34-36.

М.Әмирханов. Олуг Мөхәммәд. – №5. – Б.22-26.

М.Кәримов. Татарларның Казакъстан дәүләт төзелешенә керткән өлеше. – №4. – Б.28-30.

М.Фәйзи. «Мәрхәмәтсез кыз балалар пәрдә тартып тилмертә...» – №2. – Б.19-24.

М.Хулуси Акчура. «Дога иттек Аллаһка...» – №1. – Б.24-27.

Мансур авылы. – №6. – Б.24-25.

Марат Юнысов: «Сабан туена зур өмет баглыйбыз». – №7. – Б.42-47.

Мәскәү һәм татар дөньясы. – №4. – Б.10-15.

Мөхәммәт Мәһдиев мәкаләләре. №12. – Б.38-41.

Н.Фатыйхова-Потеева. Меңьеллык тарихлы Яуширмә. – №5. – Б.34-38.

О.Иванова. Нурсолтан. – №1 – Б.4-10;

№2 – Б.13-18; №3 – Б.4-11; №4 – Б.4-9; №5. – Б.4-9; №6. – Б.4-9.
О.Иванова. Гәүһәршад. – №7. – Б.4-9; №8. – Б.4-7; №9. – Б.4-7; №10. – Б.4-9; №11. – Б.4-9; №12. – Б.4-11.
П.Салихов. Шыгырдан таңы. – №6. – Б.15-19.
Р.Әминов. Нагайбәк казаклары: саннары, яшәү урыны һәм үзидарә. – №7. – Б.20-23.
Р.Исакаев. Эчкен татарлары. – №7. – Б.28-30; №8. – Б.20-23; №9. – Б.18-21; №10. – Б.28-31; №11. – Б.16-19; №12. – Б.34-41.
Р.Исхаков. Керәшеннәрдә «имнәү», сихер һәм күрәзәлек. – №7. – Б.15-19.
Р.Нуруллин. Бөекләрнең туганлыгы. – №8. – Б.30-35.
Р.Сабиров. Ачлыктан соң Татарстан авыллары. – №10. – Б.22-27; №11. – Б.29-35; №12. – Б.29-33.
Р.Фәхреддин. Әхмәт бай. – №9. – Б.44-49; №10. – Б.32-37.
Р.Фәхреддин. Нигъмәтулла хаҗи. – №8. – Б.24-29.
Р.Фәхретдинов. Русия мәмләкәтендә аутодафе. – №5. – Б.43-45.
Р.Фәхретдинов. Ядәч һәм ядәчиләр. – №2. – Б.34-35.
Ризаэддин Фәхреддин гыйбарәләре. – №7. – Б.9; №8. – Б.45; №9. – Б.13; №11. – Б.51.
Р.Хафизов. Асылыңда ни, Русия? – №3. – Б.28-33.
Р.Хәбибулла. Бүре кыйссасы. – №9. – Б.41-43.
Р.Шаһиев. Риза казый нәселе. – №9. – Б.35-40; №10. – Б.38-44; №11. – Б.40-43.
Р.Шәрәфиева. Мәгърифәт мәркәзе – Мәчкәрә. – №8. – Б.36-39.
С.Максуди. Әнкара хокук мәктәбенең тарихи әһәмияте. – №12. – Б.24-28.
С.Цвиклински. Маргарет ханым. – №5. – Б.46-47.
Сафакүл. – №2. – Б.29-33.
Т.Соловьев. Гани бай хатирәсеннән исемдә калганнары. №12. – Б.20-23.
Т.Кәримов. Катай авылы һөнәрчеләре. – №7. – Б.48-51.
Т.Шәйхнурова. «Хатын-кызның күрке – яулык». – №6. – Б.20-23.
Татар авылы: үткәне һәм бүгенгесе. – №2. – Б.4-8; №3. – Б.12-14
Ф. Хисамиева. Ольга апа бәете. – №9. – Б.22-24.
Ф.Бәйрәмова. Японияне ачкан татар галиме (Әбрар Кәримуллин язмаларында япон темасы). – №8. – Б.40-44; №9. – Б.25-29.
Ф.Газизова. Чал тарихлы Кодашым: алып батырлардан «чабаталы аклар»га кадәр. – №1. – Б.17-23.
Ф.Закиров. Кәче иле. – №11. – Б.46-50.
Х.Габидуллин. Татар телен гамәлгә кую мәсьәләләре. – №7. – Б.24-27; №8. – Б.16-19; №9. – Б.14-17.
Ш.Күлтәси. Хәлемездән шикаять. – №12. – Б.42-47.
Э.Гайнетдинова, Л.Закирова. Казиле мәчете һәм мәдрәсәсенең тарихы. – №10. – Б.45-51.
Э.Ихсанова. Халык язган китап. – №5. – Б.30-33.
Э.Сәлахова. «Нимесчә аш». – №5. – Б.39-42.

ТАТАР ГАМЕ

Ә.Сафуанов. Өч армия, максат – бер. – №6. – Б.50-53.
Г.Морат. Үз заманын узып яшәде ул... – №8. – Б.50-53.
Р.Мәһдиев. Галим Рөстәм Үтәмешев. – №9. – Б.57-61.
Данлы төбәк – Кукмара. – №8. – Б.54-59.
И.Әхмәтҗанов. Хаҗ сәфәре. – №4. – Б.50-55.
Кукмара муниципаль районы башлыгы Сергей Димитриев: «Кукмараның төп байлыгы – аның халкы». – №8. – Б.48-49.
Л.Лерон. Дөнья гаме – садә җанында. – №11. – Б.52-56.
М.Хәбетдинова. «Буа Талиясе». – №11. – Б.57-61.
Мирасыбыз сагында. – №2. – Б.42-49.
Н.Акмал. Ил агасы. – №1. – Б.40-47.
Р.Батулла. Безнең заман каһарманы. – №3. – Б.55-59; №4. – Б.44-49; №5. – Б.48-51; №6. – Б.35-41.
Р.Галиуллин. Остаз. – №7. – Б.74-77.
Р.Сәгъди. Карантау итәгендә. – №6. – Б.42-46.
Республикабызга һәм татар халкына фидакарь хезмәт итүче. – №8. – Б.46-47.
Сәхнә – аның тормыш аренасы! – №10. – Б.62-67.
Татар кайда да татар... – №3. – Б.50-54.
Ф.Фәтхи. Галимҗан Ибраһимов туганы. – №6. – Б.47-49.
Эмиль Җәләлетдинов: «Яшьлеккә? Юк! Кире кайтмас идем...» – №10. – Б.68-73.

ТӨРКИ ДӨНЬЯ

А.Галимҗанов. Тәңре, Дингир вә Умай... – №1 – Б.48-51; №2 – Б.36-39.
Балкар халкының сөекле шагыйре. – №2. – Б.40-41.
Бөек Тукай адашы (Абдулла Арипов). – №1. – Б.52-53.
З.Бәшири. Чуашлар. – №7. – Б.64-68; №8. – Б.62-67; №9. – Б.62-68.

И.Гафаров. «Codex cumanikus» – төрки мирас. – №6. – Б.56-59.
Казакъ халкының мәшһүр улы. – №5. – Б.52-53.
Кем ул Пурхи Ахван? – №7. – Б.62-63.
Сөрген шагыйре. – №3. – Б.48-49.
Туган телен данлаучы шагыйрь. – №4. – Б.56-57.
Үзбәк халкының сөекле шагыйре. – №6. – Б.54-55.
Чуашның мәшһүр улы. – №8. – Б.60-61.

ДИНИ МИРАС

Г.Ибраһимов. Ислам дөньясы. – №1-12.
Л.Лерон. Рәхмәт сүзе. – №1. – Б.59.
Г.Гомәр. Хәлфә бабай. – №1. – Б.60-63.
М.Галләм. Хөсни хат. – №3. – Б.66-67.
Ж.Фазлыев. Хаҗга озату догасы. – №5. – Б.60-61.
2019 елда дини бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр. – №12. – Б.54-55.

ӘДӘБИ МИРАС

«Тукаевтан соң беренче шагыйремез...» – №1. – Б.73-76.
А.Гыйләҗев. Роман уйландыра. – №11. – Б.74-81.
Аяз Гыйләҗев хатлары. – №2. – Б.56-63.
А.Хәсәнов. Әдәбиятыбыз күгендә якты йолдыз булды. – №9. – Б.72-76.
Әбрар Кәримуллин хатлары. – №9. – Б.77-79.
Әсәрләрендә – милли көрәш рухы. – №8. – Б.76-79.
Г.Бәширов. Үзем һәм юбилеем турында. – №2. – Б.74-75.
Г.Галиев. Сандугач. – №6. – Б.72-76; №7. – Б.78-81.
Г.Монасыйпов. Ышанычсыз юлга бер адым. – №1. – Б.68-72.
З.Рәмиев. Абай. – №6. – Б.78-79.
И.Фазлуллин. «Бишектән үк иртә төшкәннәр...» – №4. – Б.71-73.
И.Фазлуллин. Хәсән Туфан фатихасы белән... – №10. – Б.71-73.
К.Булатова. Милләтем, дип, халкым, дип... – №3. – Б.76-79.
К.Саттаров. Дуслыгыбыз гомерлек булды. – №8. – Б.80-83.
Каһарман Катыйл. – №1. – Б.64-67.
Кыңгыраулар җыры. – №3. – Б.80-81.
Л.Лерон. Булат Сөләймановның ике гаризасы. – №5. – Б.66-67.
Л.Хәмидуллин. «Күңел дәфтәре»ндәниләр бар? – №2. – Б.70-73.
М.Әгъләм «Яңгыр җиле» яңгыр вәгъдә итә. – №12. – Б.68-72.
М.Әхмәтҗанов. Тукай белән Дусай арасы. – №4. – Б.64-67.
Мәктәп-музей. – №3. – Б.85.
Мәхмүт Хәсәнов хатлары. – №3. – Б.72-75.
Мирсәй Әмир һәм ЛОКАФ. – №1. – Б.78-79.
Н.Фәттах. Үзем генә түгел. – №10. – Б.78-83.
Р.Ахунҗанова. Алтынга тиң киңәшләр. – №6. – Б.68-71.
Р.Әхмәтҗанов. Туган телнең хәстәрчесе. – №2. – Б.64-66.
Р.Ганиева. Олпат галим. – №6. – Б.77.
Р.Зәкиева. «Калкыйм йолдыз булып күкләрдә...» – №1. – Б.80-81.
Р.Мирхәйдәров. Безнең Чыңгыз Айтматов. – №4. – Б.68-70.
Р.Мозаффаров. Абдулла Алиш әкиятләренең басма вариантларындагы үзгәрешләр. – №3. – Б.82-84.
Р.Мөбарәкшина. Язучы, танкист, укытучы. – №1. – Б.77.
Рәҗәп Шүкрү Гүнгөр. Аяз Гыйләҗевнең «Яра» романында милли һәм дини мотивлар. – №8. – Б.72-75.
С.Максуди. Мәгыйшәт. – №11. – Б.82-87; №12. – Б.62-67.
Сәгыйть Сүнчәләй. – №12. – Б.60-61.
Үткәнгә хат. – №12. – Б.56-59.
Үткәннән үтенеч. – №2. – Б.68-69.
Ф.Кутлу. Аяз Гыйләҗев һәм мин. – №5. – Б.62-65; №6. – Б.64-67.
Ф.Хәбибуллин. Шагыйрь Бәдрүш Мокамай. – №11. – Б.88-93; №12. – Б.73-77.
Ф.Яруллин. Татар теле. – №2. – Б.67.
Э.Шәрифуллина. «Яңгыр җиле» – шифалы җил. – №4. – Б.74-79.

ХӘТЕР САНДЫГЫ

Г.Галиев. Сукыр Сибгат һәм аның хисапчы улы Миңнегали. – №1. – Б.86-89.
Галиҗәнап галим. – №1. – Б.82-85.
З.Зәйнуллин. Заһит Таз. – №7. – Б.88-89.
И.Салихҗан. Батыр йөрәкле Зәйнәп. – №8. – Б.86-91; №9. – Б.82-89.
Истә, һаман да, истә! – №2-12.
Л.Закир. Тимерче Фатих. – №2. – Б.80-82.
Л.Зөлкарнәй. Хушлашу сүзе. – №1. – Б.90-92.
Л.Лерон. Саимә апа, дисәм... – №3. – Б.94-98.
Макс Гатау шигырьләре. – №4. – Б.86-87.
Р.Шәрәфи. Әз-мәз үзем турында. – №4. – Б.91-93; №5. – Б.78-81; №6. – Б.88-91; №7. – Б.94-98.
С.Сәубанова. Шагыйрьнең соңгы музасы. – №9. – Б.90-98.
Ф.Галимуллин. Тыңлагыз, Казан сөйли! – №11. – Б.94-97.

Х.Бәдигый. Милли мәгариф каһарманы. – №7. – Б.90-93.
Х.Җәләй. Кала юлы яки качкын малай. – №3. – Б.88-91.
Шагыйрь Макс Гатау һәм аның туган авылы Тозау. – №5. – Б.73-75.
Ю.Сафиуллин. Равил Шәрәфине беләбезме? – №4. – Б.90.

СӘНГАТИ МИРАС

Алиһә. – №1. – Б.100-101.
Атлаган алга китәр. – №10. – Б.95-99.
Ә.Зарипов. Сабакташым, иҗатташым... – №2. – Б.86-93.
З.Гыйльметдинова. Татар моңы әхрамы. – №1. – Б.93-99.
Кем ул Васил Әхмәтҗанов? – №3. – Б.99-105.
Л.Лерон. Әлфия апа. – №1. – Б.103.
М.Фәйзулаева. Бәхетле моң остасы. – №7. – Б.99-103.
Р.Гатауллин. Аһәңи ләззәт чыганагы. – №10. – Б.90-94.
Р.Шаһиева. Киң тармаклы милли иҗат. – №2. – Б.94-97.
Рәшит Ваһапов ядкәрләре. – №6. – Б.92-97.
Ю.Сафиуллин. Чын иҗат кешесе. – №5. – Б.82-87.
Э.Каюмова. Җырлар артыннан илләр гизеп. – №2. – Б.98-101; №5. – Б.88-92.

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

А.Тимергалин. Миллият сүзлеге. – №№1-12.
Р.Юсупов. Телебезне кадерләп саклыйк. – №10. – Б.102-105; №11. – Б.102-105.
Р.Хәбибулла. Сүз уравын белмәгән үзенә сүз китерер... – №12. – Б.96-97.

ХӘТЕР САГЫНДА

«Мәрҗани» чишмәсе. – №1. – Б.114-115.
«Революция давылы: Россия тарихында 1917 ел». – №1. – Б.110-113.
«Совет мәйданы» – тарихыбызның өч чоры. – №6. – Б.110-111.
«Мулла чишмәсе». – №9. – Б.108-111.
Гани Сафиуллин мирасы. – №3. – Б.115.
Затлы китап. – №5. – Б.110-111.
Кала тавы. – №11. – Б.112-113.
Киез итекләр иле. – №№3-12
Л.Лерон. Татарның асыл улы. – №2. – Б.110-115.
Л.Мөхәммәтшина. «Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем...» – №8. – Б.108-111.
Л.Гобәйдуллин. «Эш» газетасы. – №3. – Б.111-114.
Милли музейда Шиһабетдин Мәрҗани. – №2. – Б.108-109.
Симетбаш җыены-2018. – №7. – Б.110-111.
Симетбаш мәчете. – №12. – Б.104-107.
Татарстан Республикасының Милли китапханәсе. – №№1-12.
Ташкичүдә – «Мәрҗани» музее. – №4. – Б.108-110.
Ф.Нәбиуллин. Гаилә-нәсел мохитендә символлар һәм тамгалар теле. – №6. – Б.104-109.
Хәрби элемтәче һәйкәле. – №10. – Б.112-113.

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН…

Абдулла Алиш. – №9. – Б.80-81.
Галимҗан Нигъмәти. – №5. – Б.68-72.
Гаяз Исхакый. – №4. – Б.80-85.
Җамал Вәлиди. – №6. – Б.80-83.
Йөгез, бер дога! – №2. – Б.76-79.
Мәхмүт Галәү. – №7. – Б.82-85.
Муса Җәлил. – №8. – Б.84-85.
Фатих Сәйфи-Казанлы. – №3. – Б.86-87.
Х.Гали. Җ.Вәлиди турында. – №6. – Б.84-85.
Хәйретдин Мөҗәй (1901-1944), Шамил Гәрәй (1916-1946). – №10. – Б.86-87.

ПЕДАГОГИК МИРАС

Х.Әбүзәров. Уку китабы. – №3. – Б.68-71.

СУГЫШ КАЙТАВАЗЫ

Ш.Мостафин. Тарихи мизгелләрне мәңгеләштерүчеләр. – №4. – Б.94-101.
А.Гаделша. Солдат бабай Миргазиз. – №5. – Б.93-99.
Х.Закиров. Әтиемнең күргәннәре. – №5. – Б.100-103.

МӨҺАҖИРЛӘР МИРАСЫ

Л.Гобәйдуллин. «Яңа милли юл». – №7. – Б.56-61.
Л.Галиева. Гаяз Исхакый Ләһстанда. – №9. – Б.50-53.
Г.Исхакый. 1931 елгы мөселман конгрессы. – №9. – Б.54-56.

БЕЗНЕҢ МИРАС ХӘБӘРЛӘРЕ. №№1-12.

МИРАСВОРД. – №1-12.

«БЕЗНЕҢ МИРАС» ЕЛЪЯЗМАСЫ. – №1-12.

ЯҢА КИТАП

М.Хәйруллин. Гамле мирас. – №8. – Б.116-117.

ФОЛЬКЛОР МИРАСЫ

Г.Хаҗиева, Ф.Баязитова. Йорт иясе – йорт тоткасы. – №11. – Б.68.

ЯДКӘРЛӘРЕБЕЗ

Алишны халык онытмый. – №11. – Б.67.

СОДЕРЖАНИЕ. ДЕКАБРЬ 2018

Историческое наследие: «Гаухаршад». О.Иванова**;** **«**Судьба Казанского ханства». Б.Хамидуллин; «Гани бай». Т.Соловьёв; «Историческая ценность юридической школы Анкары». С. Максуди; **«**Татарские деревни после голода в Поволжье». Р.Сабиров; «Ичкинские татары». Р.Исакаев.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Г.Ибрагимов; « Религиозные праздники и памятные даты 2019 года».

Литературное наследие: «Письмо в прошлое»; «Жизнь». С. Максуди; «Поэт Бадруш Мукамай».

На страже памяти: «Национальная библиотека Республики Татарстан»; «Страна валенок».

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

CONTENT. DECEMBER 2018

Historic heritage: «Gaukharshad» by O.Ivanova; «The fate of Kazan khanate»
by B.Khamidullin; «Gani richman» by T.Soloviev; «The historic value of Law school in Ankara» by S.Maksudi; «The state of the Tatar villages after starvation» by R.Sabirov; «The Ichken Tatars» by R.Isakaev.

Religious heritage: «Islamic world» by G.Ibragimov; «Religious holidays and memorable dates of 2019».

Literary heritage: «Letter to the past»; «Existence» by S. Maksudi; «Poet Badrush Mokamay».

On the guard of the memory: «The National library of the Republic of Tatarstan»; «The felt-boots country».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life

1928 елның 11 декабрендә Менделеевск шәһәрендә туа. Казан сынлы сәнгать училищесын (1949), В.И.Суриков исемендәге Мәскәү сынлы сәнгать институтын тәмамлый.

СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, Ленин комсомолы премиясе лауреаты, РСФСРның атказанган рәссамы (1970).

1964-1968 һәм 1970-1977 елларда Ярославль Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе.

1982 елдан – ТАССР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе.

Әмир Нуриәхмәт улы Мәҗитов 1992 елның 23 мартында вафат була.

Әмир Нуриәхмәт улы Мәҗитов

«Хат ташучы кыз». 1966. Киндер, майлы буяу

«Балыкчылар». 1963. Киндер, майлы буяу

«Финишта». 1957. Киндер, майлы буяу

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
белән бергә булыгыз!

ИГЪТИБАР! ИГЪТИБАР!

Хөрмәтле абунәчеләребез!
Журнал индексын каталогтан эзләп вакытыгызны югалтмыйча, турыдан-туры элемтә бүлеге хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итә аласыз.

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П-2343
РОССИЯДӘ – 70275 (П-7074)
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналына башкача язылу:
- ***uslugi.tatarstan.ru*** *сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- ***podpiska.pochta.ru*** *сайты ярдәмендә электрон версия*

«БЕЗНЕҢ МИРАС» *журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*

4 612750 670172